# Абдулла Алиш

## ЯКТЫ КҮЛ БУЕ

### Миләүшә елгасы

Җил-яңгыр белән калай түбәләренең буяулары ашалган, үзе җиргә сеңәргә әзерләнгән күн заводының корпуслары яныннан, култыкланып, Миләүшә елгасы ага. Бу елга Миләүшә авылы янындагы куе таллык эчендәге чишмәдән башлана. Чишмәлектән тауны күтәрелгәч, уч төбендәге кебек тигез кырда авыл үзенең эреле-ваклы йортлары белән җәелеп ята. Елганың башы әнә шул салам түбәләре белән капланган Миләүшә авылы ягыннан башланганга күрә, аңар Миләүшә елгасы дигәннәр.

Миләүшәлеләр үзләренең терекөмештәй саф, боздай салкын сулары белән һәрвакыт мактаналар. «Самовар куйсаң, самоварга юшкыны утырмый, җәйге кызуда урак урганда эчеп җибәрсәң, үзенең салкынлыгы бөтен тәнгә тарала, әллә нинди баллы эчемлекләрең дә кирәкми!» — дип куялар. Дөрестән дә, авыл буенда елганың суы салкын, ләкин ул, Миләүшәдән борылып-борылып киткән километрларга сузылган саен, үзенең суын җылыта бара.

Кайчандыр елга буендагы кабыргаларның куе кара урман белән капланганын сөйлиләр. Ул чакта аның суы хәзергегә караганда мулрак та, салкынрак та булган. Ә хәзер елганың шәһәргә китергән суы күп түгел. Бигрәк тә җәй көннәрендә ул авырган кеше сыман ябыгып кибә башлый.

Елганың уң ягында, күн заводының корпусларын үткәч, үзенең пулатлары, зур тәрәзәләре, кирпеч өйләре, өй түбәләрендә берсеннән-берсе үрмәкүч җебедәй сузылган тимерчыбыклы радио колгалары, завод морҗалары, чиркәү, мәчет гөмбәзләре белән шәһәр башлана.

Шәһәрдә зур корылмалар, фабрик-заводлар күп түгел, аларны санарга бер кулыңдагы бармаклар да җитә. Елга буена орынып ук торган Ленин исемендәге күн заводы иң зурларыннан санала. Ул элек бик кечкенә булган, аны башта шушы шәһәрнең Сыртланов дигән тиречеләре кустарь рәвешендә генә корып җибәргән булганнар. Япон сугышы вакытында, армиягә итекләр әзерләү заказын алгач, бу завод зураеп үскән...

...Таш урамнар аша эчкәрәк керсәң, кечкенә генә бер электр станцасы йөрәк^ тибешедәй тигез ритм белән бертуктамый эшләп тора. Йөзендәге җыерчыклар аның картлач икәнлеген, инде гомере озак калмаганлыгын, тиздән шәһәр уртасының корым туздыручы бу кечкенә өйдән котылачагын күрсәтеп торалар.

Моннан күп еллар элек Бельгия байлары, үзләренең ерак илләреннән килеп, шәһәрнең бер таш урамы буенча корыч рельслар сузган булганнар. Ул чакта әле электр тогы булмаган. Дүрт тәгәрмәч өстенә ящик куелган «трамвай» дип аталган

арба атлар белән хәрәкәткә китерелгән. Аннан соң гына Бельгия байлары, табышны тагын да күбрәк җыйнау өчен, югарыда әйтелгән станцаны корганнар.

Промышленность үскәч, күн заводы буендагы эшчеләр бистәсенә яңа трамвай линиясе сузылгач, шәһәрдә бербер артлы яңа биналар башларын калкыткач, шәһәргә күп көч, күп энергия бирә торган электрның кирәклеге көннән-көн ачык сизелә башлый. Шуңа күрә электр станцасы салыну турындагы хәбәр шәһәр халкы тарафыннан зур шатлык белән каршы алына.

Трамвай борылышларындагы плакатлар шәһәрнең киләчәге турында сөйлиләр:

«Бу елдан башлап шәһәрдә җитмеш ике мең киловаттлы электр станцасы төзелә башлый. «Светогрэс»ка ярдәмгә!»

«Бөтен көч индустрияләшү юлындагы иң көчле булган корылманы электрлаштыру өчен!»

Тротуардан ашыгып-ашыгып узучылар, башларын күтәрә төшеп, плакатларны укыйлар.

Башта яңа салыначак электр станцасын, Миләүшә суын буып, гидроэлектростанция итеп салмакчы булдылар. Күп тикшеренүләрдән, эзләнүләрдән соң бу фикер үзгәрде. Мондый зур эшкә Миләүшәнең суы җитә алмас-лыгы беленде. Шуңа күрә елганы буып, Якты күлгә кертү проекты узды. Бу проект буенча күлнең болай да мул суы тагын да күбәячәк. Аңа агып кергән Миләүшә суы үзенең ярты балыгын, ярты суын калдырып юлын дәвам итәчәк.

...Якты күл буе хәзер элеккечә тыныч түгел.

Анда эзләнүчеләр отрядыннан җирнең өске төзелешен геодезия кораллары белән үлчиләр. Бер ноктаның икенчесеннән күпме биеклектә икәнлеген тикшерәләр, электр станцасы салыначак мәйданның почмакларын билгелиләр. Техник үзенең үткен күзен шул коралларның трубаларыннан бер ала, бер тагын аларга якын килеп карый. Аннары кулындагы дәфтәренә нидер язып куя. Рейка күтәргән эшчеләр әрле-бирле чабышып йөриләр.

Әнә бурить итүчеләр отряды, җирнең карынын тикшереп, астагы катлауларның ниндилеген белергә тели. Биек итеп өч аякка беркетелгән бурларны эшчеләр, җыр-лый-җырлый, җир куенына югалтырга, аскарак сеңдерергә тырышалар. Җир әйтерсең шул тимер бурны үзе теләп йота.

* * *

...Мәйданны, күл тирәсен төзү материаллары чолгап алган. Эреле-ваклы бүрәнәләр, такта өемнәре; тау булып елга комы, чуерташ, бут ташы, арматура

тимерләре; яңгырдан саклар өчен ышык ясалган лапасларда цемент мичкәләре, төрле машиналар тиздән бу урында гигант салыначагы турында сөйлиләр.

Шәһәр дә, ничек кенә булса да бу яңа төзелешкә ярдәм итү өчен, төрле чаралар күрү эшенә керешге. Шәһәрдәге төрле оешмалар үзләренең җыелышларында гигант төзелеш мәсьәләсе турында фикер алыштылар. Төзелешкә ярдәм итү турында карарлар чыгардылар.

Яңа гигантка ярдәм итү мәсьәләсе күн заводын да читләтеп үтмәде.

Күн заводы комсомол бюросының көн тәртибендә бүген әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып заводтан ерак түгел урында салыначак «Светогрэс»ны шефка алу, аңа ярдәм итү бурыч итеп куелган. Бюро членнары өстәл янында түгәрәк балдак ясап утырганнар. Бүген дә секретарь сүзен гадәтенчә «Иптәшләр»дән бантлады:

— Комсомол 1930 елның декабрь аенда илне электр-латтыруны шефка алды. Комсомол Үзәк Комитетының шул карарында: «Милли җөмһүрият комсомоллары үзләренең республикаларында төзелә торган электр стан-цаларын шефка алырга тиешләр», — диелгән. Төзеләчәк электр станцасының безнең завод, шәһәр һәм республика өчен нинди әһәмиятле икәнлеге барыбызга да билгеле булса кирәк. Хәзерге вакытта төзелеш яңа гына оешып килә, анда комсомол көчләре ифрат дәрәҗәдә аз санда.

Авыллардан, колхозлардан килүче сезонниклар арасында аң-белем алып барырдай кешеләр аз. Без ярдәмгә килергә тиешбез.

Башта биш кешене, заводтагы эшләреннән аермыйча гына, яңа төзелешкә билгеләргә уйлаганнар иде. Ләкин партячейка вәкиле каршы төште:

— Андый зур эшкә ун комсомолны бөтенләйгә күчерергә кирәк, — диде.

Бюро да бу фикерне яхшы дип тапты. Шул ун комсомол арасында Сабир Сал ахов та бар иде. Секретарь Салаховны җибәрмәс өчен нык тырышты. Аңар каршы Разия:

— Яңа Салаховлар тудырырга тиеш син, иптәш секретарь! — дип, нәзек тавыш белән җавап кайтарды.— Чөнки яңа төзелеш өчен комсомолның бик тә активлары кирәк. Анда әле заводка караганда да эш күп булачак, бердән, анда вакытлы эшчеләр эшлиләр. Аларның күбесе безнең көлләү цехындагы чимал кебек. Аларны тәрбияләп, яңа тормыш өчен көрәшүче батырлар тудыру — бу безнең бурыч!

Бюро соңыннан Сабир белән Разия икәүләп кайтырга чыктылар. Ишекне узган чакта, кайсыдыр, бармак селкеп:

— Сиздем эшегезне! — дип көлеп калды.

— Сиздерергә кирәк аны! — диде Разия. Юлда ул: — Ну бәхетле дә син, Сабир, нинди зур төзелешкә эләктең бит. Кара аны, күн заводы комсомолының авторитетын төшерәсе булма,— диде, шаярып кына бармак янап куйды.— Беләсеңме, Рәхимне билгеләтергә мин ник каршы төштем?

- Ник?

— Бөтен матур, булдыклы егетләребезне алып китеп бетерәләр.— Үзе шаркылдап көлеп җибәрде. Сабир да бу сүзләрнең уйнап әйтелгәнен сизеп алды. Шуңа да тагын ниндидер сүзләр көтте. Ләкин Разия, бөтенләй җитди итеп: — Сабир, син үзеңнең безнең заводка ничек килеп эләгүең турында миңа сөйләргә теләгән идең бит, — диде.

— Мин аны һаман сөйләмәдеммени әле?

— Юк шул.

— Ну ярый, тыңларга иренмәсәң, мин сиңа үземнең тормыш юлымны кыскача гына сөйләп чыгам. Бәлки, ул сиңа кызык та булмас...

— Ярар инде, аларын калдырсаң да, — диде Разия.

— Юк инде, мин, сөйләргә тотынгач, берсен дә калдырмыйм, — диде дә Сабир сөйләргә тотынды: — Авыл кырыенда караңгы гына кечкенә салам башлы өй безнең өй иде. Бәлкем, синең Миләүшә дигән авылны ишеткәнең дә бардыр. Менә бу Миләүшә елгасы башланган авыл минем туган авылым була...

...Минем эти — авылның бер ярлысы, аңар Салах Ертык дип кушамат та такканнар. Беләсең инде, хәерче кеше ертыксыз булмый. Аны яшь чагында әтисе мәдрәсәгә дә биреп караган. Ул юкә башмак белән бер-ике малайның борынын сугып канаткан да аннан качкан. Бабай аны, кыйнап, яңадан илтеп караган, әмма эти барыбер укымаган.

Революция башларында этине ярлылар комитетына сайлап куялар. Ә бездән көлүчеләр һаман бетми... Кайсы явызларыдыр бәетләр дә чыгарып өлгерәләр. Менә сиңа хәтердәгесен китереп узам:

*Сәлахетдин бакчасында яфрак яра таллары,*

*Кәмитеткә кергәчтен рәхәтләнде җаннары.*

*Кибет эче салкын икән, әйдә, Хәйрулла, кайтыйк,*

*Комган белән кирасин ташый Салахетдин «Кәмитет».*

Сабир, әзрәк тукталып торгач, тагын сөйләргә тотынды:

— Шулай итеп, комитет тирәсенә активлар, совет кешеләре җыелды. Әле ул чагында безнең авылда партия ячейкасы да, комсомол ячейкасы да юк иде.

Әтидән байлар дер калтырап тордылар. Тора-бара әтине тегесе дә, бусы да сыйлый башлады. Ул үзе болай эчә торган кеше түгел иде. Инде эчеп кайткалый башлады. Соңыннан, бу эшкә тәмам бирелеп китеп, алкоголикка әйләнде. Аны комитеттан себереп чыгардылар. Шулай итеп, тәмам бозылды... Бервакыт җәйге бөркү төндә эти исереп кайтты. Ишекне ватарлык булып дөбердәтә. Мин юрган астыннан гына карап ятам. Әни, курка-курка, ишекне барып ачты. Өйгә керүгә, эти, ачуланып, әнигә үзенең тупас йодрыгын күтәрде. Аның сукса тимер өзәрлек йодрыгы бер-бер артлы әни аркасына төшә башлады. Аннары ул мин яткан сәкегә таба килде дә: «Син әниең яклымы, сабака?» — дип мыгырдады. Мин инде юрган астында бөгәрләнеп, нәни генә калган идем. Ул мине тартып төшерде дә тотынды сосарга, кай җиреңкычыта... Әни мине якларга тотынды. Шуннан мин аның кулыннан ычкындым да ишегалдына, аннан капканы ачып урамга... ча-бам-чабам, үзем һичкая барганымны белмим... Ул төнне ындырдагы әрбәлектә үткәрдем. Шуннан инде күп авырлыклар белән шәһәргә килеп, шушы көн заводына кердем...

— Их, бик күп авырлыклар күргәнсең, — диде Разия, аның беләгеннән йомшак кына итеп тотып.— Ә бит мин дә, Сабир, белсәң иде, ниләр генә күрмәдем...

Разия, нәрсәдер уйлаган кебек булып, сүзеннән туктады да тирән итеп сулап куйды. Алар берникадәр вакыт сөйләшми бардылар.

— Разия, бер сөйләрсең әле син ал арны миңа, — диде Сабир.

— Сөйләрмен, билгеле, сөйләрмен...

— Беләсең, менә шуларны сөйләсәң, әллә ничек күңел бушанып китә.

— Димәк, син инде аларны ташлап качтың?

— Сиңа шулай аңлашылдымыни? Мин аннан соң әле авылда күп тордым. Шулай да мин качып китмәдем. Бары да ризалык белән эшләнде...

Алар тагын сөйләшми бардылар. Сабир, Разиянең бераз гына калтыранганын сизеп:

- Туңасыңмы әллә? -- диде, аңа таба елыша төште. Капка төбенә җиткәч, алар туктадылар.

- Кара әле, Сабир, син үзегезнең цех буенча ярыш договоры пунктларының үтәлешен тикшер әле. Иртәгә үк тегендә бармый торгансың? Аннан синең урыныңа бер җаваплы кеше билгеләргә кирәк!

Разия инде баягы йомшаклыгын югалткан. Хәзер аның тавышында ниндидер эшлеклелек бар иде. Алар саубуллаштылар.

**Күк күлмәклеләр**

*Без — эшче яшьләр,*

*Безгә бар эш билгеле.*

*Шуңа күрә бар эшкә дә*

*Чаклап кисәбез өлгене.*

*Бер, ике, өч. Бер, ике, өч.*

*Бер, ике, өч. Мә сиңа чүкеч!*

Күн заводының клубы көн дә шул җырларны ишетә. Сәхнәдә уйнаучыларга, бетмәс-төкәнмәс энергияле яшьлек ялкыны битләрендә балкыган кешеләргә әйтерсең кемдер ерактан кычкыра...

Кызып репетиция бара. Суфлер кычкырып-кычкырып укый, кемдер аның артыннан декламацияли.

Чаттагы өстәлгә таянып, бер егет белән бер кыз сөйләшә. Алар белән беркем дә кызыксынмый, чөнки башкалар, дәрт биреп, рольләрен башкаралар.

Шадра битле, саргылт чәчле егет, сүзен дәвам итеп:

— Сез кайда эшлисез әле, Фатыйма? — диде.

— Мин тегү мәктәбендә укыйм, — диде каратутлы кыз.

— Ул мәктәп шәһәрнең аргы башында бугай. Сез шулкадәр җирдән килеп йөрисезме?

— Юк, мин бит бу тирәдә генә торам. Репетиция ясаучыларның берсе җырлый башлады.

Сөйләпшүчеләр, туктап, аның җырын тыңлап алдылар.

— Шәп җырлый бит, — диде Сабир. Аннары: — Ул бит минем авылдашым, — дип арттырды. Соңыннан үзе дә уңайсызланып китте...

— Мин аны беләм, — диде Фатыйма. — Хәтерем ял-гышмаса, исеме — Вафа, фамилиясе Абдуллин бугай?

— Ие, Абдуллин.

Алар артык сөйләшә алмадылар, чөнки юлбашчы Разия:

— Сабир Салахов! — дип кычкырды. Кычкырды да, ике кулын чәбәкләп:
— Тынычлык саклагыз әле, иптәшләр! — диде.

Сабир сәхнәнең уртасына килеп басты.

...Сәхнәдә капиталистик илләрнең сугышка әзерләнүе турында «Женева өстәле» күрсәтелде. Әнә Бриан, озын мыекларын сыпыра-сыпыра, сугышны «булдырмау» турында речь сөйли. Ә сүзеннән туктагач, авызыннан һавага ялкын күтәрелә. Бриан ролен башкаручы Сабир, речь арасында туктап, маңгай тирен сөртә, аннары алдындагы стаканнан «су эчә». Шырпы сыза, һәм аның авызыннан һавага ялкын күтәрелә. Клуб керосин исе белән тула.

Икенче номер завод тормышыннан алынган. Көлләү цехы комсомоллары төрлесе төрле урынга таралып эшлиләр. Бар эшләре — тәмәке тарту. Беләк юанлыгы итеп махра төрәләр дә тартырга утыралар, махра төрәләр дә тартырга утыралар. Җитмәсә, цех мөдире Кашимов бу эштә бигрәк тә аерыла төшсә. Аның трубкасы адәм күтәрә алмаслык. Әнә аңар комсомоллар ярыш договоры күтәреп киләләр, ул әйләнеп тә карамый... Шул вакыт сәхнәгә Разия чыгып баса. Ул күкрәгенә «Өзеклек» дигән язу таккан.

*Сез мине чакырдыгызмы?*

*Рәхмәт, мин килдем.*

*Мине яшәтегез инде,*

*Китмәскә килдем...—*

дип җырлый ул.

Яңадан күк күлмәклеләр чыгып, комсомолларны, эшче яшьләрне, бөтен эшчеләрне өзеклек белән көрәшкә чакыралар. Шуның белән пәрдә төшә. Бөтен залны яңгыратып кул чабалар.

Залда ут кабынуга, көлләү цехында эшләүчеләрнең дә битләренә кызыллык йөгерә. Бигрәк тә хурланучан Рәхим, аскы иренен тешләгән килеш, ут кабынуга, ишектән чыгып югала... Ул, йодрыкларын кыскан килеш, үзенә-үзе сөйләнеп кайта: «Иртәгә үк, иртәгә үк барын да оештырырга!» — ди ул.

Бу номерларны Вафа эшләгән. Аңарда сүзне, фактларны калыпка салу куәте бар. Бу куәте өчен ул Разия тарафыннан мактала, Фатыйма тарафыннан сөелә, Сабир тарафыннан якын күрелә.

Клубтан таралучыларның тавышлары, сөйләшүләре белән урам тулды.

— Әй, көлләү цехын көлләделәр дә соң!

— Сөйләргә генә җиңел ул, бар әле, үзең ул цехта эшләп кара!

— Ә рамочныйда җиңелмени?

— Аның ише эшмени ул, кәҗә савып утыралар шунда...

Фатыйма белән Вафа клубтан соңарып кына чыктылар да куе яфраклы тупыллар буйлап алга атладылар. Вафа чаттагы сәгатькә карап алды:

— Иртә икән әле, — дип куйды.

Алар, бер-берсен аңлаган шикелле, сүзсез генә бакчага таба атладылар.

Бакча халык белән тулы иде. Кешеләр аллеялар буйлап йөриләр, эскәмияләрдә утыралар, бакчаның кичке саф, тын һавасын сулыйлар.

...Алар бакчаны бер-ике тапкыр әйләнделәр. Җанлы газетта кемнәрнең рольләрен начар башкарулары, кемнәрнең яхшы уйнаулары турында сөйләштеләр. Әнә теге тау сыртында үскән сирень агачлары төбендә әйбәт чирәмлек. Бу аллеяда халык та йөрми. Йөри торгач, Фатыйма да:

— Арыдым... — диде. Сузып әйтелгән сүзенә үзе ялгап та куйды: — Берәр җиргә барып утырсаң иде.

Вафа аны баягы агачларга таба алып китте...

**Тире белгече**

Тиречe Әнвәрне Миләүшә авылында белмәгән кеше юк. Аның туры ат белән атна саен Спас базарына тире төяп китүен миләүшәлеләр күреп калалар. Әнвәр бай әлегә авылда рәхәтләнеп тора, әлегә аңар революция давылының җилләре нык кагылмаган. Ул җилләрдән яшел калай түбәле йорт сакланып калган. Алай булса да, давыл булуы көтелә. Бу давылның булачагын Һашимов барометр кебек сизә.

Салах Ертык гомер-гомеренә Әнвәрдә хезмәтче булып торды. Утарларга сыеша алмыйча үскән малларны карады, тәрбияләде, асларына салам түшәде, вакытында кирәк кадәр азыгын бирде.

Соңгы елларда Һашимовка хуҗалыгын киметергә туры килде: ул артык хайваннарның кайсын кая сатты, кайсын уртакка асрарга бирде. Шуңа күрә

Салахка эш калмады. Әнвәр: «Бу елларда бит әле кеше тота башласаң, кулак-фәлән диярләр», — дип, Салахка икенче бер эш — көтүчелек эшен табып бирде. Көтү көтә башлагач та, Салах, иске гадәте буенча, һәр чәршәмбе кич Әнвәрләргә бара иде.

Кич була. Әнвәр Кашимов чәршәмбе базарыннан кайта. Ак күбеккә баткан туры айгырны, туарып, баганага бәйләп куялар. Әнвәр кул сумкасы эченнән «кызыл баш»-ны чыгара. Бутылканы уч төбенә бик каты итеп бәрә. Улы Касыйм, өйгә йөгереп кереп, чәшке алып чыга. Салах белән Әнвәр тарантаска утырган килеш кенә кәгеп алалар.

Сабир да Әнвәргә хезмәт итте. Кыш көннәрендә, беренче баскыч мәктәптә укыган чакта, бер кабартма кисәге өчен ул аның сыеры асларын карап кайта иде. Мәктәп укытучысы Карип Мусин яхшы кеше иде. Ул бар кешедән битәр Сабирның тормышы өчен борчылды. Сабирда укуга дәрт барын, ярлы баласының эш белән күмелеп югалачагын сизеп, дүрт сыйныф бетергәч тә, аны җидееллыкка укырга урнаштырды. Бик нык ярдәм итте. Салах үзе малаеның ничек укыганлыгын, укып кем була алуы турында кызыксынмады. Тик Карипнең, аны күреп: «Малайны әрәм итмә, Салах абзый, аңардан яхшы кеше чыгачак», — дигән сүзләренә каршы, көлемсерәп кенә: «Әйдә укысын, укысын, аның бер эше дә юк», — дип җавап кайтарды. Әйтерсең үзе бик эшчән кеше иде. Ләкин бервакыт Әнвәр Салахка да: «Сезнең ни, кайтасыз да куышыгызда кырын ятасыз. Ә без, эшчән кешеләр, төн йокламыйча чабабыз...» — дип әйткән иде.

Кантон шәһәрендә ачылган «Союзкож» тире җыю бүлегенә агентлар кирәк, дигәч, Һашимов дус-иш аркылы анда да үрмәләп алды. Хәзер ул совет червонецлары белән эш итә. Тик аның зур бер кайгысы бар. Ул ничек кенә булса да червонецларны, совет банкларына биргәнче, үз бумаж-нигында калдыру юлларын эзли. Шуның өчен ул, тиреләр авыр килсен өчен, аларны тозлый торган булды. Чаттагы амбарының бер бүлмәсенә тоз китереп төятте.

Дөрес, тире җыю эшендә аңар байтак кына авырлыклар да кичерергә туры килде. Шуларның берсе аны аз гына теге дөньяга алып китмәде. Аның борыны янына кара башлы бетчә чыккан иде. Ул докторга барып күренгәч, алар аңа: «Тагын бер генә көн соңгарып килсәң, ычкынган булыр идең, синдә сибирская язва бит», — диделәр. Тимерне кып-кызыл булганчы кыздырып, шул бетчәне яндырдылар. Әнвәргә бик авыр булды... Ул үзен тәмугта янучы гөнаһлы кеше, докторларны зобанилар итеп сизде.

Шуннан озак та узмады, революция давылы аңарга ныграк кагылды. Кемдер совет агенты булып эшләүче Нашимовның элеккеге кулак икәнлеген «Союзкож» идарәсенә җиткерде. Аннан аны чыгарырга әзерләнделәр. Ләкин ул алар чыгарганны көтмәде. Шәһәрдән ашыгып кайтты да туры айгырны, болан күк зур көрән сыерын базарга алып барын сатты. Яшел калай түбәле олы өенең тәрәзәләренә аркылы такталар кадаклады һәм шул көннән һашимов Миләүшәдән чыгып сызды. Беркем дә аның кая китеп югалуын белмәде һәм кирәк дип тә тапмадылар. Шәһәргә килеп, ул күн заводына эшкә керде.

Билгеле, авылдан килгән Кашимов заводта яхшы урынга урнаша алмады. Хәер, ул үзе дә өмет итмәде. Аңар чимал складына мөдир булырга тәкъдим ясадылар. Ул никтер моңа күнмәде. Пычраграк булса да, көлләү цехының мөдире булырга ризалык бирде һәм шунда эшкә урнашты.

Менә бүген дә Кашимов, үзенең кыска брезент пин-жәген киеп, эшчеләрнең эшләүләрен карап йөри. Чанга берьюлы күп тире салып юдырмый, чиста эшләнсен өчен болгаткалап куярга куша. Күн заводының бик күп бүлекләре бар. Нәр бүлегенә кереп карап чыкканда, көн сизелмичә үтеп тә китәр...

Чимал склады белән янәшә көлләү цехы сузылып киткән. Аның калай вентиляторлары бертуктамый зыр-лап әйләнеп торалар. Чөнки көлләү цехында һава башкаларга караганда начар була.

Ишектән кергәч тә, борынны ярып, әчкелтем бер ис аңкый. Барабаннар бертуктамый шаулап су чәчрәтеп әйләнәләр. Алардан чыккан тавыш машиналардан чыккандай тоела.

Складтан вагонеткаларга төяп китерелгән тиреләр юешләү чаннары тирәсендә өелеп чират көтәләр. Бетон идән төрле пычраклардан таза, чөнки аяк астына түгелгән су идән астындагы шакшы суларны читкә чыгару трубасына — канализация челтәренә барып тоташа. Тире юешләү чаннары идән уртасында калкытып эшләнгән. Складтан китерелгән пычрак тиреләрне шул чаннарга ыргыталар. Трубалар аша чаннарга салкын су килә. Ул трубалар аша китерелгән пар белән җылытыла. Тире шунда җеби, барлы-юклы йонына ябышкан пычраклар шул суда юылып калалар. Аннан тирене бер кат алып саркыткач, тагын берничә кат юалар.

Һашимов эшчеләргә төрле күрсәтмәләр бирә, җитеш-сезлекләрне әйтә.

Тиредән чыккан йонны, кәрзиннәргә төяп, киптерү бүлегенә таптыйлар. Һашимов бу бүлеккә дә күзен төшерә. Монда бер карт эшли. Ул бик еш кына тәмәке тартырга йөри. Еш йөрсә дә, ни өчендер Һашимов аңар сүз әйтми, белмим, картлыгын кызгана, белмим, картның шулай тәмәке тартуын кирәк таба. Бирედә Маруся исемле матур гына бер рус кызы да эшли. Тәмәке тарту бүлмәсенә бару өчен, картка көлләү цехы аркылы узарга кирәк. Һашимов, ул картның тартырга узып китүен күрүгә, йон киптерү бүлмәсенә ашыга. Ишекне ябып кергәч тә, як-ягына каранып, кеше юклыгын тикшерә. Марусяны эштән туктата.

— Тукта, Маруся, бабайлар да эшләп үлгән, эш беркайчан бетми ул, ә менә яшьлек үтә!

Маруся боргалана:

— Дөрес, иптәш Һашимов, дөрес, — дип, керле кулларын киеменең чабуына сөртә башлый.

Һашимов Марусяның ияк астын үзенең тупас бармаклары белән тота. Кыз каршы килми, кашларын сикертә, күзләрен уйната башлый. Алар онытылып

китәләр. Ул, үзе дә сизмәстән, Марусяны кочагына ала. Кинәт ишек ачыла. Йөткерә-йөткерә, зур кәрзин күтәреп, йон юучы карт керә. Ләкин ул күрмәмешкә салына. Бердән, Һаши-мовтан курыкса, икенчедән, кыздан яхшысынмый. Ул керүгә, Маруся тиз генә сушилка янына бара, ә Һашимов тизрәк һәм күбрәк эшләү турында Марусяга күрсәтмәләр бирә башлый.

Бервакыт Һашимовка Сабир белән очрашырга туры килде. Шәһәрнең таш урамында очраган Сабир аңа аз гына кызганыч тоелды. Ул дәшми генә узып китәргә чамалаган иде дә, Һашимов үзе каршысына барды:

— Нихәл, авылдаш? Каян җил ташлады? Ни эшләп йөрисең?

— Эш эзлим. Ә син кайда эшлисең?

Һашимов үзенең күн заводында эшләвен Сабир-дан яшермәде. Шулай да күн заводын яманлап сөйләп китте:

— Һич рәтләре-чиратлары юк, акча әз төшә, эшчеләре качалар...

Һашимовның Сабирны икенче күрүе күн заводында булды. Ул складтан вагонеткага тире төяп маташа иде. Һашимов бу юлы инде аның янында сырпалана башлады.

— Нигә мин эшли торган цехка кермәдең? Авылдаш булгач, акча ягын да рәтләгән булыр идем, — диде.

Сабир: «Ах, капкорсак, минем бу заводка керүдән шүрлисеңмени?» — дип уйлады. Ә Һашимов, эченнән генә: «Бетте. Сызудан башка юл калмады», — дип куйды.

Шулай да ул, йөзенә мөлаемлык чыгарып, Сабирга эндәште:

— Кереп-чыгып йөргәлә, авылдаш, мин менә шунда гына.

Җанлы газетта булган хәлне Һашимовка шул кичтә үк җиткерделәр. Ул өендә иде. Хәбәр ишетелгәнче үк, башын кыйшайта-кыйшайта, озак итеп нәрсәдер язды. Ахыры кулындагы каләмен кара савыты читенә куеп уйга батты: «Юк, бер вакыт килер, Һашимов, һичшиксез, баер. Иске байлыктан да уздырып, яңадан мал-мөлкәт җыяр, яңадан үз эшенә, тире җыярга тотыныр. Менә бу завод тиреләре Һашимов кулында булсыннар иде, ул аларны кая озатырга, ничек акча табарга белер иде». Бу уйлар аны һәр көнне диярлек шулай йөдәтәләр иде.

...Уйларын бүлеп, кемдер тәрәзәгә чиртте, Һашимов куркып китте. Ул ишек ачарга чыкты. Рәхим икән.

Рәхим ишектән керү белән әйтеп салды:

— Әй пешерделәр дә соң сине!

— Кайда? — диде Һашимов, үзе агара төште.

— Җанлы газетта. Син генә дип, син генә түгел инде: цехыбыз белән...

— Нишләп? Ни җитмәгән тагын аларга? Рәхим сөйләп китте:

— Промфинплан бервакыт тулмый, диләр, комсомоллар тәмәке тарту белән вакытларын үткәрәләр, диләр, цех мөдире зур портфель, зур трубкадан йөрүне генә белә, диләр, комсомолларның ярыш ачуына каршы төптә, диләр...

— Ялган бу, ялган, мин ник каршы булыйм.

— Шулай диләр бит.

Аның сүзен бүлеп:

— Юлбашчысы, юлбашчы кем? — диде Һашимов. Аның күзләрендә ачу чаткылары ялтырый иде.

— Разия Баязитова, — диде Рәхим. Аннары арттырып та куйды: — Мин ярыш оештырыйк дип бик күптән әйттем бит. Ә син..

**Разия Баязитова**

Разия, бюродан кайтып, үз бүлмәсенә керде. Бүлмә тын, тик сәгать кенә келт-келт йөри. Тәрәзәдән ай нуры кереп, бүлмәнең яртысын яктырткан. Мич сырында мәче мырлый.

Разия, ут кабызмый гына, караватына барып утырды... Ул хәзер Сабир турында уйлый, аның белән беренче очрашуны күз алдына китерә. Менә Разия цехлар саен җанлы газетка теләгән кешеләрне язып йөри.

Шадра, дулкынланып торган саргылт чәчле бер егет:

— Нәрсә соң ул җанлы газет? — дип сорый. Разия аңлата. Теге егет:

— Алай булгач, мине дә яз, — ди.

Аннан соң аның иптәше, кара чәчле, каратутлы, оял-чан гына егет тә:

— Мине дә яз, мин Вафа Абдуллин, — ди. Тора-бара җанлы газета өчен бик тә файдалы кеше

булып чыга. Ул завод эчендәге вак-төякләрне күрә белә, шуларны җырга да сала.

Аннары Разия Салахов кичергән тормыш авырлыкларын үзенең күргәннәре белән чагыштырып чыга. Аңар Салахов күргән авырлыклар инде таныш, бар да аның аша үткән кебек күренәләр.

Ул белә башлаган авырлыкларның очы дәһшәтле ачлык елдан килә. Шул елдан башлап беренче кабат, бала күңелендә яшь агачка үткен пычак белән киртләп эз калдырган кебек, ярлылык тормышы гомер буена сөйләрлек эз калдыра.

Ачлык ел.

Көтүче Баязит карт авылда беренче булып ачыга башлый. Аның ике баласы, мич башында иске чүпрәкләргә төренгән килеш, җылылык эзлиләр. Ә җылылык юк.

Баязит ачлыкка бирешә башлый. Ул чыдый алмый, азак чиккә җитә... Сәкедәге мендәргә капланып үксеп-үксеп елый башлый. Күршеләр Чыгыш тавыннан майлы кара балчык алып кайталар. Үзалдына каралып, майланып торган бу балчык әти кешенең соңгы азыгы була. Иртәгесен балалар мич бантыннан гына юкә чыптага төрелгән үлекне кемнәрнеңдер алып чыгуларын күреп калалар.

Күп тә узмый, ана да ахыр чиккә җитә.

Авылда шатлыклы хәбәр тарала: ачлар өчен авылга кукуруз кайтарыла. Әнисе, үзенең кечкенә чанасын тартып, кукуруз биргән җирдән паек алып кайта. Күп тә үтми, балалар өчен ашханә ачыла. Ләкин бу шатлыкны әнисе генә күрә алмый. Әти-әнисез калган Разинне авылга килгән бер кызылармеец шәһәргә алып китеп балалар йортына бирә.

Разия ул вакытларны төштәге кебек кенә хәтерли. Еллар үтә, ул инде үсмер кыз булып җитешә. Аңар: «Син зур инде», — диләр. Аны балалар йортындагы бер иптәше белән шушы күн заводына урнаштыралар.

Кайвакыт сүз чыга. Егетләрнең кайберләре: «Юк, имеш, син теләсәң нишлә, табигать барыбер ул сине җиңә. Син үз гомереңдә кемне дә булса берәүне яратырга тиеш...» — диләр.

Разиячә бу дөрес түгел.

«Дуслыкмы, иптәшлекме?» соравы аның үзенчә, Разиячә чишелә. Ул барысы белән дә дус, барысы белән дә иптәш, үз сыйныфы кешеләрен тигез ярата. Шуңа күрә аңар башка беркемне дә алардан — шушы сыйныф кешеләре эченнән аерып алып яратмас кебек.

Бәлки, ул Сабирны яратадыр? Юк, бу андый ярату түгел. Бу ярату иптәш кызларны, рамочныйдагы бригада членнарын яратудан берни белән дә аерылмый шикелле...

Көлләү цехында эшләүчеләргә ярыш ачу дәрте кызлар арасында күптән йөри иде инде. Шулай да ул бертөрле калыпка салынып оешып җитмәгән, шуны

кузгатырга, шуны алгы планга куярга кирәк. Көлләү цехында эшләүче Рәхим кергәч тә, кызлар берәм-берәм аңар үзләренең күңелләрендә йөргән ярыш пунктларын әйтеп чыктылар:

— Без менә акчабызның ун процентын һәр айны саклык кассасына калдырабыз, сез дә шулай эшләгез!

— Без эшләп чыгаруны йөз процентка җиткерәбез, брак, прогулның затын да калдырмыйбыз, сез дә шулай эшләгез!

Соңгысы Рәхим өчен әзрәк җайсызрак булды. Комсомол Рәхим кепкасын бөтенләй алга таба шуыштырды да, башын кашый-кашый:

— Бусы белән тезгә сугасыз, малай, Разия, — дип куйды.

Болай Рәхимгә әйтеп чыгару гына ярыш ачу түгел иде, аны бөтен завод белерлек, һәр цех ишетерлек итеп әйтәсе иде.

Кызлар шуңа әзерләнделәр.

Разия рамочный цехта эшләүче кызларның бригадиры иде. Кайчандыр аңа, авылга кайткач, шәл бәйләү эшен күрергә туры килде. Йортка яңа гына төшкән алсу битле, кирәк булса да, кирәк булмаса да һәрвакыт беләкләрен сызганып йөри торган яшь килен нәзек кенә итеп эрләгән бәрән йонынннан аруга ябынып өчен шәл бәйләгән иде. Бәйләп бетергәч, шәлне агартып юдылар, сыктылар; киптерер өчен, шәлнең һәр теле саен берәр кадак кагып, тактага тарттырып куйдылар. Менә шул шәл кадаклау аларның хәзерге эшләренә бик охшый иде.

Рамлау бүлеге дә заводның бантка цехлары кебек: тәрәзәләре якты, диварлар төрле лозунгларга бизәлгәннәр. Эшләүчеләрнең барысы да хатын-кызлар, шуңадырмы аеруча пөхтәлек күренә. Кулларына кечкенә келәшчәләр тоткан бу хатыннар, тирене өстәл тактасы сыман такталарга тартып, пробкаларга охшашлы пешкаларны тиренең кырыена кагалар.

Ярышны көлләү цехына белгертү көне җиткән иде.

Разия тәнәфес вакытында язылган договорны укып китте:

— Иптәшләр, тыңлагыз, теге әкәмәтләрне ярышка чакырабыз. Мин монда яздым, калганнарын өстәрбез. Укыйм:

«Без, Ленин исемендәге күн заводы эшчеләре, рамлау цехындагы Баязитова бригадасы, биш елны дүрт елда тутыруның барлык җаваплылык ларын искә алып, удар бригадага оешып һәм социализм ярышына чыгып, партия тарафыннан алга куелган бурычларны эшчеләр сыйныфының батырлыгы белән үтәвебезгә хөкүмәтебезне ышандырабыз.

Көлләү цехындагы иптәшләрне үзебез белән тиңләшергә чакырып, түбәндәге шартларны һәр ике якның да үтәүләрен сорыйбыз:

1. Эш көнен тыгызлау, бракларны бөтенләй юк итү, прогулларны ясамау (кирәксез сөйләшүләр, тәмәке тартуларны бетерү Һ.б.).

2. Машиналар өстеннән шефлык алу, эш кораллары белән сак эш итү, кадакларны кирәкмәгән урынга тотмау, аларны идәнгә ташламау.

3. Бирелгән эш бәяләрен удар хезмәт нигезендә түбәнәйтергә тырышу, шуның белән хөкүмәткә әйбернең эшләнеп чыгыш бәясен төшерергә ярдәм итү.

4. Айлык акчабызның 10% ын саклык кассаларында калдыру, моның белән илнең индустрияләшү фондына ярдәм итү.

5. Эшләп чыгаруны 100% ка җиткерү, үзебезнең цехтагы булган сәбәпләр аркасында башка цехларга һичбер өзеклек тудырмау.

6. Кирәк булган чакта ял көннәрдә дә эшләү».

— Разия, син бит тегеләр турында бернәрсә дә язмагансың?

— Кемнәр турында?

— Администрация турында.

— Нинди тәкъдимнәр бар соң?

— Мә яз берне, минекен яз әле: киләшчә белән чүкечләр һәрвакыт булып торсыннар.

— Булды, — диде Разия.

Аннан соң Разиягә кызларның тәкъдимнәре бер-бер артлы ява башлады:

— Ә кадрлар турында?

— Безнең цехка иң кимендә биш өйрәнчек алырга кушарга.

— Тагын?

— Эшкә килүне һәм эшләп чыгарган продукцияне нык исәпкә алу турында...

Кызлар онытылып озак утырдылар, ләкин берсенең исенә төште:

— Иптәшләр, аш ашамый калабыз.

Кызлар бер-бер артлы, ашыгып, договорга кул куйдылар. Иң соңыннан договорны эш киеме кесәсенә бөкләп салган Разия җиңел генә, баскычлар аша түбәнгә, ашханәгә таба атлады.

Разия иртәгесен договорны көлләү цехына алып керде. Бер генә минутка алар Кашимов белән күзгә-күз очраштылар.

Ул, муенын суза төшеп:

— Кем кирәк иде сезгә, туташ? — диде.

— Рәхим кайда?

— Шундадыр, — дип, Һашимов цехның икенче башындагы бушлыкка кулы белән күрсәтте.

Һашимов Разиянең Рәхим янына киткәнен һәм алар-ның бөтен хәрәкәтләрен җентекләп карап торды. Менә Разия кесәсеннән нindидер бер язу чыгарып укыды. Аннан язуны Рәхим үз кулына алды һәм бер кат карап чыкты. Алар, нәрсә турындадыр озак кына сөйләшкәч, кул бирешеп аерылыштылар.

Кыз китәргә җыенгач та, башын яктыга таба борып:

— Кара, озаклама, — дип куйды.

һашимов, постка куелган кирәксез сакчыдай, килбәтсез зур аяклары белән идәнгә шап-шоп басып, әрле-бирле йөрде.

Яңа кергән кызны Нашимов, билгеле, белә иде. Чөнки күптән түгел булып узган җанлы газетада Һашимовны зур трубкасы белән күрсәткәннәр иде. «Күнче» газетасында да Ьашимов турында чәнечкеле мәкалә басылып чыкты. Имеш, ул вакытында башка цехларга кирәкле чималны өлгертми. Удар бригадалар оештырырга комачаулый. «Тагын мине газетага язарга кергәндер әле бу кыз, — дип уйлады ул. — Юк инде, бу юлы язу белән генә калмас, төрле материал җыя башласа, бөтенләй заводтан сөрдерер».

Һашимов шуңардан курыкты.

Ул, йомшак кына басып, Рәхимгә таба юнәлде. Башта аның эшләгәнен карап торды. Аннан, җай чыккач, сүзен башлады:

— Нишләп йөргән була ул кыз тагын? Рәхимнең нигәдер белгертәсе килмәде:

— Юк, болай гына.

Ьашимов Рәхимнең нечкә хисләрен бел мәкче булды, ахры, бармагын өскә күтәреп:

— Кара, син кызлар белән бик шаярма! — дип куйды. Рәхим елмайды гына. Аңар Һашимовның тел төбе бик

аңлашыла иде.

Иң оешмаган һәм оештыру өчен җайсыз да булган цех көлләү цехы иде. Чөнки монда, бердән, сезонниклар, кара эшчеләр эшләсәләр, икенчедән, цех мөдире Һаши-мов күбесенчә эшкә аяк чалып килде.

Сәгать дүрт тулды.

Гудок эшчеләргә өйләренә кайтырга хәбәр бирде. Завод капкасына сыеша алмыйча, эшчеләр төркем-төркем булып эштән агылдылар. Һашимов та, начар тиредән тегелгән зур портфелен күтәреп, брезент пинжәгенең төймәләрен каптыра-каптыра, цехтан чыкты.

Икенче смена килде.

Цехның бер буш почмагына беренче сменада эшләүчеләр җыелдылар. Рәхим сүз башлады:

— Иптәшләр, эш менә нәрсәдә, сезгә билгеле хәл инде ул: безнең цехка бантка цехларның да язмышлары бәйләнгән. Күрәсез, безнең цехта эш аксап бара. Складтан килгән тиреләр әле дә булса чират көтеп яталар... Болай булганда, без үзебезнең цехның промфинпланын тутырмау гына түгел, завод промфинпланына да зыян китерәчәкбез. Менә минем кулда рамлау цехында эшләүче кызларның договорлары бар. Алар безне үзләре белән ярышка чыгарга чакыралар.

Ул бая Разин белән тикшергән договорны укып чыкты. Беркем бер сүз дәшмәде. Бар да сөйләр сүзләрен каядыр яшерделәр.

— Йә, нишлибез? — диде Рәхим.— Хурлык бит, кызлардан да артта калдык, егылып үләрлек хурлык...

Иптәшләре белән озак уйлашып торганнан соң, ул тагын башта әйтелгән сүзне кабатлады:

— Йә, нишлибез? Арадан берәү:

— Билгеле, кабул итәбез! — диде.

— Юк, алай тикшерми-нитми генә кабул итүдән файда юк. Безгә үз пунктларыбызны әзерләргә кирәк.

Берәү каршы төште:

— Өлгерербез әле, башта чандагыларны карарга кирәк.

— Юк, аларны карап кына калырга ярамый, буксирга алырга, үзләре өлгерә алмаган җирдә ярдәмгә килергә кирәк.

...Договор кызларныкы төсле үк башланды. Беренче пункт заводның барлык цехлары өчен дә мөһим булган чималны цехларга вакытында өлгертү,

эштән тукталуларны бетерү иде. Аның артыннан башка пунктлар тезелеп киттеләр...

Иртәгесен Рәхим Разия белән тагын очрашты. Алар договор язган кәгазьләрне алыштылар.

Цехтагы кызлар да договорда язылганнар белән кызыксындылар:

— Кая, әки, ата ялкаулар ни язган булганнар? Укып чык әле!

Разия договорны укып чыкты. Укып чыккач та, бер кыз:

— Бу безнеке төсле үк булган ич! — дип кычкырып җибәрде.

— Барыбыз да бер теләк өчен көрәшкәч, бер булмый, ничек булсын соң! — диде икенче кыз.

— Мин, әки, төкермәсләр дә дип уйлаган идем.

— Нишләп алай итсеннәр, үзебезнең иптәшләр ич алар! Рәхим үпкәләгән сыман әйтеп куйды:

— Ай-яй, Фатыйма, «төкермәсләр дә» дип карарга бер дә килешми инде. Без бит Советның үги балалары түгел. Безнең дә сез янган теләкләр белән янасыбыз, коллектив алдында эш күрсәтәсебез килә.

— Юк, үпкәләмә тагын син, Рәхим, мин болай гына, шаярып кына.

Рәхим, терсәге белән өстәлгә таянган килеш:

— Әйдәгез, көч сынашкач сынашыйк инде, кем җиңәр,— дип куйды.

Кызлар, шатлыктан дәртләнеп, биегән сыман сикерештеләр:

— Без җиңәбез! Без җиңәбез!

**Җиңү көне**

Завод корпусының крепость кебек сузылып киткән җиренә зур тәрәзәләре белән механика мастерское килеп тоташа. Монда күмерләр нечкә ялкын телләре белән кызган тимерне ялыйлар. Тимергә тимер бәрелеп, үзенчәлекле музыка туа...

Заводта механика цехы зур урын алмый. Шулай да машина ватылса, электр уты белән берәр проблема килеп чыкса, тимердән берәр нәрсә эшләргә кирәк булса, меха-ническийга йөгерәләр.

Сабир белән Вафа да шушы цехта эшләде. Сабирга монда бик аз вакыт эшләргә туры килде. Ә Вафа һаман кеше белән аралаша алмады. Беренчедән, «кеше» дип карт тимерче Бориска әйтсәләр, икенчедән, мастер Селезневны шулай атыйлар.

Башкалар әле һаман кеше булып җитмәгәннәр. Аларның кеше булыр өчен әле байтак өйрәнәселәре, кулларыннан әле шактый тимерне үткәрәселәре бар.

Бер җыелышны Сабир әле дә булса онытмый: ничектер һәр цех саен промфинпланны үтәү турында эшчеләр гомуми җыелыш: алдында вәгъдә бирделәр. Иң соңыннан Борис та күтәрелде.

Ул салмак тавыш белән сөйләргә тотынды:

— Промфинпланны тутырыр өчен, ун сәгать эшләргә кирәк булса, ун сәгать эшлим. Минем цехтагы лар бар да шулай диярләр. Ял көнемне дә ял итмим — кирәкми. План тулгач — безнең бәйрәм! Аңлыйсызмы, план тулса, үзе безгә ял була ул...

Тыңлаучылар:

— Бүген Борис кәккән булырга кирәк, — диделәр.

Аның шундый гадәте бар иде. Эш алдыннан, кесәсеннән чыгарып, әз генә капкалый иде ул. Аның бу эшен цех-ташларыннан берәү дә «күрмәсә» дә, бары да белә иде. Юк, Борис ул көнне «ак»ның тамчысын да капмаган иде. Эчендә кайнаган теләкне, уйны, фикерне аңлаталар иде ул сүзләр.

Борис гомерендә мәктәп, уку дигән нәрсәне белмәде. Башта ул тимерчелеккә өрдерүче булып кына керде... Яшь Борис әкренләп югары баскычларга таба үрмәләде. Шулай да ул язарга өйрәнде. Кулына эләккән теләсә нинди китапның соңгы битенә кадәр күзеннән кичерде, шулай итеп, үзлегеннән белем алды.

Оешып эшләүнең иң беренче дошманы булып мастерскойда Борис санала. Ул менә, эшлик, ди, тырыша, башкаларга да тырышып эшләргә куша, ярышырга да каршы түгел, әмма аңар удар бригадалар төземәсеннәр, Борисны ударник итмәсеннәр, чөнки болар, аныңча, бар да формаль кебек күренә. Ул эштә үзенә хас «бунтарьлыкны» сайлап алды: кеше ялгыз гына тырышсын, аңар беркем баш булмасын, аңардан бертөрле җавап алмасыннар, аның өчен кануннар, кагыйдәләр, договорлар, пунктлар язмасыннар. Шуннан чыгып, Борис бригада оештыруга каршы...

— Оештырыгыз, мин каршы килмим, тырышып эшләрмен, әмма мине исемлеккә кертмәгез...— дип сөйли Борис.

Механический цех белән тимерчелек цехы бер корпуста урнашкан. Ишектән кергәч, әүвәл тимерчелек цехы. Тагын бер ишекне ачсаң, механика цехы башлана.

Кара-каршы куелган ике станокта яңа гына кара эшчедән күтәрелгән Сабир белән Вафа эшлиләр.

Әнә Селезнев, борын өстендәге кечкенә күзлеген алып, кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, күзлек пыялаларын сөртте. Болторез станогының әйләнүен мастер әйтерсең беренче кат күрде. Тимернең аяк астына төшүен ул озак карап торды.

Сабирга бу әллә ничек җайсызрак булып тоелды. Әйтерсең мастер аның эшеннән разый түгел.

Ләкин мастер берни дә дәшмәде. Авыз эченнән сызгырынып, китәргә бер-ике адым атлаган иде дә, кире килеп сүз катты:

— Салахов, син бездән китәсеңмени?

— Ие.

— «Светогрэожамы?

— Мин үзем китмим, җибәрәләр.

— Жалко, тиз төшенгән булыр идең. Менә разрятыңны арттырырга дип тора идем. Жалко... Ә үзеңнең китәсең киләме?

Сабир моңа ни дип тә җавап кайтарырга аптырады... Ике төрле аңлашырлык булсын өчен:

— Килсә дә, килмәсә дә, аңа бит карамый, — диде.

— Да, шулай шул инде. Шулай да, анда баргач, шушы эшкә керергә тырыш.

Ярыш авырлык белән булса да бу цехка да керде. Комсомоллар цех киңәшмәсендә ул мәсьәләне кузгаттылар.

Борис тагын каршы төшеп карады:

— Оештырыгыз, эшләгез, ләкин мин каршы. Мин эшкә каршы түгел. Мин эшне яратам. Мин бригадага керә алмыйм. Минем натурам аны күтәрә алмый. Мин үзем тырышырмын. Үзем генә.

Ике кеше, ике мастер бүген пычакка-пычак килделәр:

— Собраниеләрдә син бугаз ертасың!

— Мин бит үзем турында сөйлим, Сергей Николаевич, сөеклем. Эшлим, унике сәгать, унөч сәгать эшлим, но оешу миннән булмый. Натурам күтәрә алмый, аңлыйсыңмы син шуны, юкмы?

— Аңлыйм, аңлыйм кайсы гайкаң бушаганын, — диде Селезнев.— Француз ачкычы юк әле, тәрбия аласың бар әле синең, тәрбия аласың бар. Эшче җыры түгел бу, Борис! Син анархистлар җырын җырлыйсың. — Ул, ачуланып, йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты: — Аңламаган кешегә аңлатуы авыр да соң! — Аннары азрак басылгандай булды: — Син, Борис Петрович, алай анархист-ланма, син Совет властенда яшисең, үз иптәшләрең белән бергә бул. Син эшчеме?

— Ие, эшче.

— Син эшче иптәшләрең беләнме?

— Әйдә, андый мәсьәләгә кермә әле син. Оештырыгыз, мине язмагыз, мин язылмыйча гына эшлим.

Күп сүзләрдән соң тимерчеләр — үзләренә, механический цех үзенә берәр бригада оештырдылар.

Эштән чыгышлый, Сабир белән Вафа сүзгә килделәр:

— Вафа, ике станок белән эшләп булыр идеме? — Сабир шундый сорау белән Вафаның йөзенә карады.

— һәй, кит, малай, эштән чыгарсың.

— Минем алай да сынап карыйсым килә әле.

— Кит инде, юк белән саташма...

Рамочныйдан бер көтү кызлар чыркылдашып, йөгерешеп чыктылар. Шулар арасында Разия дә бар иде. Ул Сабирга кычкырды:

— Сабир, Сабир, сиңа бер сүз әйтәсем бар.

Сабир Разингә таба китте, Вафа белән сөйләшкән сүз өзелде.

— Әйдә аулакка барыйк, Разин, диген, Сабир! — дип, кызлар арасыннан берәү кычкырды.

Барысы да шаркылдаштылар.

Алар бер читтән атладылар. Разин сүз башлап китте:

— Сабир, менә нәрсә: Нашимов дигән кеше Миләүшәнеке икән, син аны беләсеңме?

— Ник белмим, ул безнең авылныкы шул.

— Ул нинди кеше?

— Төскәме?

— Юк, чыгышы ягыннан. Революциягә кадәр кем иде ул?

— Бер тирече иде шунда. Безнең әти дә, мин дә аңарда хезмәтче булып тордык.

Ул, Сабирга үпкәләгән шикелле карап:

— Ник син аны башта ук әйтмичә йөрдең? — диде.— Менә көлләү цехының квартал заданиесен үти алмавы нәрсәдән икән, эх! — Аннары ул иреннәрен кысты. — Ярый, мин аны кирәкле урынга җиткерермен.

— Мин бит аны беләләр дип торам. Нәрсә, ул белгеч бит...

Сабир үзен акларга теләде, ләкин үз сүзеннән үзе кызарды.

* * *

Һашимовны завкомга чакырдылар.

Завком бүлмәсе башка бүлмәләрдән әллә ни аерылмый. Аның диварларында, башкаларныкындагы кебек, бүгенге көрәшнең лозунглары күренеп торалар. Диварда Ленин, Сталин рәсемнәре. Уртага өстәл куелган. Анда завком председателе Һадиев утыра.

Ишектән зур трубкалы, брезент киемле берәү күренде:

— Исәнмесез!

— Исәнме!

— Сез мине чакырттыгыз?

— Ие. Сезнең белән бераз сөйләшеп аласы бар иде. Утырыгыз.

Һашимов өстәлгә каршы торган урындыкка килеп утырды.

— Нашимов иптәш, сезнең цехта план ничек, бүген бит егерме алтысы?

Завком, бер күзен кыса төшеп, шул сорауны бирде.

— Ничек дип сорыйсыз, Һадиев иптәш, безнең һәммә адымыбыз сезгә билгеледер инде дип уйлыйм: химикатлар җитешми. Дөрес, чимал бар, ләкин эшче көче әз. Социализмча эш методларын әле дә булса үзләштереп җиткерә алмыйбыз... Аннан соң, онытмаска кирәк, көлләү цехының эш шарт ларын үзегез беләсез.

— Син объектив сәбәпләр артына качма, конкрет итеп әйт, нәрсәләр җитешми?

Ул өстәл тартмасыннан зур блокнот чыгарды да Һашимов әйткәннәрне яза башлады:

— Химикатлар җитешми. Лабораторияне кысарга кирәк. Булды.

— Бригада юк.

— Гафу итегез, сездә бит бригада бар: Рәхим бригадасы.

— Белмим. Алар миңа әйтеп эшләмәделәр.

— Гаҗәп инде, бер-берегезне белешми эшлисез. Ярый алайса, бригаданы ныклап юлга салырга.

— Эшче көче җитешми...

— Без артык эшче көче ала алмыйбыз. Ул вакытта өстәмә расходлар, — диде Надиев, карандашын өскә күтәреп. — Менә болай итсәк, товар бәясе үсәчәк. Эш көнен тагын да тыгызландыру турында көрәш алып барырга. Беттеме?

— Иң зурлары шулар.

— Инде хәзер әз генә үзегез турында. Сез бит әле, ял-гышмасам, Миләүшәнеке буласыз?

— Ие, шул авылныкы булам.

— Сезнең авылдагы көнкүрешегез ничек иде?

— Урта хәлле крәстиән. Үзем Советка тире җыядыр идем.

— Батрак тоттыгызмы?

— Юк, мин үзем тотмадым. Минем бер эшкә яраксыз карт әти бар иде. Без аның белән бер өйдә: ул югарыда, мин түбәндә тордык. Миңа нишләп батрак кирәк булсын үземнең бу беләкләрем бар чакта...

Ул беләкләрен күрсәтте.

— Ә заводка нинди язу белән килдегез?

— Нинди язу белән килим, революция башыннан Советка тире җыйдым. Бервакыт лишун булганым юк. Язулар күп минем, әле менә монда да бар. - - Ул, ашыгып, эчке кесәсеннән бумажнигын тартып чыгарды: — Менә карагыз: бусы «Кожсоюз»да тире җыйган өчен бирелгән.

Председатель, тәмәкесен тартып, язуны караштырга-лады да:

— Сез бит, батрак тотмадым, дисез... Монда эшләүче Салахов сездә батраклыкта эшләгәнен әйтеп тора.

— Дөрес, Салахов эшләде. Тик ул миндә түгел, әтидә эшләде.

Аларның сүзләре бетте. Завком председателе Наши-мовка үзе хакында тагын өстәмә документлар табарга кушты.

Ул бүлмәдән чыкты һәм баскычка таба юнәлде. Баскычтан түбән төшү аңар әнә шул хәзерге тоткан урыннан — түбәннән түбәнгә таба төшү кебек күренде...

* * *

Бүген белдерүләр эленә торган тактада кызыклы гына бер мәгълүмат бар иде.

*«Кем ала?*

*Ашыгыгыз! Ашыгыгыз!*

*Айның, азаккы көннәре якынлаша. Комсомол ячейкасы завод күләмендә үзенең промфинпланын алдан тутырган цехка кучмә байрак бүләк итәчәк. Бар цехлар да кучмә байрак өчен көрәшкә!»*

Клуб ишегеннән кергәч тә иң алдагы витринага эре хәрефләр белән шул белдерү язылган иде.

Менә ишек шыгырдады. Ишектән Разия белән бер иптәш кызы керде. Алар витринага якынлаштылар. Разия белдерүне кычкырып укып чыкты да:

— Алабыз, үзебез алабыз! Беркемгә дә бирмибез! — диде.

Янындагы иптәше сорау бирде:

— Бүген ничәсе, егерме бишеме әле?

— Егерме бише.

— Ә безнең план ничә процентка тулган?

— Туксан икегә җиткән инде.

— Алай булгач, арттырып үтәргә була. Алар алга атладылар.

Ишектән Вафа белән Сабир да уздылар. Алар да белдерүне укыдылар:

— Бездән ычкыныр, Сабир, булмас безгә...

— Ник алай? Биш көн тырышып карарга кирәк. Әйдә, эштән соң калып эшләү тәкъдимен кертик.

— Ярый шул.

Алар да алга атладылар.

Иң ахырдан Рәхим килеп керде. Аның да күзләре белдерүгә төртелделәр. Укыган саен, ул үзендә бертөрле уңайсызлык, төшенкелек сизә барды. «Бәлкем, булыр әле, тагы көч куеп, биш көнне эшләп карарга кирәк», — дип уйлады ул. Аның күз алдына юешләү чаннары алдында тау-тау булып яткан тиреләр, Нашимовның химикатлар юк дигән булып эшкә аяк чалуы, тагын башка шундый нәрсәләр килеп басты.

Инде белдерүгә иптәш булып аның өстендә янган электр лампасы гына калды...

Числоның беренче көне иде.

«Күнче» газетасы бүген көндәгедәй ике тапкыр зуррак булып чыкты. Өйләгә ашка утырган эшчеләргә ашханәдә аны таратып чыктылар. Газетаның башында ук «Комсомолның күчмә байрагын рамочный алды, киләсе айда башка цехлар байракны рамочныйдан алырга тырышсыннар. Рамочный, җиңүеңне ныгыт, ярыш байрагын түбән төшермә!» дигән сүзләр буйдан-буйга сузылып ята. Рамочныйда айлык заданиенең егерме сигезенә 100% тулганлыгы, каршылау планының 10% ка үтәлгәне әйтелә. Көлләү цехын тагын сүгәләр. Ул «Объектив сәбәпләр астына капланып» дигән мәкалә утлы, чәнечкеле сүзләр белән башлана.

Механический цехта план 95% ка үтәлгән. Ул цехка багышланган мәкаләдә тимерче Борисовка бик каты эләккән. Механика цехы турында түбәндәгеләр дә әйтеп узыла: «Механика цехында да уңышлар юк түгел, комсомоллар тарафыннан кертелгән ударчылык цехны кузгатты дияргә кирәк.

Комсомол әгъзасы Салахов производствоның алдынгы батыры икәнлеген эштә күрсәтә алды. Ул берүзе ике болторез станогы белән эшли башлады. Шуның аркасында механическийда алга китеш бар...»

Иң кызыклысы — рәсемнәр. Менә алдан аэроплан очып бара, аңар кызыл яулык бәйләгән бер кыз утыртканнар да «Рамочный» дип язганнар. Аның артыннан автомобильдә дубильный цех бара, аннан, утырып, «анархист» Борис дыңгырдавыклы юлдан чаба. Иң ахырдан гына берәү озын киемнән, зур мыеклы, килбәтсез зур портфель тоткан, авызындагы зур трубкасы паровоз морҗасыдай төтен чыгарып бара. Үзе ишәккә атланган. Тегеләр артыннан калышмаска уйлый. Ишәккә атланган кешенең Һашимов икәнлеген фамилиясен язмыйча да һәркем белә.

Нашимов теш арасына кысылган ит кисәген шырпы белән чыгарырга маташканда, аңа да газета китереп бирделәр. Ул газетага баштанаяк күз йөртеп чыкты. Бигрәк тә аны үзе хакындагы мәкалә һәм рәсем көендерде. Анда болай язылган иде:

«Көлләү цехы мөдире һашимов элекке вакытта тире җыючы, революциядән соң да батрак тоткан, кеше көченнән файдаланган. Хәзерге вакытта эшче көче җитми дигән булып эш көнен тыгызламый, химикатлар сылтавы белән чималны озак яткыра. Үз цехында эшләүче бригада барлыгын да белми. Объектив сәбәпләр астына поса...»

Һашимов газетаны дүрткә бөкләде дә, редактор янына дип, рәхимсез язган мәкаләгә каршы үзенең документлар теле белән каршылык күрсәтә аласын уйлап, ишектән чыкты.

Редактор аны салкын гына каршы алды.

— Сез, иптәш, миңа урынсыз бәйләнгәнсез бит.

— Безгә мәкаләне завкомнан бирделәр, һәрхәлдә, без завкомга ышанабыз.

— Соң бит менә бу документлар?

— Ә батрак тотмау турында бармы? — Анысы юк.

— Менә шунысын табып китер син миңа.

— Ник, анысы да була.

Һашимовта ике кешегә ачу туды. Аның берсе — Ра-зия, икенчесе Сабир иде. Сабир бөтен нәрсәне Разиягә сөйләп биргән. Тегесе аны завкомга җиткезгән. Разия беркөн, цехка да кереп, Рәхимнән материал алып чыкты.

Һашимов, Сабирны алдан ук очратып: «Минем турыда күп сорарлар, син берни беләсе булма, авылдаш», — дип әйтеп тә куйган иде. Малай күнгән иде дә бит, ә хәзер менә барысын да сөйләп ташлаган. Бу ике кешедән, ничек кенә, кайда гына туры килмәсен, үч алырга уйлады ул. Хәзер шуңа планнар да кора башлады. Базар көнне, «документлар» җыярга дип, Миләүшәгә кайтып китте...

**Бүгенге кыенлыклар**

Бюро сайлаулары үткәрелде.

Партячейкадан беркетелгән Шаһи абзый бу сайлауларның нинди әһәмиятле икәнлеген секретарьдан соң тагын бер кат кабатлады. Җыелыш шуңар күрә дә кандидатураларны бик озак тикшерде.

Сабирны да бюрога сайладылар.

Разияне дә сайламакчылар иде. Моңар Сабир һәм башкалар каршы чыкты:

— Нәрсә һаман бер кешене җигәсез: үз цехында производство киңәшмәләрен алып баручы ул, җанлы газетта юлбашчы ул, җитмәсә, комсомол линиясе буенча, хәзер эштән дә туктатып, үзен укытучылар курсына мобилизовать иттек.

Вафа бу җыелыштан көнчелек утына кабынып кайтты. Кайчандыр Миләүшә мәктәбендә алар әүвәл Сабир белән бер партада утырып укыдылар. Аннан Вафа бер сыйныф югары күтәрелде, Сабир сыйныфыннан күчә алмады...

Ә хәзер Сабир күтәрелә. Аның күз алдында шадра битле, зур соры күзле, саргылт бакыр чәчле Сабир түгел — кепкадан, кулына күн портфель тоткан, кирәкмәгән урында артык сүзен дә ычкындырмый торган Сабир булып күренде.

Ну җыелыштан соң байтак җыелышлар булды, ләкин Вафа очен анда бер генә дә кызыклы мәсьәлә каралмады, тикшерелмәде. Имеш, ударчылык турында мең тапкыр чәйнәлгән бер балык башы бүген тагын мең дә беренче кат чәйнәлә. Социализм, киләчәк белән кызыктыру... ә хәзерге тормыш турында сөйләшү кайда? Товар юклык, тормыш авырлыгы мәсьәләләрен нигә көн тәртибенә куймаска? Нигә аларны эшчеләр массасы алдына чыгарып тикшермәскә?

Вафа бу хакта озак уйлады, күптөрле фикер йөртте. Бу мәсьәләне берәр җыелышта чыгып әйтергә дә омтылды. Тагын курыкты да: оппортунист, контр диярләр, эштән куарлар дип шикләнеп калды...

Кич. Сирәк кенә утыртылган баганаларда фонарьлар җемелди. Вафа каядыр барырга җыенган иде. Вәлүк килеп керде. Алар икәүләп чыгып киттеләр. Вәлүк — ач яңаклы кеше. Ул сөйләргә, сөйләшергә бик ярата. Вафа белән дә бик озаклап сөйләшеп торгалыйлар.

Алар бакчага бармакчылар иде, ләкин юл өстендә пивной туры килде. Вафа анда керергә һич тә уйламаган иде, тик Вәлүк, әйдә кереп чыгыйк, дигәч, каршы килмәде.

Ишектән керүгә, борыннарына тынчыган, күңелне болгандыра торган ис килеп бәрелде. Ләкин тора-бара алар күнектеләр, исне бөтенләй тоймый башладылар... Алар чаттагы клеенка җәйгән бер өстәлгә килеп утырдылар. Юан официант сыра китереп бирде...

Вафага әнә шул ишектән керүе генә авыр. Шул бусаганы атлаганны кеше күрмәсә, иптәшләре сизмәсә, аның җаны тыныч, ә эчтә кем генә очрамасын, ул Вафа өчен куркыныч түгел. Чөнки ул кеше дә инде анда тикмәгә кермәгән — эчәргә кергән. Менә хәзер ул Вәлүк белән ялгыз. Аның тирәсендә комсомоллар да юк, промфинплан, удар бригада, ярыш дигән сүзләр дә комачауламыйлар. Кружкадагы сыра күбекләре берәм-берәм шиңә, шуның белән начар уйлар да югала бара. Ул башын күтәрә төште: «Мин нинди кешеләр белән утырам?» — дип уйлады. Үзенең табындашларын күздән кичерде: әнә бер чатта кепкасының козырегын кырыйга калдырып кигән бер сәләмә киемле кеше перчатка сатып йөри. «Кайдан булса да суккандыр», — дип уйлады Вафа. Чаттагы өстәлгә бер кеше башын куйган да гыр-гыр йоклый. Аны сыра ташучы юан урыс уята:

— Гражданин, биредә йокларга ярамый. Исерек каршы килә:

— Синең ни эшең бар, теләсәм — йоклыйм, теләсәм — эчәм, бу минем үз эшем.

Әнә берәү яшь кенә хатын белән эчеп утыра. Егете кызык нәрсә сөйли, ахры, чөнки алар икесе дә шаркылдап көлеп куялар. Яшь хатын, папирос төтененнән «балдаклар» очыра-очыра, егеткә текәлеп карый. Тышка чыга торган ишек янында берәү шыңшып-шыңшып елый...

Әнә ике авыл агае утыралар. Кыршаулы бүрек кигәне ара-тирә сирәк сакалын төзәткәләп куя:

— Колхозга кергәнче, Ваһап, кинәнеп калыйк әле, — дип хихылдый-хихылдый, бутылкадан сыра агыза. — Анда кергәч, сыра эчәргә ярамыйдыр?

Икенчесе, гайрәтләнеп:

— Кайтам да һәйбәтләп бер атны сатам да җибәрәм, бер сыерымны тотам да суям, аннан гына керсәм керәм,— ди.

Вафа аларны таныды. Алар авылдашлар булып чыктылар. «Черт алыр сезне колхозга...» — дип уйлады ул. Ләкин барып эндәшергә хурланды.

Менә ул караштыргалаудан туктады, ә Вәлүк үзенең сүзен һаман дәвам итә иде әле:

— Син, егет, китап укый-укый бозылган. Китап бит ул, иптәш, кешене бик боза торган нәрсә.

Вафаның Вәлүк сүзен тыңлыйсы килмәде. Чөнки алар бик мәгънәсез булып тоелдылар.

Вафа алдындагы бер кружка сыраны эчәргә тотынды. Сыра салкын иде, үзенең әрем тәме, боз кебек салкынлыгы белән тамакны туңдырып төште. Кинәт ул айнып киткән кебек булды. Табындашлары турында: «Бар да үләргә хөкем ителгән, юкка чыгарга тиешле халык...» «Мин кемнәр белән утырам?» дигән соравына ачык җавап бирелде кебек. Инде икенче сорау туды: «Мин нигә соң монда кердем?»

...Ул кружка төбендә калган сыраны ашыгып йотты да, кепкасын баса төшеп:

— Әйдә, Вәлиулла абзый, тайдык моннан! — диде.

* * *

Заводның капкасы гудоктан соң ун минут үткәч бикләнә. Соңга калучылар заводка керә алмыйлар.

Өй ишеген ябып чыкканда, Вафа үзләренең гудогын ишетте, шуңа күрә дә ашыгып, урыны-урыны белән йөгергәләп бара башлады, ләкин ул килеп җиткәндә, капка бикләнгән иде инде. «Капка төбендә тору яңа гына комсомолга кергән кешегә килешеп бетә торган эш түгел. Капка төбендәге сакчыдан никадәр генә ялынып сорасаң да, ул кертмәс», — дип, Вафа, монда торуның файдасыз икәнлеген сизеп, кире борылды... Менә кичә Вәлүк белән очрашмаган булса, аның боерыкларына күнмәгән булса, болай булмас та иде!

Димәк, бер прогул булды.

«Бу бит бер сәбәпсез прогул. Ничек сәбәп табарга? Иртәгә ни йөз белән цехташлар күзенә күренергә? Җитмәсә, вагонеткалар этеп йөртү эшеннән, кара эштән Сабир белән аларның икесен механический цехка күчергәннәр иде. Станок буш тора торгандыр...»

Бүлмәсенә кайтып кергәндә, ул Вәлүкне сүкте: «Йә имде, эт нәрсә, кич ялга каршы очраган булса...»

Оггэлдә яткан китапларның берсе күз угына эләкте. Ул, аныр уйларны онытып торыр өчен, бер китапны ачты. Ләкин укымыйча кире куйды. Караватына ятып торып, тәрәзәдән карый башлады. Кояш нурлары Якты күлнең өстенә төшкәндә, җәйге җил күл тирәсендәге камышларны әкрен генә селкетә. Электр станцасы салыначак урындагы эшчеләр кырмыскалардай кечкенә генә булып күренәләр. Аннан ул караватына сузылып ятты...

Вафа йокыдан торганда, сәгать унберне сукты. Өстәл өстендә баягы тәртипсезлек...

Баш авырта, әйтерсең ике чигәгә кечкенә чүкечләр белән бертуктаусыз бәреп торалар. Колаклар шаулый. «Барсам, йә эшли алмаган булыр идем», — ди Вафа.

Тәмәке төреп, шырпы кабызыйм дигәндә генә, бүлмә ишеген кактылар. - Кем бар?

— Мин. Ач әле, Вафа.

— Ә, син икәнсең, Вәлүк, менә сине каргап ята идем әле...

— Каргый торгансыңдыр дип килдем дә шул, — диде ишектән керүче, аннары куллары белән кесәсенә тыгылды: — Давай, баш төзәтеп алыйк, — дип, кесәсеннән бер «ак»ны тартып чыгарды.

Аның бу кыланышы Вафаның ачуын китерде:

— Хәл белергә керсәң, кесәңә «яшел елан» тыгып килмә син миңа!

Вәлүк гаҗәпсенде, кашларын сикерткәләде. Кичә генә рюмкаларны чәкештереп-чәкештереп эчкән Вафадан бүген шул сүзләрне ишетү аңар гаҗәп тоелды.

— Ә кичә ярый идеме? — дигән сорауны әйтеп ташлаганын сизми дә калды.

Вафа дәшмәде, урын күрсәтте.

— Әнә тегендә утыр да, төзәтсәң, үзең генә төзәт, — дип, кунакка артык әһәмият бирмәде.

Кунак бер мәлгә чыгып китәргә дә уйлаган иде, ләкин никтер туктады:

— Синең аркада, Вәлүк, бүген прогул ясадым әле.

— Син, энекәш, прогулдан курыкма, — диде Вәлүк.— Хәзерге эшче көченә аптырау заманында куркырга ярамый. Безне бит кая да алалар...

— Эш анда түгел, — диде Вафа.— Мин яңа гына комсомолга кердем. Яңа гына механический цехка, станокка күчерделәр.

— Ь.е! — диде Вәлүк, бутылканың астына каты иттереп сукты. Пробка, борчак кебек, читкә атылды. Баягы пычрак стакан кулга алынды, кесәсеннән бер баш суган чыгарды.

Вәлүк берүзе ныклап баш төзәтергә тотынды.

Вафага көн ифрат озын тоелды. Җәйге көннәр, хәер, болай да озын була. Эшсез торсаң, тагын да озын, үткәреп бетерә алмаслык булып күренәләр.

Менә кич җитсен иде. Вафа бу кайгысын һич булмаса Фатыйма белән уртаклашыр, Сабирдан үзенең станогының хәлен сораптыр иде. Ие, тизрәк кич җитсен. Юк, моннан соң Вәлүк сукмагына аяк басмас ул. Шулай үз эченнән генә ант та итте... Ул бүлмәсендә шундый җирәнгеч кешегә баш төзәтергә рөхсәт иткәненә дә үкенә башлады. «Хәзер берәрсе килеп керсә, икәү эчеп утыралар икән дип әйтәчәк» дип, Вафа әзрәк кенә шикләнеп тә алды.

Бәхетсезлеккә каршы, нәкъ шул вакыт тагын ишек шакыдылар.

— Ни хәлләр бар, Вафа? — дип, ишектән үк сораша-сораша, Сабир керде.

— Менә авырып торам, малай, һич хәл юк.

— «Яшел җылан авыруы» гына түгелме?

— Юк, каян килсен ди ул, эчмәгәч.

Сабир Вәлүк белән дә исәнләшкән булды. Яңа кешенең керүенә артык әһәмият бирмәгән сыман, Вәлүк өзелгән сүзен дәвам итте:

— Кичә әле берәү белән ызгышырга туры килде дә, шуннан бөтен нервалар кузгалды. Шуннан, давай, мәйтәм, берне алып кайтып, кабып ятыйм да, кызышкан каннар таралсын дип алдым. Каптым. Бере артыннан икенчене, икенче артыннан өченче... Каһәр бит ул, бер китсә китә. Ә бүген пахмил инде, ансыз булмый... Вафаны да кыстыйм да, якын да килми, авырыйм, гына ди...

- Мине Селезнев сорадымы? — диде Вафа.

— Юк, нишләп сорасын.

— Минем станок тик торамы?

— Мин аны җибәрдем. Менә дигән итеп ике станок белән эшләп була икән...— диде Сабир, шатлыклы тавыш белән.

Вафа урыныннан күтәрелде:

- Кит аннан!

- Әйе, зырылдап кына торалар.

Сабир, ашыгып, ачык тәрәзәдән нидер карады да:

- Ярый, Вафа, мин ашамаган бит әле, ашыгам, бүген җыелыш та буласы. Кил, — дип, ишектән чыга башлады.

Вафага авыр иде. Алай да ул Сабир артыннан:

Сорасалар, авырый, диген, — дип кычкырып калды.

...Вафа Вәлүктән читкә тайпылырга, эчмәскә, прогул ясамаска уйлаган иде. Ләкин сүзендә тора алмады. Шушы вакыйгадан соң ул тагын ике көн прогул ясады. Хәтта бер комсомол җыелышында иптәшләре тарафыннан аны шелтәләгән сүзләр ишетелә башлагач, ул трибунага чыгып гафу үтенәсе, үзенең гаепләрен танийсы урында сүгенергә тотынды. Болай ярамаганын үзе дә бик яхшы белә иде. Шулай да, үзе дә сизмәстән, баш иярга теләмәде. Хәтта бу мәсьәләгә һич тә бәйләнеше булмаса да, аны борчып торган ашау-эчү һәм башка шуның кебек нәрсәләр турында да сөйләп китте. Шулай итеп, партиянең бүгенге сәясәте дөрес түгел дигән сүзгә кадәр барып җитте.

Аңа бөтен уйларын әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр. Әле күптән түгел генә үзен комсомолга алган иптәшләре, кычкырып-сызгырып, аны трибунадан куып төшерделәр. Бу хәлдән ул кинәт тирләп чыкты һәм үзенең төзәлмәслек бик зур ялгыш ясаганын сизә башлады...

Аның эшен механический цехтагы комсомол ячейкасы бюросында да карап, комсомолдан чыгарырга булдылар.

Бу ячейкада секретарь Сабир Салахов иде.

**Көн нинди матур!**

Электр станцасының нигезен салу өчен кызу җир эшләре бара. Егермеләп җир казучы алмаш-тилмәш көрәк белән балчык ыргыталар. Менә иңенә берьюлы егерме пар чабата күтәргән Галиулла чокыр алдына килеп басты:

— Сезгә, егетләр, чабатаның менә дигәнен алдым. Аның өстендә кыска брезент пинжәк, пинжәк өстеннән

кул яссуы зурлыгындагы каеш белән билен нык итеп буган. Ул әле күптән түгел генә авылдан эшкә килде. Тальян белән авыл урамын бер итеп йөрмәгәненә дә инде бер ай. Бер ай инде аның кызларын күргәне юк. Артельдән аны: «Син русча беләсең...» — дип сайладылар. Имеш, десятникларның эшләткән эшләрен барысын да белеп тор, вакытында нәрәт яздыр, вакытында эш киемнәре алуны кайгырт...

Кичә генә алар беренче хезмәт хакын алдылар. Вак акча булмагач, Хәйри картның егерме тиене Галиуллада калды. Шул акчаны сорый-сорый, Хәйри карт Галиулланы йөдәтеп бетерде. Галиулла: «Бүген тагын сорар, үзе сораганчы бирим», — дип, аңар көмеш тәңкәне бармаклары эченә яшереп сузды.

— Хәйри абзый, мә әле, бер нәмә бирәм.

Хәйри карт көл төшкән сакалын селкетеп көлемсерәде:

— Ала каргада алачагың булсын икән, — дип, акчаны сузылып алды.

Галиулла чокыр кырыена баскан да әле һаман карап тора. Аның әнә шул балчыкларны казып, тиз генә эшләп, күп кенә акча аласы килә. Алачак акчаны канларга тоту турында да баш вата ул: егерме сумы өйгә, ун сумы чалбар алырга, ашаудан артканы өйгә кайтканда баеп кайтыр өчен сума җыярга китәчәк... Аннан башка хыяллар...

Шулай матур уйларга чумган чакта, аның алачак-би-рәчәкләре фикерен чуалтты.

— Вәлиулла абзый, минем синнән аласым бар бугай.

— Каян килсен ул?

— Ник, столовойда икәү винегрет ашадык ич, оныттыңмыни?

— Ай-яй, Галиулла, онытмыйсың икән үзең дә. Шат, гел шуны уйлап йөрисең, — дип, Вәлүк елмая төште.

— Егет кешенең башында мең төрле уй була ул. Вәлүк башын селкеп елмаеп куйды:

- Бирермен, Алладан вәгъдә җиткәч бирермен. — Үзе кесәсе төбеннән киндер янчыгын эзләп тапты да, акта-рына-актарына: — Вак акча юк икән шул, апаем, — диде.

— Юк, миңа хәзер үк бирүең кирәк түгел, тик онытып кына җибәрмә диюем, — дип, Галиулла үзен-үзе юатты.

Якты күл буенда субай сугалар.

— Әйдә күтәрик әле!

— Тагын күтәрик әле!

Менә атлылар бүрәнәләр, такталар төяп уздылар.

Галиулла субай сугучыларга да, бүрәнә төяп китүчеләргә дә артык әһәмият бирмәде. Аның иң зур әһәмият биргән нәрсәсе — эш, аннан акча иде.

Кинәт сөйләшә башладылар:

— Ну, егетләр, нишлибез, ударныйга язылабызмы? — диде ул.

— Бер-ике-өч ай эшлик әле. Үзебезне эштә күрсәтик, ә болай кәгазьдә генә торып, бер файда да булмас, — диде егетләрнең берсе.

— Ударныйны отпускыга кайтармыйлар дип сөйлиләр,— диде икенчесе.

— Юк ла, карчыклар сүзен сөйлисең син!

Арада көлдерә торган Җамали бар иде. Ул сүзгә кушылмый калуны бер кимчелек санады, ахры. Башта:

- Ну, товар бирәләрме соң, товар? — дип сорап куйды.

- Бирәчәкләр ди шул.

- Мин риза, җегетләр, сез теләсәгез нишләгез. Башкалар:

— Котырынма әле, Җамали! — диештеләр.

Ул, бераз гына уйлап торгач, кинәт кыяфәтен үзгәртә төшеп:

— Юк, булмый икән, җегетләр, — дип куйды. Бар да аңар карадылар:

— Ник булмый?

— Беләсезме, ударный булгач, акчаны ничек бүләчәкләр?

— Ничек?

— Борын башыннан.

— Әй, адәм рәтле сүз әйтә дип торабыз тагын, — дип көлешеп алдылар.— Вәлиулланың борыны кечкенә, аңар акча да аз тиячәк, шуңа күрә ул ударныйга язылмый

да...

Бары да шаркылдаштылар. Вәлүк кенә көлмәде.

— Вәлиулла әле ул дарым ярты борынлы булсын, Ленинградта эшләгән чакта, Җамали ише шакмак борыннарны чакрым ярым ташлый торган иде.

— Булмас ла, Вәлиулла, булмас ла, артыграк сүтеләсең, — дип каршы төште Җамали.

Галиуллага Якты күл буенда бер төркем кешеләрнең нидер карап йөрүләре күренде. Алар үзара нидер тикшерәләр. «Берәр комиссия-фәләндер. Тикшерергә чыкканнардыр», — дип уйлады Галиулла.

Якты күл буенда йөрүчеләр тикшерү комиссиясе түгел иде. Ул билгеләнгән ун комсомолның, төзелешкә килеп, эш белән танышып йөрүләре иде.

Төзелеш башлыгы Вәлиев аларны шатланып каршы алды, эш белән таныштырды.

Җир эшләре беткән урында опалубщиклар нәзек кенә шома нарат такталардан төрле багана формалары, колонна калыплары ясыйлар. Арматурщиклар бармак юанлыгы тимерчыбыклардан, ерткычларга читлекләр әзерләгәндәй, тимер-бетон өчен челтәрле рәшәткәләр үрәләр. Шуннан соң бетон эше башланачак. Әнә чуерташ юдыру машинасы әйләнә. Юылган чуерташларны вагонеткаларга төяп әзрәк алып баргач, бер ковшка бушаталар. Шунда ук икенче яктан бетонщиклар аңа ком, цемент кушалар. Ковш югарырак күтәрелә, һәм эчендәге катнашма бетон бутагыч машинага бушатыла. Шунда ком, цемент, чуерташ бергә кушылып болгатыла.

Өлгергән бетон күтәрү ковшына килеп төшә, анысы исә аны тиз генә тиешле урынга күтәреп алып менеп китә. Аннан бетон калай трубалар буенча кирәкле урынына барып җитә. Арматура тимерчыбыклары тигез тулсын өчен, калай трубалар аша биектән агып төшкән бетонны трамбовать итеп тыгызлап торалар.

Шефлар җир казучылар янына да килделәр.

Менә бер карт җирнең катылыгыннан зарлана башлады. _

— Йә, бигрәк тә каты булып чыкты бу урын, бер-ике генә ыргыткач та, йөрәк сикерә башлый, — диде.

Сабирны бетонщикларга бригадир итеп куйдылар... Аның күз алдында яңа эш кыры ачыла: аның кулыннан башларын күккә сузган колонналар, үзләренең җилкәләрендә ничә мең тонналы корпусларны күтәреп торачак борыслар туачак...

Ул, канаудан көрәген аркылы куеп, җир өстенә чыгучыны күрде:

— А-а, Галиулла авылдаш, ни хәлең бар?

— Ничек килеп чыктың, Сабир?

— Ничек дип, мин хәзер гел монда эшләячәкмен.

— Әллә безгә кердең?

— Ие, комсомол мобилизовать итте.

— Әйдә, конторга таба бармыйсыңмы? Минем шунда барасым бар иде, — диде Галиулла.

Алар, комендатура янындагы игъланнар ябыштыра торган такта янына туктап, белдерүләрне караштыргаладылар.

«Иртәгә, 29 июльдә, төзелештә булган партияле һәм партиясез яшьләрнең кырга чыгып күңел ачулары үткәрелә. Ашау расходларын төзелеше каплый. Җыелу урыны контора янында, иртән сәгать 7 дә» дип язылган игъланны укыдылар.

Кыр дигәч, Сабир күз алдына еракларга сузылган, дулкынланып торган игеннәр килә... Кояш әкрен генә күтәрелә, чирәмнәрдәге чыклар көмеш кебек ялтырый, тургайлар сайрый...

— Барабызмы? — диде Сабир.

— Юк, бармыйм, — диде Галиулла.— Кызу эш вакытында эшләргә кирәк. Ә шулай да анда соң нәрсәләр булачак?

Сабир башта ни әйтергә дә белмәде. «Нәрсә турында әйтсәң аның күңеленә ошар икән?» —дип уйлады ул.

- Кызлар, халык уеннары, су керүләр була инде, — дип куйды.

- Ә гармун буламы?

Галиулланың тел төбен Сабир тиз сизеп алды:

Гармун гынамы соң, анда башка уен кораллары да күп була.

— Барсаң да ярый икән, — диде Галиулла.

Сабир өчен иртәгеге көнне җиткерү авыр. «Менә иртәгә кызарып кояш чыгар, су өсте тын булыр, кармак алып барсаң да ярый. Хәер, вакыт булырмы икән? Бигрәк тә әле аның шунысы кызык: бу кырга чыгу күн заводы эшчеләре белән бергә булачак».

Иртә белән Сабир беренче эш итеп тәрәзәгә күз салды. Тышта вак кына яңгыр сибәли иде. Димәк, болай булгач, бары да бетте.

Ул, һәр атнадагы ял көнендәгечә киенеп, төзелешкә барды. Комсомоллар ял көннәрен үзләре теләп онытканнар иде.

Төзелеп! капкасыннан кергәндә, аңар рабочком председателе Корнишин очрады. Ул бөтенләй алҗыган; «күбенгән» портфелен көчкә сөйри:

— Безобразие, опалубщиклар бригадасы бүгеннән эшләрен туктатты.

— Нигә, әллә айлык әз төшәме?

— Такта юк.

Каяндыр, ашыгып, инженер Гуревич килеп чыкты. Аның ялан ялтыр башы фуражкасыз, күлмәк якалары каптырылмаган.

Корнишин, әтәч сыман, Гуревичка ташланды:

— Нигә материалларны алдан әзерләмисез? Утыз опа-лубщикның бүген простой...

— Мин гаепле түгел, иптәш Корнишин. Тәэминат бүлеге ни карый? Ул утыз кеше турында кайгыгыз булмасын, мин аларны башка эшкә урнаштырдым.

— Такта турында тәэминат бүлеге ни ди?

— Такта заводы такта җитештереп өлгерә алмый, ди.

— Такта булырга тиеш! Сабир да сүзгә катнашты:

— Яле, булмаса, үзем барып карыйм әле.

— Вот молодец! — диде Корнишин. Атлар да килде.

Өч комсомолдан торган бригада, такта алырга дип, такта заводына китте.

Корнишин алар артыннан кычкырып калды:

— Карагыз, тактасыз кайтып керәсе булмагыз! Атлар юыртып баралар. Такта өчен махсус эшләнгән

кәкре арбада утыручылар тып-тын. Ал арның тәмәке төтене генә ат җиле белән артка бөтерелеп кала. Урман алдындагы үрне менгәч, такта заводының тимер морҗасы күренде. Аның янында тау-тау булып өелгән такталар. Тирә-якны пычкы чүбе каплап алган.

Комсомоллар заводның директорын эзләп таптылар. Ул завод каршындагы правлениенең бер кабинетында тәмәке төтененә күмелеп утыра иде.

— Иптәш директор сез буласызмы? — диделәр комсомоллар.

— Ие, мин булам.

— Вот, иптәш директор, без сезгә «Светострой»дан бик зур үтенеч белән килгән идек. Безнең хәзер анда эш тәмам тукталды. Утыздан артык опалубщик эшсез тора. Такта юк.

— Не, — диде директор, маңгай чәчен ике кулы белән төзәтеп.— Да, җегетләр, такта хәзергә юк шул.

Партия оешмаларының «Светострой» турындагы карарлары директорга билгеле иде, ул моны бик яхшы белә. Ләкин директор барыбер күнмәде. Менә якында тимер юл станцасы салыначак икән. Җитмәсә, ул да удар төзелеш. Анда эшчеләргә торырга барак төзү өчен такта кирәк. Бар тактаны иртәгә үк шунда озатачаклар: инде бол арының нәрәт вакыты әллә кайчан үткән. Җитмәсә, җитмеш чакрымдагы кәгазь комбинатының моннан ике ай элек бирелгән заказы үтәлмәгән.

— Юк, такта юк, иптәшләр. Булса, бик-бик рәхәтләнеп бирер идек.

Чыннан да, заводта артык такта юк иде.

Кычкырышып эш чыкмаслыгын белгәч, Сабирлар китү ягын карадылар. Ишек төбенә чыккач, алар бер план кормакчы булдылар.

— Тукта, завод хәтле завод булгач, аның партия ячейкасы, һич булмаса, комсомол ячейкасы бардыр, — диде Сабир.

Алар шул правление урнашкан йорттан комсомол ячейкасын эзләп таптылар. Өстәл артында берәү нидер язып утыра иде. Сабир туры аңа барды.

— Секретарь сез буласызмы?

— Ие, мин булам. Утырыгыз, — диде секретарь, кар-шыда торган урындыкка ишарә ясап.

Алар ни өчен килгәнлекләрен, директорның ничек җавап биргәнен сөйләп бирделәр. Секретарь дикъкать белән тыңлап торды да:

— Алай булгач, мин партия ячейкасы белән сөйләшеп карыйм әле, — дип чыгып китте.

Шул арада Сабирлар сөйләшеп алдылар:

- Бол айга киткәч, алабыз инде. Секретарь озак тормады:

— Ул юк икән, эшчеләр янына производствога чыгып киткән. Зарар юк. Әйдәгез әле, берегез белән директор янына кереп карыйк.

Сабир белән секретарь директор янына керделәр. Директор нидер ашыгып яза иде.

— Менә бу иптәшләр «Светострой»дан килгәннәр,— диде секретарь.

— Алар минем янда булдылар инде. Артык такта юк, иртәгә үк мин боларын озаттырам. Әгәр булса, бик рәхәтләнеп бирер идек.

— Алай булганда, менә нәрсә: безнең комсомол бригадасы, ял көне булса да, иртәгә эшкә чыгар. Бүген без «Светострой»га кирәкле тактаны биреп җибәрик, ә иртәгә без сезгә аның урынына яңаларын әзерләп өлгертербез.

— Менә алай дисәгез ярый, — диде директор. Ул комсомол секретареның бу сүзенә чыннан да шатланды. Хәтта, урыныннан торып, секретарьның аркасыннан сөеп куйды.

Алар такта төяргә дип чыкканда, көн дә аязып килә иде инде.

**Байрак өчен**

Якты күл буеның ике ягында да эш кызып бара.

Бер ягында, төзү материаллары арасында, үзләренең тимер көрәкләрен, балталарын тоткан эшчеләр төркеме эш мәйданына сибелгән; икенче якта күн заводының бетон корпуслары эчендәге эшчеләр тиреләрне төрле сыйфатка кертәләр. Аяк киемнәре, күн перчаткалар, күн курткалар әзерлиләр.

Күн заводы инде ярыш уты белән кабынды, ләкин әле яңа төзелештә бу нәрсә юк. Яңа төзелеш мәйданында бригадалар оеша гына башладылар. Күн заводыннан төзелешкә күчерелгән комсомолларга бу турыда нык кайгыртырга туры килде. Алар үзара җыелып сөйләштеләр, күн заводының тәҗрибәсен уртаклашырга, ул тәҗрибәне яңа төзелешкә дә күчерү кирәклеген әйттеләр.

Завод комсомол ячейкасы да төзелешкә ярдәмгә кил-мәкче булды. Бу эшне башлап җибәрер өчен, күн заводыннан Разия җибәрелде...

Ул, комендатурадан пропуск алгач, озак итеп төзелешне карап йөрде. Балаларча кызыксынып, бетонщиклар янына килеп чыкты. Бетон бутагычның әйләнүенә исе китеп карап тора иде, аркасына бер кул әкрен генә килеп төште. Артка борылып карады — ул Сабир иде.

— Каян җил ташлады?

— Каян булсын, бергә тор да төзелешне күрмә! Бетонщиклардан берәү сүзгә кушылды:

— Син, кызый, нигә безнең бригадирны хаять итәсең? Разия, елмаеп:

— Әй, андый агач бригадирлар, — диде.

Эшчеләр дә елмаештылар. «Равиянең бүген бертөрле эше юк, ахры, шулай шаян сүзләр сөйләр өчен генә килгән кебек», — дип уйлады Сабир.

Разия, бетонщикларга карап:

— Җә, кайчан разряд аласыз? — диде. Бетонщиклар, шаярып:

— Иртәгә! — диделәр.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, конторга таба киттеләр. Инде хәзер Разиядә баягы уен сүзләр юк, аның йөзенә җитдилек билгеләре чыккан иде.

— Беләсең нәрсә? — диде ул.— Обкомолның ярышта өстен чыккан завод-фабрикаларга дип билгеләнгән байрагы бар. Мин сезгә шул хакта килдем. Адушкин белән сөйләшергә дип килгән идем.

— Сез, рамочныйлар, заводта өстен чыккач, инде шәһәр күләмендә дә өстенлекне алырга уйлыйсызмы әллә?

— Эш аңарда гына түгел бит.

Алар баскычтан өске этажга күтәрелделәр. Сул якта ячейка бүлмәсе иде.

Аларны «Светогрэс» комсомол коллективы секретаре Адушкин каршы алды. Аның өстендә ак күлмәк, ике җиңе дә пөхтә итеп беләккә кадәр сызганылган.

Ул, керүчеләрне күргәч, яза торган каләмен куйды да:

— А-а, әйдәгез, кадерле кунаклар, түрдән узыгыз,— диде.

Адушкинның сүзенә каршы:

— Нинди кунак булыйк без сезгә, көн дә сездә дигәндәй йөрибез, — диде Разия.

— Кунак дими, сезне кем дияргә кирәк. Сез бит ай күрде, кояш алды кебек, керәсез дә югаласыз.

— Көне-төне сездән киткәнем юк, тик син үзең менә, бюрократ кебек, кабинетыңда ятасың.

— Менә хәзер генә кузгалырга уйлаган идем, сез кердегез...

Секретарь өстәл өстендәге кәгазьләрне рәтләргә тотынды. Разия белән Сабир тынып калдылар.

Секретарь, кәгазьләрне өстәл тартмасына сала-сала:

— Нигә тын калдыгыз, авызларыгызны бикләделәрме әллә? — диде.

- Гел-гел сөйләп тормыйлар бит, җил дә вакытлы гына исә, — диде Разия.

- Беләсеңме, Разия безгә ник килгән? — диде Сабир.

- Ник?

— Үзе әйткәнче, мин әйтим инде: матур җегетләрне күзләргә.

Разия уенны тагын да сузарга уйламады, ахрысы, төсенә җитдилек чыгарып, сүз башлады:

— Менә нәрсә, Адушкин иптәш, — диде. — Гәзиттә укыгансыздыр инде обкомол ярышта өстен чыккан оешмага байрак вәгъдә итә... Син аны укыдыңмы? — дип, ул секретарьга текәлеп карады.

— Укыдым.

— Уку гына җитми, аны җыелып тикшерергә дә эшкә башларга, ярышка чыгарга кирәк. Мине үзебезнең ячейка шул хакта җибәрде. Без сезнең комсомоллар белән бергәләп җыелыш ясарга да ярыш договоры кабул итәргә уйлыйбыз.

— Дөрес сөйлисең, — диде Адушкин. — Анысы кирәк, ә бит минем комсомоллар әле чыныкмаганнар, сезнең как-никак, үзең беләсең... Безнең җиңелүебез бар...

— Син ул хакта борчылма, безнең социализм ярышы капитализм конкуренциясе түгел бит ул. Без буксирга килербез, ярдәм итәрбез. Аннан, монда бит әле безнең менә мондый ун җегетебез бар. — Ул кулы белән Сабир-га күрсәтте. — Алар шактый эш башкарырлар.

Адушкин бераз гына уйлап алды да:

— Булды, Разия, бир бишне! — диде. ...Алар кул кысыштылар.

— Озын сүзнең кыскасы, әйдәгез, договорның пунктларын әзерлибез, — диде Разия.

Сабир бетонщиклар янына чыгып китәргә борылган иде, Разия аны бик тиз күреп шелтәләп алды:

— Кая качарга йөрисең син, җегет кеше?

— Кая качыйм, эшкә барырга кирәк.

— Хәзер бу эш барысыннан да кирәклерәк, әйдә безнең белән бергә эшләш, — диде Адушкин, үзе өстәл тартмасыннан кәгазь-каләмнәр чыгара башлады.

Разия, торып, тәрәзәләрне ачып җибәрде. Бүлмәгә саф һава керде. Алар, кулларына кәгазь, каләм алып, өстәл янына уңайлабрак утырдылар.

* * *

Төшке аш вакыты. Завод эче тын...

Рамочныйда да тынлык... Рамочный цех урнашкан бүлмә диварын зур кош канатыдай кызыл байрак каплаган. Ул байрак завод эчендәге ярышта беренчелекне алган өчен бирелгән булган.

Кызлар аны безнең байрак дип йөриләр. Төшке ашны ашап кергәч, Разия кызларны үз янына чакырды.

— Нәрсә бар? — дип, кызлар төрле почмаклардан килә башладылар.

— Менә шул нәрсә бар, — дип, ул диварда эленгән байракка төртеп күрсәтте.

— Әй, аның барлыгын күптән беләбез без, — диде кызлар.

— Беләсез дә, белеп тә бетермисез әле. Безнең комсомоллар белән «Светогрэс» комсомол коллективы ярышырга уйлый.

— Белмим, әки, аларны җиңеп булыр микән? — диде бер кыз.

— Ә ярышта өстен чыккан якка нәрсә бирeләчәк? — диде икенчесе.

— Республика күләмендә өстенлек байрагы, — диде Разия, аннан тавышын күтәребрәк сөйләп китте: — Иптәшләр, безнең алда зур бурычлар тора. Шуның өчен тагын да көчләрне арттырып, үзебезнең договорны алдан үтик, промфинплан завод күләмендә тизрәк тулсын. Шул хакта завод күләмендә комсомол җыелышы булыр, менә шуңа әзерләнергә кирәк. Әгәр дә тыңларга теләсәгез, мин сезгә договорның проектын укыйм.

— Укы, укы! — диде кызлар.

Разия халат кесәсеннән кәгазьләр чыгарды.

— Мин сезгә аның кереш сүзен укып тормыйм. Хәзер звонок булуы бар, тик аерым пунктларын гына укып чыгам, — дип, баскан килеш кенә укый башлады: «Светогрэс» һәм безнең комсомоллар тарафыннан үтәлергә тиешле пунктлар:

1. Завод һәм төзү промфинпланын һәр айныкын да тулы килеш үтәргә. 2. Брак һәм прогулны бетерү өчен көрәш алып барырга. 3. Ленин комсомолының шефы булган илне электрлаштыру планын үтәү нигезендә «Светогрэс» гигантын беренче майда ходка җибәрергә. Ә күн заводы комсомоллары икенче квартал планын вакытыннан элек —15 майга үтәп бетермәкчеләр».

Пунктларның иң зурлары шулар. Өстәрдәй әйберләрегезне җыелышта әйтерсез. Җәелеп сөйләшеп торырга вакыт юк.

Нәкъ шулчак звонок шалтырады.

Тагын чүкеч тавышлары, такта шапылдаулары, пешкаларның сикерү тавышлары цех эчен чорнап алды. Аскы катта мездра машинасы зырылдарга, барабаннар үкерергә тотындылар.

**Ун сәгать**

Кояш, кара туфраклы җирдән дымны үзенә алып, рәхимсез рәвештә кыздыра. Аның кыздыруыннан эшләүчеләрнең киндер күлмәкләре, манма су булып, тәннәренә ябышалар, әйтерсең әнә шул җир казучы кешеләр көннең кызулыгына чыдый алмаганнар да, Якты күлгә барып, чишенми генә чумып чыкканнар. Урак ургандагы кебек, ал арның салкын әйрән эчәселәре килә, ә төзелеш бакларында бары тик кайнаган су. Кайнаган су Вәлүкнең сусынын басмый. «Син аны эчәсең, бер минуттан ул, тир булып, тәнгә чыгып җитә... — дип уйлый Вәлүк. — Нәрсә дип кайнаткан булып суның тәмен бетерәләр икән, әҗәлең җиткән булса, теләсә нинди су эч — барыбер кәкрәерсең», — ди ул.

Җир казучылар бүген бетерергә тиешле эшләрен бетерә алмадылар, өзеклек килеп чыкты. Срок буенча иртәгә эшне тәмамлап тапшырырга тиешләр, тик әлегә сул як стена колонналарының булачак урынының балчыгы да кузгатылмаган.

Баш инженер Рейдел белән төзү башлыгы Вәлиев, икәүләп, башкарылган эшләрне карап йөриләр.

Инженер, үзенең һәрвакыт бимазалый торган пенснесен урыныннан кузгата-кузгата, Вәлиевкә сүз кушты:

— Иптәш Вәлиев, болар бетерә алмыйлар бит.

— Нишләргә соң?

— Бетонщиклардан Салахов бригадасын кушарга кирәк булыр.

— Каршы килмим, — диде Вәлиев.— Бик мәслихәт,— дип өстәп тә куйды.

Бетонщиклар бригадасы, көндезге сменадан эшләрен бетереп кайтып, ял итәргә ятканнар гына иде, Сабир янына Адушкин кереп сөйләп бирде:

— Менә, дус кеше, эш нәрсәдә: сиңа бригадаң белән бүген төнге уникедән өченче сменага чыгарга туры килә. Кара, подкачать итмә, комсомоллык байрагын югары тот!

— Була ул.

Сабир ышандырып калды. Ә бригадага әле хәбәр дә ителмәгән иде. Кайсыларыдыр ятарга әзерләнә башладылар. Каршыдагы уку бүлмәсендә ут сүндерелде. Аннан бер төркем яшьләр чыкты. Сабир аларга төнге уникеләрдә эшкә барырга тиешлекне әйтеп куйды.

Вәлүк каршы килеп маташты:

— Ул нишләгән эш тә эш, ял итәргә ярамый микәнни безгә?

Сабир каты бәрелде. Күптән инде шул исереккә аның ачуы кабара башлаган иде.

— Берьюлы, станцаны ходка җибәргәч ял итәрсең, — диде Сабир.

Башкалар дәшмәде.

— Беләсезме, иптәшләр, — диде Сабир.— Җир казучылар фундамент урынын берсекөнгә өлгертә алмыйлар. Фундамент урыны өлгермәгәч, бер яктан, ташчылар, икенче яктан, опалубщиклар эшсез торачаклар. Без төзелешкә аз булса да ярдәм итәргә тиешбез бит. Әгәр без баш тартсак, шулмы безнең ударниклыгыбыз?

- Мин бүген сәгать уникенче яртыда эшкә чыгам, сезне дә үзем белән чыгарга чакырам... Үзен эшче дип йөргән кеше...

Ул әйтергә теләгән сүзен әйтеп бетермәде, иптәшләренең күбесе, тавышланып, аның сүзен бүлдерделәр:

— Тукта әле, сиңа бит бармыйбыз дигән кеше юк шикелле...

— Иптәш бригадир, син агитация ясап маташма, тот та әйт: җегетләр, эшкә чыгабыз, диген.

Чыннан да, Сабирга күп сөйләп торырга кирәк түгел иде. Эшчеләрнең күбесе чәй алып кереп эчәргә утырдылар. Тик Вәлүк кенә нәрсәдер мыгырдап йөрде. Ул бармаска уйлады. Баракта калучыларны да бутарга кереште. Сабир чыгып киткәч:

— Беләсезме, Сабир ник тырыша? Ул наград алырга тели, ә без, җүләр җилкәләр, арка тиребез белән аңар наград әзерлибез, — диде.

Ләкин аның нинди кеше икәнен бетонщиклар белеп өлгергәннәр иде инде. Шуның өчен дә аның сүзенә колак салучы булмады. Бөтен кеше китеп беткәч, ул да үз фикереннән кайтты.

Соңгы трамвайлар ашыгып уздылар.

Соңгы трамвай кук, бригаданың соңгы члены Вәлүк тә эшкә чапты.

«Мин генә бармый калу килешеп бетмәс, аннан бит әле...»—дип уйлады ул.

Галиулла бригадасы икегә бүленеп эшли иде. Алар-ның бер өлеше эшкә тотынган инде. Аларга Сабирлар бригадасының болай ярдәмгә килүе хурлык булып күренә... Галиулла өчен дә бу, билгеле, уңайлы түгел иде. - Нихәл, җегетләр, эшләр хөрти диген, ә? Алла куәт бирсен, — дип, бетонщиклар көлемсерәп хәл сораштылар.

— Сезнең шикелле тимер җегетләрне монда бирсен,— диделәр җир казучылар, алар да сер сынатмадылар.

— Барыбер үзегезне килеп буксирга алырга туры килде...

— Буксирга булгач, сез ничек, баржа буласызмы инде?

— Буксирга караганда баржага күбрәк мал төйиләр ич.

— Сөрлектегез, җегетләр, сөрлектегез.

— Яхшы ат та бер сөрлегә ич ул, Вәлүк абзый.

— Анысын дөрес әйттең, абзый кеше.

Алар шундый уен-көлке белән эшкә тотындылар. Икенче көнне ашханәдән кайтып чәй эчәргә утырыр алдыннан Сабир белгертеп куйды:

— Җегетләр, чәйдән соң беркая чыгып китмәгез, сөйләшәсе сүзләр бар.

Чәй эчкәннән соң, менә шул «сөйләшәсе сүзләр» өчен, бетонщиклар бригадасының җыелышы булды.

Беренче мәсьәлә ун сәгатьлек эш көне хакында иде.

Председатель, секретарь сайлап тормадылар, җыелышны бригадир Сабир алып барды.

- Эш менә нидә тора, җегетләр. Безнең төзелештә хәзерге вакытта эшче көчләр җитми. Без булган кадәр эшчеләрнең эшләп чыгару мөмкинлеген, куәтен-көчен файдаланырга тиешбез. Шуның өчен без, алдынгы бригада сыйфатында, үзебез бантлап ун сәгатькә күчеп, башка бригадаларны да үзебез белән тиңләшергә чакырыйк. Менә минем шундый тәкъдимем бар. Сез ничек карыйсыз?

Башта берәү дә сүз башларга батырчылык итмәде. Бераз тын торганнан соң, Исмай чыкты:

— Ну соң, Сабир, ун сәгать эшләп безнең талчыгу арта, эшләп чыгаруыбыз түбәнәймәс микән? Аның нинди кирәклеге бар? Эшләп чыгару кимеми торган булса, күчәргә кирәк, җегетләр, минем әйтәсе килгән сүзем шул гына иде, — диде ул.

— Аны исәпләгәннәр инде, — диде Сабир.— Дөрес, эш көненең унынчы сәгате белән беренче сәгатен чагыштырып булмый. Шулай да аерма зур түгел.

Арадан берәү кычкырды:

- Ә акча ягы ничек булачак?

— Безнең эшләү эш башыннан, аннан соң шуңар өстәмә рәвештә шул артык ике сәгать өчен тариф ставкасын да китереп кушачаклар.

Арадан бер карт чыкты:

— Сабир, нани, бу турыда күп сөйләп торасы юк. Без болай да ун сәгать эшлибез бит, кешедән алда барып ябышабыз... Әйдә яз, барыбыз да риза, диген. Галиулланыкыларны да, Митринекеләрне дә чакырыйк.

Бу фикерне башкалар да яклады.

Вәлүк дәшми-тынмый гына утырды. Эченнән ул каршы иде. Ләкин ул да кулын ун сәгатьлек эш көненә риза булучылар белән бергә күтәрде.

— Иптәшләр, тагы бер мәсьәлә бар. Бу үз арабыздагы тәртипсезлекләр турында: менә Вәлиулла абзый күп вакыт куелган мәсьәләгә каршы төшә. Бүген менә ничектер әле каршы чыкмады. Аңарга без җыелыш исеменнән әйтеп үтик: әгәр дә тагын бер мәртәбә генә бригаданың карарына аның тарафыннан каршы килүме, аяк чалумы астыртын рәвештә сизелсә, ул бригададан чыгарылачак.

Моңар бары да риза иде...

* * *

Сабир бригадасының чакыруын төзелеш башлыклары бик шатланып каршы алдылар. Бу мәсьәлә турында Наркомтруд белән дә сөйләшенде. Анда, төзелешкә эшче көчләрнең җитешмәвен искә алып, вакытлыча ун сәгатьлек эш көне кертүгә каршы килмәделәр. Менә хәзер комендатура янына ун сәгатьлек эш көне кертү турында приказ эленгән. Узган-барганнар һәрберсе шуны укып китәләр. Анда бу эшне башлаучы Сабир бригадасына рәхмәт тә бар.

Менә сәгать дүрт тулды. Нәзек кенә итеп төзелеп! гудогы сузылды. Эшчеләр кое янындагы тау сыман калкып торган урынга җыела башладылар. Әнә рабочком председателе Корнишин белән партия ячейкасы секретаре Адилов та кое янына килеп басканнар. Таушалган портфель күтәргән Корнишин җыелган эшчеләр өстеннән бер күз йөртеп чыкты да:

— Башласак та ярый, — диде.

Мыжлап торган кырмыска оясына охшашлы эшчеләрнең тавышларын Корнишин тиз басты:

— Тынычланыгыз әле, иптәшләр! Корнишин дәвам итте:

— Беләсез, иптәшләр, безнең төзелеш — удар төзелеп:. Ул бездән күп көч куюны сорый. Безгә хәзерге озын көннәрдә сигез сәгать эшләү генә җитми, безгә ун сәгатькә күчәргә кирәк. Без менә хәзер шуны тикшерәчәкбез.

Ач яңаклы җир казучы Мәһди карт, тирә-юньдәге иптәшләренә дә ишетелерлек итеп:

— Миколай вакыты кире кайта икән алай булгач, — дип әйтте дә, кычкырып, Корнишинга сорау бирде: — Кара әле, рабочком иптәш, ун сәгать эшләп кенә күп файда китерә алырбызмы соң?

Корнишин җавап кайтарганчы, Адилов сүз алды. Сүзен сөйләргә керешкәнче, ул зәңгәр күзлеген сөртте. Адилов-ның бер күзе генә исән, икенчесе пыяла иде. Ул бер күзен гражданнар сугышында калдырган, батырлыгы өчен бирелгән Кызыл йолдыз хәзер күкрәгендә ялтырый иде.

— Бездә, иптәшләр, хәзерге вакытта эшче көче җитешми, ә төзелешне тизләтергә кирәк. Аның сузылган һәр сәгате безнең өчен миллионнар тора. Бездә бит эш эш башыннан эшләнә. Ун сәгатьлек эш көненә күчкән кеше аңардан башка тариф ставкасыннан егерме биш процент алачак. Бу эшне бетонщиклар, Салахов бригадасы башлап җибәрде. Алар аны бөтен төзелеш алдына куйдылар.

Контора эшчеләреннән андыйлары, Совет властена җаны-тәне белән бирелеп эшләүчеләре, һичсүзсез, ун сәгатьлек эш көненә күчәчәкләр.

Шуның белән Адилов тукталды.

Баягы Мәһди карт, ишетелер-ишетелмәс кенә, тагын әйтеп куйды:

— Күп сөйләп торасы юк инде, приказ бар бит. Ике сүз булырга да мөмкин түгел.

Бу сүзне Корнишин ишетте да козырегы астыннан Адиловка карап куйды, үзе кызып сөйләп китте:

- Вот, иптәшләр, сыйнфый дошман безнең ялгышла-рыбыздан һәрвакыт файдаланырга гына тора. Эшчеләрнең үзләре башлап җибәрүләре белән вакытлыча ун сәгатьлек эш көненә күчүне Миколай вакытына кире әйләнеп кайту, ди. Без, эшчеләр, болардан сак булырга тиешбез...

Корнишин туктады да:

— Кемнәр сүз ала? — диде.

Бу эшне башлап җибәрүче Сабир сүз алды:

— Иптәшләр, бетонщиклар һәрвакыт алда барган кебек, партячейка тарафыннан яклап чыгылган һәм бик кирәкле дип табылган ун сәгатьлек эш көненә күчерүне төзелеп! башлыгыннан эшчеләр үзләре сораганнар иде. Рәхмәт, безнең тәкъдим кабул ителгән, безгә җиң сызганып эшләргә генә кала. Әгәр дә төзелеш шуны сорый икән, без бу айдагы ял көннәрне дә эшләргә сүз бирәбез һәм җир казучыларны, бигрәк тә Галиулла бригадасын ярышка чакырабыз.

Галиуллага җавапсыз калу оят иде. Ул тирә-яктагы бригада членнары белән нидер сөйләшкәләде дә сүз алды:

— Иптәшләр, авыл кырларында көтү көткән чагымда, кайвакыт шулай көтүем таралып киткәли иде. Шуның кебек әле минем бригада яңа оеша, аңарда әле таркаулык сизелә. Мин начар көтүче түгел идем, таралган көтүне минут эчендә туплый идем... Мин үз бригадамның күпчелеге исеменнән бетонщикларның чакыруын кабул итәм. Кирәк булганда, ял көннәрендә дә эшләргә сүз бирәм...

Хезмәткә күнгән куллар күтәрелделәр. Ун сәгатьлек эш көне бертавыштан үтте... Шушы җыелыштан кайтып килгәндә, Сабирга Вафа очрады:

— А-а, Вафа, исәнме!

Сабир Вафаның башыннан алып аягына кадәр карап чыкты: таушалган кепка, аның астыннан таралмаган чәчләре салынган, җиткән сакал-мыек.

Вафа авыз эченнән генә җавап кайтарды:

— Ничево, үзеңдә ни хәлләр бар?

— Ни хәлләр дип, малай, хәлләр ал да гөл. Менә әле собраниедән кайтам. Моннан соң төзелештә ун сәгать эшләмәкче булабыз. Мине бит әле бетонщикл арга бригадир итеп куйганнар иде, без хәзер — ударниклар.

Вафа игътибарсыз гына тыңлады. Сабирның сөйләп бетергәнен көтмичә, аны бүлде:

— Әйдә, юлда басып тормыйк, мин дә шул якка таба барам.

Сабир, сүзеннән бүленмичә, Вафа белән бергә атлады:

— Үзебезне берничә тапкыр бүләкләделәр. Мине тиздән десятниклыкка күтәрәләр...

Вафа әзрәк кенә көнләп куйды: «Бу аның авылдашы Сабирмы? Юк, һич юк. Бу башка Сабир». Сабир сорашырга тотынды:

— Ну, гаилә хәлләрең ничек?

— Ничек дип, шул инде, башкаларныкы кебек.

— Юк, мин Фатыйма белән сине начар торасыз дип ишеттем...

— Кеше сүзе инде ул, — диде Вафа, эч серен ачып саласы килмәде. Үзе, Сабирга үпкәләгән сыман: — Син дә авылдаш итмисең хәзер, һич килеп чыкмыйсың... Килеп чыксаң, үз күзең белән күрер идең менә.

— Хәзер эшнең бик тыгыз чагы, унар-уңикешәр сәгать эшләргә туры килә. Ял димибез, ни димибез. Бит менә җәй көне безгә фундаментларны салып, стеналарны корып, түбәне ябып калдырырга кирәк. Аннан кыш көне, машиналарны куеп, беренче майда зырылдатып ходка җибәрергә. Кара әле, Вәлүкне белмисеңме син?

— Беләм, — дип көрсенеп куйды Вафа.— Беләм, ник белмәскә. Аны суд белән утын кисәргә җибәргән булганнар, ул, качып, сезгә эшкә кергән...

Алар саубуллашып аерылдылар.

Ул көнне кичтән җир казучылар барагында Вәлүк озак котыртып йөрде. Шуның аркасында Галиулла бригадасының яртысы ун сәгать эш көненә калмады. Алар да Вәлүк сүзен кабатладылар:

— Хөкүмәт үзебезнеке, эшчене аны бернишләтә алмыйлар. Галиуллага нәрсә аңар, бүләк тә бирерләр, награда да алыр... Безгә кая әле ул.

Корнишин тагын кызды. Сабир да битарафлык күрсәтмәде. Тагы бетонщиклар бригадасының җыелышы булды.

Вәлүкне бригададан чыгардылар.

Корнишин кызып-кызып сөйләде:

— Сыйнфый дошман... хөкүмәткә саботаж ясап, утын кисәргә хөкем ителгән, аннан качкан. Безнең арада әле алар күп, шуның өчен һәрвакыт искәреп йөрергә тиешбез.

Эшчеләр зур игътибар белән тыңладылар. Азактан Корнишин икенче тәкъдим ясады:

— Төзелештә эшче көче җитмәүне исәпкә алып, Вәлүкне җир казучылар бригадасында калдырабыз, каршы кеше юкмы?

Моңар берәү дә каршы килмәде.

**Корыч кадаклар**

Эшнең кызып барган чагында, кадак җитмәү мәсьәләсе көн кадагына килеп басты. Кадак күп тә кирәк түгел иде. Магазиннарда да һичбер төрле кадак заты юк, бүген-иртәгә кадак килүен көтәләр.

Кадак юклыкка карап эшне туктатырга ярамый. Төзелеш башлыгы Вәлиев анда сугылды, монда сугылды да комсомол ячейкасы секретаре Адушкин янына керде. Аларның сүзләре шул кадак табу турында барды. Сала-хов килеп кермәсә, алар, бәлкем, озак утырган булырлар иде. Ишектән шадра битле, сипкелле Салахов күренде.

Вәлиев кычкырып каршы алды:

— Әйдә, әйдә, Салахов, түрдән уз.

— Дәшмәсәгез дә киләм инде.

— Салахов, опалубка әзер була, бетонга әзерләнегез. Ул җир эше сезне туйдырып бетергәндер инде.

— Бер генә кадак та булмагач бит аны...

— Булмаса, табарга кирәк, — диде ул, бу малайдан берәр файдалы фикер чыкмасмы дигәндәй, аның ягына башын кыйшайтып.

— Менә мин дә шул кадак хакында җенләнеп йөрим. Миндә ике төрле тәкъдим бар иде, — диде Сабир.

Вәлиевнең күзләре Сабирга текәлде. Адушкин да, ашыга төшеп:

— Йә? — диде.

— Берсе — тимерчыбыктан кадак кисү, икенчесе... Адушкин, әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә, кулын

селекте.

— Белмим, булмас, — диде, кинәт өметсезләнеп.— Ә икенчесе?

— Икенчесе? Теге корпусның уң ягындагы бетон колонналар кипкәннәрдер дип уйлыйм. Кипсәләр, ал арның опалубкаларын алырга кирәк.

— Аның белән нишләмәкче буласың?

— Иске кадакны суырып алып, турайтып, эшкә җибәрербез.

Секретарь утырган җиреннән торды:

— Ә монысы, чыннан да, барып чыгар шикелле. Төзелеш балалыгы да, папиросын суыра-суыра:

— Бер гаҗәп эш булачак, — дип куйды. — Давай, Адушкин, бу эшне тиз генә оештыр, — дип өстәде.

— Мин әле күн заводында булдым. Безнең бит андый эшкә үз эшчеләребезне тоту файдасыз, күн заводы комсомоллары безгә өмәгә килмәкче булалар, шул арны кушарбыз, — диде Сабир.

Бу йөрәкнең нинди дәрт, нинди ашкыну белән типкәне әллә кайдан сизелә иде... ...Вәлиев урыныннан торды:

— Кайтыйм мин, җегетләр, иртәгә иртүк барасы җирем бар иде, — диде. Аннан, Адушкинга таба борылып: — Кадак өмәсен оештыруны сиңа тапшырам, — дип куйды.

— Була ул! — диде Адушкин. — Әйдә, мин дә киттем, күн заводына тагын бер тапкыр әйтеп куйыйк, яхшырак булыр.

Алар өчәүләп баскычтан төшеп киттеләр. Иртәгесен ял көне иде. Күн заводындагы яшьләр кадак өмәсенә килделәр. Аларны Сабир:

— А-а, иске дуслар килгән, — дип каршылады.

— Ие, безне онытып та җибәрдегез, — дип җавап кайтарды Разия.

— Сез онытыласызмы соң? — дип, Сабир уенга борды.

Яшьләр эшкә тотындылар. Разия корпусның уң яктагы опалубкасының тактасын лом белән каера. Сабир, эш белән үтеп барганда, аның янында тукталды. Ул Разиягә бераз карап торды да:

— Бир әле ломыңны, каера белмисең, — дип, аның кулыннан ломны алды.— Аны менә болай итеп каерырга кирәк.

Такталар шытырдап кубып чыктылар.

Әнә Галиулла да кулындагы ломы белән бетон багана һәм такта арасындагы арага китереп-китереп суга...

...Каерылган такталар, тавышланып, җиргә төшәләр. Секретарь белән бер төркем яшьләр кулларына корыч келәшчәләр алып аларның кадакларын суыралар. Суырылган кадакларны бер ящикка җыя баралар.

Әнә бер урында шул кадакларны тимерләр өстендә турайталар. Бер читтә доң-доң итеп тимерчыбыктан кадак кисәләр. Чүкеч тавышы үзенең чыңы белән колакны яра.

— Кадак булачак!

Өмәдәге яшьләрнең барысы да шул уй белән яна, алар-ны шул нәрсә шатландыра.

* * *

Күн заводы белән төзелеш яшьләре кырга чыгарга дип билгеләнгән көннәрендә яңгыр яуганга күрә бармый калганнар иде. Шуннан соң инде берничә ял көне үтте. Менә алар кадак суыру өмәсеннән соң килгән беренче ял көнендә барысы да кырга җыелып чыктылар.

Якты күл буйлап барып, Шайтан чокыры яныннан үтеп үрне менгәч, Миләүшә елгасы ялт итеп җәелеп ята. Тирә-ягы яшел болын белән уратып алынган елга, боры-лып-борылып, үзенең очын әрәмәлектә югалта.

Таллар ботаклары белән суга иелгәннәр дә әйтерсең Миләүшәнең терекөмеш суын эчәләр. Болын һавасы күкрәкләргә рәхәтлек бирә.

Разия, сумкасын тоткан кулын селки-селки, Сабир белән янәшә атлый. Алар ни турындадыр кызып сөйләшәләр.

Фатыйма белән Вафа да килә... Вафаның йөзе болытлы көн төсле ачулы, аңардан дөньядан туйганлык сизелә. Ул менә хәзер дә теләр-теләмәс кенә атлый. Бантка яшьләр кебек шат түгел.

Үткән прогулдан соң Вафага бары да кырын күз белән караган сыман тоела...

Колактан-колакка Фатыйма турында йөргән сүзләр Вафага килеп ишетелделәр: «Имеш, Фатыйма Булат дигән бер студент белән чуала, Вафаны ташлаган икән». Билгеле, бу сүзләр көнче Вафа күңелендәге ачуны тагын да кабарта төште.

Разия генә ул сүзләргә чик куярга теләде:

— Сез, әкиләр, кеше артында сөйләмәгез, берәр сүз ишеткәнсез икән, тотыгыз да аның күз алдында чикылдатып әйтегез.

Кызларның бер-икесе каршы килеп маташты:

— Туры әйткән туганына ярамаган, диләр бит, кеше йөзенә ничек чикылдатып әйтәсең.

Әле менә Вафа бу күңел ачуга килмәскә дә теләгән иде. Аны Фатыйма ирексезләп алып килде. «Барыйк, барыйк, әллә безнең хакыбыз юкмы?» — диде. Вафа каршы килә алмады.

Ә Галиулла күңел ачарга чыгу турында язылган белдерүне укыгачтын ук икеләнгән иде. Сабир ничек кирәк алай күндерә алды...

Менә хәтфә кебек тигез болынлык. Чалгыларны үтмәсләндерүче бер генә ат кузгалагы да күренми. «Их, киерелеп, үткен чалгы белән бер-ике пакус чыксаң иде!» — дип куйды Сабир.

Кемнәрдер ромашка чәчәкләре җыя башладылар. Фатыйма башкалардан да уздырып җибәрде, шул чәчәкне кулына алып берәмләп өзә башлады:

— Ярата, яратмый, ярата, яратмый...

Ә кайсылары ромашкаларны якаларына кыстырдылар, букетлар ясап, кулларында тотып йөрделәр.

Башта комсомол секретаре Адушкин ял итәргә ник чыкканлыкны аңлатып үтте:

— Иптәшләр, беләсез, машина да ял итә. Кешене без машина белән беррәттән куя алмыйбыз. Кеше машина түгел. Димәк, шуңа күрә без вакытында уйныйбыз, көләбез... Ә эш вакытында тауларны-ташларны актарып ташларлык дәртле көч белән муеннан эшкә чумабыз. Менә бу — безнең беренче мәртәбә ялга чыгу. Без, комсомоллар, бу ялга чыгуны да файдаланырга, партиясез яшьләрне дә үз сафыбызга тартырга тиешбез. Иптәшләр, әнә теге агач төбендәге өстәлдә утыручы комсомолга керү өчен анкеталар өләшә, теләгән кеше барып алсын...

Секретарьның сүзе беткәч, халык шау-гөр килеп таралды.

Мәйдан уртасында, Миләүшә елгасы янында халык уеннары башланды. Һәркем шат, һәркемнең йөрәге урыныннан чыгарлык булып тибә. Хәер, һәркемнең дип әйтеп булмас, әнә Вафаның...

Вафа бер читтә күңелсез генә уйланып утыра. Әйе, ул уйлый, үкенү катыш кайгыра: «Мин, комсомол булмагач, монда ник килдем? Комсомол булмаганнарга монда килергә ярамыймыни?»

Бүген ул барлык үткәненә үкенү аша карый...

**Тагын очрашырбыз әле**

Уйнап кына кабызган шырпыдан да көчле янгын чыгарга мөмкин. Шуның кебек, кечкенәдән башланган сөешү дә Вафаларның йөрәгендә ялкынга әйләнде. Гаилә чылбыры үзенең күренмәгән богаулары белән ике араны тоташтырды. Бу гаилә башка гаиләләр кебек бер-береңә булышу, җәмгыятькә файда китерерлек итеп корылмады. Гүя бу гаилә ашыгыч рәвештә генә төзелеп, үзенең тиздән җимерелүен көтте.

Менә хәзер аларның яши торган бүлмә эчләрендә үпкәләү катыш тынычлык хөкем сөрә. Мич тирәли юеш керләр киптерергә элеп куйганнар. Ике тәрәзә арасындагы буш урында өстенә кара түгелеп беткән, кырылган клеенкалы өстәл тора.

Мич буендагы караватта, тәртәләрен өскә күтәргән чанадай, киез итек кигән аякларын караватт тимеренә куеп, авызыннан моржа төтенедәй төтен чыгарып, Вафа ята. Ул үзенең үткән көннәрен бөртекләп саный, күз алдыннан үткәрә: беренче очраган юан гәүдәле, тиз йөрешле Фатыйма. Ул да булмый, аны чәчен йолкып-йолкып елый торган Фатыйма алыштыра... Менә аларның Фатыйма белән яңа танышкан көннәре. Вафа билет алган, алар театр карарга кереп баралар. Фатыйма алгы рәтләргә үк утырырга ашкына, Вафа әкрен генә аның чабуыннан тарта. Пудраланган, кызыл иннекләр сөрткән Фатыймага арткы рәттә утыру авыр була... Менә тагын алар бервакыт урамнан баралар, нидер кызу-кызу сөйләшәләр. Шул вакыт шакмаклы кепка кигән егет очрый:

— Ә-ә, исәнмесез, Фаечка, — дип, ул Фатыйма белән килеп күрешә, Вафага да баш игән була.

Фатыйма:

— Әсгать, нинди җилләр сине бу якларга китереп ташлады? — дип, шакмаклы кепка кигән егетнең кулын каты итеп кысып күрешә.

Вафаның йөрәгендә көнчелек уты кабына... Алар сөйләшеп калалар. Вафа, тәмәкесен кабызып, тротуар буйлап алга таба китә, ләкин Фатыйма һаман аны куып җитми. Ул артына әйләнеп карый, ләкин инде анда сөйләшеп торучылардан җилләр искән була...

Ул көнли. Иртәгә Фатыймага бер сүз дәшмәскә, аның белән ике араны бөтенләй өзәргә була. Ләкин иртәгесен Фатыйма үзе килеп сарыла.

— Авызыңны турсайткансың, җүләр, минем абый ла ул, — ди.

Бүгенге әрләшү дә, кычкырышу да Вафаның көнләшүеннән килеп чыга, ул өйгә кайта. Ни өчендер көн дә бикләнми торган иктек бүген бикле. Эчтә кемнәрдер ашыгып йөри. Ишек ачыла. Ут яндыруга, өстәлдәге тәмәке төпчеге, арткы яктан чыга торган ишекнең ябылып җитмәве Вафаның шиген арттыра.

Менә шул күренешләрдән соң өйнең асты өскә килә. Менә шуннан соң Фатыйма чәчен йолкый-йолкый елый башлый.

Ачу әзрәк басыла. Вафа елаган Фатыйманың җилкәсенә кулын сала. Фатыйма аның кулын алып ташлый. Бер-бер артлы зәһәр сүзләр әйтелә:

— Син теләсә нинди хатын белән сөбереләсең, эчәсең... Ә мин өй сакчысы булып утырам... Икең ике яры ташланып йөргәч, гаилә түгел инде бу. Хурлык бит, иптәшләрдән хурлык.

— Ие, хурлык, — дип, Вафа да сүзен башлый.— Нигә алай булгач бергә торырга? Яратмыйсың икән, тот та әйт, аерыла ала торганбыз бит. Комсомолдан чыгарылуга, прогуллар ясауга синең белән Вәлүк кенә сәбәпче булдыгыз...

Вафа күңелсез уйларга бата: «Юк, болай яшәргә ярамый. Мин моңа чыдый алмыйм, үземне кулга алырга тиеш мин».

Вафа караватта озак ятты. Әнә шул балдакланып-бал-дакланып түшәмгә таба үрелгән төтеннәргә әллә никадәр очсыз-кырыйсыз кара уйлар ялганды. Кая алып баралар соң алар Вафаны? Ул инде артык түзә алмады. Кепкасын башына элде дә ишектән чыгып китте.

Ул бик озак барды. Кешеләр аның күзенә күренмәде. Вывескага күтәрелеп карагач кына айнып киткән сыман булды. «Хәрби комиссариат» дип язылган ишектән эчкә атлады.

— Иптәш, армиягә доброволец булып китәргә теләүчеләрдән үтенечләрне шушында алалармы? — дип сорады.

Аңар бер өстәлне күрсәттеләр. Ул алдан ук әзерләп куйган гаризасын кесәсеннән чыгарды...

* * *

Кырга чыгып күңел ачканнан соң, байтак көннәр үтте. Якты күл буена төрле машиналар килде. Корпуста соңгы бетон эшләре бара. Турбиналарга нигезләр инде күптән әзер, аларга монтаж ясап, вак детальләрдән торган машинаны җыеп ходка җибәрәсе генә калды.

Тиздән менә Якты күл буендагы насос станцасы өлгерер. Алар ходка китеп, көмеш; тамчылы суны суырырлар. Ул су, трубалар аша күп мәртәбәләр чистарыну үткәннән соң, пар казанына төшәр, анда парга әйләнер, ул пар турбинага барыр. Турбина, авыр тегермән тапты сыман әйләнеп, үзе белән бергә генераторны әйләндерер. Үзенең төзелеше белән моторга охшашлы генераторның эчендә ток хасил булыр. Ул бакыр чыбыклар буенча кирәкле җиргә яшен тизлеге белән барып җитәр. Тиздән Якты күл буенда зәңгәр күктәге кояшка көндәш булып икенче бер «кояш» пәйда булыр. Аннары кара төннәрдә чыраен сыткан ай белән урам чаты саен нур чәчеп торган Ильич лампалары очрашырлар.

Төзү эшләре шул дәрәҗәгә җиткән көннәрдә алар трамвайда очраштылар. Разия бик зур китаплар бәйләме тоткан иде.

— Исәнме, Сабир! — дип, ул кулын сузды, аңа буш урын күрсәтте.

— Кая җыендың болай? — диде Сабир.

— Кая дисең, китәргә җыенам ич.

— Кая китәсең?

— Авылга, курсны бетердем.

Разияне райком педагогия фронтындагы яшь буынны тәрбияләүдә өзеклекне бетерү өчен мобилизовать иткән иде. Ул укытучылар әзерләү өчен ачылган берьеллык курсны бетереп чыкты.

Менә хәзер инде авылга җибәрәләр. Бер уйлаганда, аның гөрләп торган шәһәрдән һич китәсе килми. Шаулап торган күн заводын, курста бергә укыган иптәшләрен, җанлы газетада катнашучыларны, бригадасындагы акыллы кызларны, бантын зәңгәр күккә сузган «Свето-грэс» гигантын, андагы Сабирны ташлап китәсе килми. Ләкин комсомол тарафыннан бирелгән задание...

...Трамвай корыч рельслар буенча тәгәри.

— Без тагын очрашырбыз әле, — дип, Разия Сабир-ның күзләренә карап куйды.

Сабир сүзсез генә башын селкеде. Трамвай һаман йөгерде дә йөгерде...

**Беренче паровоз**

Эшчеләрнең киңәшмәсендә председательлек итүче Сабир кыңгырау шалтыратты:

— Иптәшләр, җир казучылар цехының киңәшмәсен ачык дип белдерергә рөхсәт итегез. Киңәшмәне рабочком тарафыннан сайлап куелган кешеләр алып барачак, беренче мәсьәлә — инженер Гуревичның эшләрнең барышы турында кыска гына аңлатмасы була. Хәзер беренче булып сүз прораб, инженер Гуревичка бирелә.

Инженер Гуревич торып сөйли башлады. Берничә минуттан сүзен шулай бетерде:

—...Безнең алга бу айда куелган бурычлар: су агызу каналын казып һәм тимер юл өстенә комны җәеп бетерү. Күптән түгел җир казучылар бригадиры Галиулла Биктаһиров белән сөйләшкәндә, аңардан гаҗәп файдалы булган бер тәкъдим ишетергә туры килде. Ул тимер юл өчен кирәкле булган ком урынына су агызу каналыннан казып чыгарылган комны файдаланырга куша. Без хәзергә кадәр комны ничә километрдан ат белән ташый идек. Галиулла атларга да эш калдырмый. Су агызу каналы буенча сузылган ул участокны тачкалар белән илтеп аудару җаваплылыгын үз өстенә ала. Аяк астында гына яткан практик эш. Без моның белән күп экономия калдырачакбыз. Су каналыннан чыгарылган ком хәзерге вакытта лабораториядә тикшерелде, аның сыйфаты уртача дип табылды. Иртәгәдән без практик эшкә тотынабыз... Инженерның сүзе бетте.

— Сораулар бармы? — диде председатель. Сораулар бирүче булмады.

Сөйләргә Галиулла чыкты:

— Иптәшләр, бит бар эшне дә юлбашчылар гына күреп бетерә алмыйлар, безнең әле җитешсезлекләребез күп. Менә алар турында сөйләргә дә кирәк. Алар эшченең сүзенә колак салсыннар. Ул чагында безгә эшләве күңелле. Менә бу столовой турында әйтергә уйлыйдыр идем...

Башкалар:

— Әйтергә кирәк, әйтергә, — диештеләр.

— Туктагыз әле, җәмәгать, сөйләргә ирек бирегез. Миңа сүз бирелгән икән, мин сөйлим... Шул, столовойдагы ашның бер дә рәте юк. Продуктлар болай ярыйсы гына үзе, пешерә белмиләр, җәмәгать. Мин, ашаганда, эчтән генә уйлап куям: «Әй, мәйтәм, минем катын пешерсә иде бу ашны, телеңне йотар идең», — дим. Бусын примергә генә китерәм әле. Теге, ком турында инде анысы, иптәшләр, мин әйтмәсәм, башкасы әйтер иде дигәндәй.

Галиулладан соң башкалар да чыгып сөйләде. Күп кенә яхшы тәкъдимнәр керттеләр.

Бу киңәшмәгә ай дигәндә, яңа гына сузылган чуен тасмалар буйлап беренче паровоз килде. Аны вакытыннан алда эшләп бетерделәр. Тимер юл такта заводын каплаган биек тау буеннан борылып чыга. Тауның кабыргасын казып тигезләп салынган юлның бу борылмасы шундый матур. Аста әрәмәлекләр, яшел камышлары белән Якты күл җәелеп ята. Тынлык. Ара-тирә балта тавышы да күл буенда субай кагулары гына тынлыкны боза. Менә еракта, көпчәкләрен дөбердәтеп, поезд килгән тавыш ишетелә башлый. Якты күл буендагы тау кабыргасына борылып карарга да өлгерә алмыйсың, пар яулыгын сел-ки-селки, паровоз килеп чыга.

Бүген шул юлны ачу көне ялга туры килде.

Халык җыелды.

Юлның ике ягына да багана утыртып, капка сыман бернәрсә ясап куйганнар. Аның башында Кызыл байрак җилферди. Юлга аркылы тасма сузылган.

Тантаналы митингны баш инженер Рейд ел ачты. Ул:

— Иптәшләр! — дип сүз башлады.— Бу — безнең җиңүләребезнең беренче адымы. Такта заводыннан сузылган җиде километрлык юл тармагы эшчеләрнең, инженер-техник көчләрнең зур тырышлыгы аркасында вакытыннан алда төзелеп бетте. Бу тимер юл тармагы безгә бик күп ярдәм итәчәк. Бу юл буенча станца өчен кирәк булган заказлар киләчәк. Юлның әһәмиятенә озак тукталып тормыйм, чөнки барыбызга да билгеле. Тик монда, иптәшләр, гади бер эшче Биктаһиров тарафыннан ясалган тәкъдимнең безгә никадәрле файда китергәнен генә әйтеп узам, тимер юлның аскы полотносын салганда, безгә бик күп күләмдә елга комы кирәк иде. Без комны ерактан китертергә уйлаган идек, һәм бу Мәскәүдән килгән проект буенча да шулай билгеләнгән иде. Казып чыгарылган комны файдалану мөмкинлеген җир казучылар артеле башлыгы килеп әйтте. Анализлардан соң ком яраклы дип табылды. Без бу тәкъдим аркасында кырык биш мең сум экономия ясый алдык. Шуңа күрә мин үз ягымнан Биктаһировны биш йөз сумга бүләкләү турында төзелеп! өчпочмагында тәкъдим ясадым, һәм бу кабул ителде.

Халык бердәм кул чапты.

Кайсыдыр Галиулланы табып килде. Аны, «ура» кычкырып, һавага чөеп алдылар.

Баш инженер, кызыл шнурны кисәр өчен алып килгән ялтыр кайчыны тотып:

— Безнең юлны салуда күп кенә экономия ясаткан иптәш Биктаһировка бирәм кайчыны, — дип, Галиуллага сузды.

Биктаһиров кызарган, оялган хәлдә кайчыны алды да шнур буена ук килеп җиткән паровозга юл ачты.

Көпчәкләрен әкрен генә әйләндереп, тимер рельслар буенча беренче паровоз алга кузгалды.

Музыка җиңү көен уйный башлады...

**Хат**

Көннәр салкынайта башлады. Якты күл буендагы өянкеләрнең яфраклары саргайды. Бертуктамый яңгыр сибәли. Болытлар кояшның нурлы йөзен каплаган, әйтерсең инде ул бер дә чыгачак түгел. Кичләрен ай да күренми, йолдызлар да җемелдәмиләр...

Шундый яңгырлы төндә Якты күл буендагы «Светог-рэс» төзелеше, кара-кучкыллы булып, караңгылыкны ерта. Механический цехта бертуктамый тимер чыңлый.

...Иртә белән көн аяза башлады. Төзелешнең яңа гына куйган гудогы иртәнге сәгать җиде тулганлыкны белгертте. Бетонщик л ар бригадасы гадәттә гудокны көтеп тормый. Алар, кешедән алда килеп, ун замес биреп тә өлгерәләр.

— Ну, җегетләр, бүген рекорд көне, — диде Сабир. Һ.әр көн сүз шулай башлана, ләкин рекорд алырлык

биш йөз замес бирә алган бер генә көн дә юк әле. Теге ун сәгать эшләгән көннәрдә алты йөздән узган чаклар булды. Ә хәзер алар сигез сәгать кенә эшлиләр. Кичә дүрт йөзгә биш кенә тулмады, аннан алдагы көнне дүрт йөз егерме икене санадылар. Ә биш йөз цифры ударникларның алга куелган идеаллары булып тора. Ныграк куалый башласаң, киртәләр килеп чыга. Моторист: «Мотор кыза», — ди, биргән замесканы күтәреп өлгертә алмый, йә чуерташны юып өлгертмиләр. Шуңа күрә дә Сабир бүген үзе чуерташ юучыларны кызулап торачак, инженерга әйтеп, мотористның «кнопка»сын бераз басачак. «Бүген ни булса да була. Биш йөзсез туктау юк! Салкыннар якынлаша. Тизрәк бетон эшләрен бетереп калырга кирәк...» — дип уйлый ул.

— Ну, җегетләр, бар көчегезне аямый, биш йөз өчен көрәшкә! — диде ул. — Җиңеп чыксак, биш мең сумлык бүләк безнең кулда булачак. Җиңеп чыксак, көзге салкыннарга кадәр бер атна эчендә барлык бетон эшләре бетә дигән сүз.

Аның иптәшләре дәртләнеп эшләүләрен дәвам иттеләр. Сабир чуерташ юучылар янына барганда, аның артыннан берәү куып җитте. Караса, Галиулла икән.

— Мә, сиңа кемнәндер хат бар! — дип, Галиулла зәңгәр конвертны Сабирга сузды.

Галиулла хатның кемнәнлеген белим инде дигән сыман тукталып калган иде, ләкин Сабир конвертны күкрәк кесәсенә тыгып куйгач:

— Мин булсам түзмәс идем, һич түзмәс идем укымыйча, — дип куйды.

— Вакыты ул түгел, әле ашыгам, бик ашыгам, — диде Сабир.

— Кая алай ашыгасың?

— Әнә шул чуерташ җыючылар аптыраттылар инде, шулар хакында рекорд биреп булмый.

Сабир, сөйләнә-сөйләнә, эре адымнар белән алга атлады.

Озынча, иләк сыман итеп ясалган чуерташ юдырткыч бертуктамый янга таба сикереп тора. Аның өстеннән, түтәлләргә су сибә торган лейка борыныдай, водопровод трубасыннан су сибелә.

Зур тимер көрәкләр бертуктамый шул иләккә чуерташ ыргыталар. Эш кызып бара. Бүген ни өчендер бераз үзгәреп: туган. Моны Сабир соңыннан сорашып белде. Кичә артель булып эшләгән эшчеләр бүген бригадага әйләнгәннәр. Алларына «Бетонщикларга тоткарлык ясамаска!» дигән бурыч куйганнар.

Бригадир, алгарак чыгып, Сабирны каршы алды:

— Тагын сүгәргә килә торгансыңдыр инде?

— Тукта, килеп җитим әле. Бүген сездә Нух темпын большевиклар темпы алмаштырган кебек күренә. Молодцы, иптәшләр.

Бригадир, Сабирга карап:

— Алаймы? — диде.

— Болай булгач, минем монда хаҗәтем юк икән, — дип, Сабир тарту мәйданына таба юнәлде.

Аны бригадир куып җитте:

— Тартырга бармы?

— Юк, мин бит тартмыйм.

Тарту мәйданында беркем дә юк иде. Сабир түзмәде, эскәмиягә утырып, кесәсеннән зәңгәр конвертны чыгарды да аның читен буйдан-буйга ертты. Эчтән ярты табак чамасы кәгазьгә язылган хат килеп чыкты. Хат Разиядән иде.

*«Сабир!*

*Син инде артык эшле кеше, муеннан эшкә чумгансың да һаман шул бригадаң... әлегә кадәр колак ишетмәгән, күз күрмәгән темп тудыру, рекорд алу өчен тырышасыңдыр. Тырыш, тырыш, өстен чык. Мин шул теләктә.*

*Менә мин дә шулай итеп интеллигентлашып киттем инде. «Безнең Миләүшә, безнең Миләүшә...» — дип, ике сүзнең берендә кыстыра торган Миләүшәңне күрә алдым. Авыз суыңны корыта торган Миләүшәңә мине укытырга билгеләделәр. Син укыган җидееллыкта хәзер зав булып эшлим.*

*Белсәң, беркөнне шулай читтәге партада утыручыга күзем төште. Күземне тутырыбрак карадым, әллә синең күләгәң чагылгандай булды. Барысының да фамилияләрен белеп бетерми идем әле. Укучымның фамилиясен сорасам, Салахов, диде. Сораша торгач, ул синең энең булып чыкты... Шулай итеп, энең миндә укый, миндә тәрбияләнә.*

*Хәзер безнең мәктәп сез «йодрык» чыгарып йөргән Сафин мәктәбе түгел. Ул бөтенләй башка, төбе-тамыры белән үзгәргән...*

*Мәктәптән ерак түгел урында мастерскойлар ачып җибәрдек. Бердән, китапханәнең, уку йортының барлык китаплары төпләнсә, икенчедән, балалар үзләре эшкә өйрәнеп үсәләр. Мәктәбегез җидееллык түгел хәзер, ШКМга әйләндердек, яңа кыр белгечләре, агрономнар әзерләп ятабыз, аңлы колхозчыларның санын күбәйтәбез. Механический мастерскоебыз бар, ләкин әлегә өйрәтерлек кешеләребез юк — бик аптырау. Вакыт-вакыт: «Әй, Сабир монда булса иде», — дип куям. Син шул болторез станогың белән бергә күз алдыма килеп басасың. Дөнья кадәр иген кораллары, машиналар төзәтергә кирәк. Менә шулай политехнизацияне тормышка кертеп ятабыз. Син, бәлкем, станцаны ходка җибәргәч, кайтып әйләнерсең әле дип уйлыйм.*

*Ие, Сабир, сез кайчан инде ул «кояшыгызны» кабызырсыз? Монда да аны өзелеп көтәләр. Кайсылары инде синең турыда әкиятләр дә чыгара башлаганнар. Имештер, шәһәрдә салына торган станцага Германиядән инженер китерткәннәр. Шулар булдыра алмаган нindидер бер әйберне аларның Сабирлары булдырган. Нимесләр башларын селкеп шаккатканнар да синең кайсы, авылныкы икәнлегеңне, исем-фамилияңне язып алганнар, ди. Германиягә чакырып аптыратканнар, ди... Кыскасы, синең монда, малай, почет зур. Тизрәк кабызыгыз инде ул «кояшны», крестьяннар бит ул утларның кабынуын дүрт күз белән көтәләр. «Миләүшәгә дә якты китереп булмас микән?» — диләр алар.*

*Җәмәгать эшләреннән күп нәрсә юк. Сельсовет члены булгач, утырышларын калдырмаска туры килә. Килеп тә җитә алмадым, сайлап та өлгерделәр үземне. Хәзер икмәк әзерләү бик кызу бара. Эш муеннан.*

*Галиуллага сәлам диген. Аналары исәннәр. Анасы: «Улыма ярты мең награт чыга икән», — дип, авыл буена сөйләп йөри, ди.*

*Синең атаңны күрдем. Гаҗәп, ул сиңа һич-һич охшамаган, һәм син аңар охшамагансың. Аның кулыннан стакан төшми, алкоголикка әйләнеп бара, диләр. Анаң бик йомшак күңелле — ул миңа ифрат ошады. Синең хакта сораша да җылый, аннан бөртекләп сарайга: «Анысы да шәһәргә китеп азып-тузып йөри күрмәсен...» — ди.*

*«Юк, — мин әйтәм, — ул эчу түгел, тәмәкене дә авызына якын китерми», — дигәч, карчык шатлана.*

*Миңа хәзер синең авылдан ничек китүең бик аңла-шыла, һәм синең алай эшләвеңне дөрес дип табам.*

*Нашимов бу арада авылда йөри. Ник кайтканы билгеле түгел. Көн дә синең атаңнар белән җыелып эчәләр.*

*Вафага сәлам әйт. Каһәр малай, ул бит, ахрысы, юлдан яза. Сабир, шуны кеше итеп булмасмы икән? Инде комсомолдан да ычкынды...*

*Шәһәр хәбәрләренең барысын яз. Мин киткәч, нинди яңалыклар булды — берсен дә калдырма. Бик озын яз, укып туярлык булсын.*

*Ярый, хуш. Адресым сиңа билгеле.*

*Коммунистлар сәламе белән Разия.*

*5. X. 1930, Миләүшә авылы».*

Сабир хатны бертын белән укып чыкты. Шәһәрдә эшләгәннән бирле аның мондый хатны беркемнән дә алганы юк иде. Дөрестән дә, бу хат аңар ошады.

Хат өстенә алынган числосын язып куйды да, бөкләп, кесәсенә тыкты. Үзе, Разия турында, кечкенә энесе Галим турында, атасы турында уйлый-уйлый, алга атлады. Сабир бетонщиклар янына килеп җиткәндә, кояш инде төшлеккә авышкан, алар инде ике йөз илле биш замес ясаганнар иде.

«Ике йөз илле биш. Төшке ашка кадәр өч йөз, төштән соң ике йөз. Биш йөз дигән сүз», — дип уйлады ул. Аның күңеле хәзер гаҗәп күтәренке иде.

Өлгергән бетон күтәрү ковшына шаулап коелды. Билгеләп торучы тактага акбур белән тагын бер билге сызды. Ике йөз илле алтынчы замес труба буенча шаулап ага башлады. Эш кызып барганда гына, моторист эшне бүлде:

— Булмый, мотор кыза.

Кызган мотордай, Сабир да кызды. Ул, әүвәл барып, моторны кулы белән тотып карады. Дөрестән дә, мотор кызган иде.

— Кызсын, давай җибәр, үзем җавап бирәм, — диде.

— Юк, мин җаваплылыкны үз өстемә ала алмыйм. Мотор бәһасен бер ел эшләп тә түләп бетерә алмассың...

— Бар кит, җибәрмәсәң, үзем җибәрәм. Син менә бетон күтәрү ковшын төшерүгә, без тәмәке тарткан арада моторны тик тот...

— Ну, ярый, ни булса, шул була, җибәрәм, — дип, моторист та күнде.

Кичкә таба, гудок булыр алдыннан, инженер Гуревич төзелеш эшләрен тикшерергә чыккан иде. Ул бетонщиклар бригадасының эшләвен карарга да кагылды. Шунда билгеләп торучы малайга барып:

— Ничәнче замес? — дип сорады. Аңар:

— Биш йөз икенче, — дип җавап бирделәр. Әле бетон бутагыч һаман бертуктамый әйләнә, калай труба аша цементка укмашкан чуерташлар коелалар иде...

**Инженерлар**

Инженер Гуревич үзе хакында зур фикердә иде.

Маңгайга җыерчыклар салган еллар, дөрестән дә, аның эшләгән саен практика багажын арттырдылар. Бу инженер үз гомерендә күп нигезләр, шулар өстенә сансыз кирпечләрдән өйләр, пулатлар өйдерде, һәр яңа йорт баш калкыткан саен, аңар җиңү бәйрәме килде.

Ул бүген ниндидер бер чертежны җентекләп утырадыр иде. Ишектән артельщик Галиулла күренде. Башта Гуревич аны күрмәмешкә салынды. Бүреген култык астына кыстырган Галиулла, борынын тартып кына, бүлмәдә үзенең барлыгын белдерде. Гуревич, күзлеген төзәткән булып, керүчегә карады да:

— А-а, Биктаһиров, әйдә утыр, — дип, буш урындыкка ишарә ясады.

— Ничево, басып та торырбыз, — диде Галиулла.— Вот эш нәрсәдә бит, иптәш Гуревич, эшчеләр бик зарланалар, эш киемнәре юк бит.

Гуревич җилкәләрен өскә таба күтәрде дә:

— Юк бит әлегә, килеп җитмәгән, сез аңлыйсызмы шуны?

— Аңлыйбыз да бит...

— Аңлагач?

— Кияргә кирәк бит.

— Ярый, мин менә хәзер сезгә чабаталар яздырып торам. — Ул, ишекне ачып, десятникка кычкырды: — Мусин, Биктаһировка чабата яз әле!

Галиулла чабата яздырыр өчен чыгып китте.

Гуревич тагын ялгызы калды, кулындагы чертежны өстәл кырыена куеп, уйга чумды... «Ул быел җәй көне отпуска да алмый калды бит. Нинди кызганыч...»

Ул, уйларыннан бушанырга теләгән кебек, ашыгып кына чыгып китте.

Тышта колак яфракларын чеметә торган салкын кыш көне иде.

Соры сукнодан тегелгән кыска гына пинжәк американ ялтыр балтырлы итекне, билгеле, каплап җиткерә алмый. Аның балтырлары, аякка шып ятып ялтырап, инженерның кыяфәтенә тагын да матурлык, тагын да ыспайлык өстиләр.

Юлда ул баш инженер Рейдел белән бер төркем халыкның Якты күл буена табан төшеп баруларын күреп калды. Төркемдәге бобрик пальтолы бер кешедән башкалары бары да Гуревичка таныш иде.

Бобрик пальтолы таныш булмаган кеше белән Гуре-вич, бәлкем, кызыксынмаган да булыр иде, ләкин аның күп вакыт баш инженер тирәсендә әйләнүе аның кемлеген белергә теләүне арттырды.

Ул уен җыя алмыйча торган Столяровка табан якынлашты да, аның колагына иелеп:

— Николай Иванович, теге бобрик пальтолы кем ул, центрданмы әллә? — дип куйды.

Дөрес, центр дан дип әйтү бобрик пальтолы кешегә артыграк бәһа бирү кебек тоелды аңар. Чөнки, бердән, пальто бик таушалган, студентныкына охшап калган, икенчедән, галошлардагы ертык кырыйлар да аның күзенә бәрелгәч, яшь егетнең андый ук зур кеше була алмаслыгын кычкырып торалар иде шикелле.

— Юк, яңа пешкән совет инженеры, татардан, — диде Столяров.

- М-м, — дип, Гуревич ис китү кыяфәте белән бер генә карап алды да мәсьәләне артык сузмады. Аныңча, шул начар киемле татар малаена инженер исемен бирү ничектер килешми, ул инженер дигән югарылыкны бөтенләй югалта кебек тоелды. Үзе белән бертигез права бирү, баш инженерның аңар зур игътибар күрсәтүе, яңа кешегә кулларын бутый-бутый аңлатуы, аныңча, бары да артык булып тоелдылар.

Әле хәзер генә булган инженер-техниклар киңәшмәсе Якты күл су алгыч коесына кертмичә генә җир эшләрен эшләү өчен буа ясау проектын кабул итте. Бу проектны Булатов эшләгән иде.

Менә шул проект буенча буа эшләнәчәк урынны инженерларның бары да карарга чыкканнар.

Барыннан да битәр бу авыр эш турында Булатов үзе күп кайгыртты. Дөрес, өстән генә карасаң, бу эш җиңел дә кебек. Нәрсә, буе унике метрлы, иңе шуңардан ким булмаган бер мәйданчык. Шуны, кыш булуга, туңган балчык булуга карамастан, язга кадәр эшләтеп бетерергә, дүрт мең кубометр җирне бер ай эчендә актарып ташларга, тирәли карлыгач койрыгыдай итеп шпунт кагарга, коперлар көйләтергә һәм су алгыч коесы әзерләп, бетон-щикларга тапшырырга кирәк. Алга куелган бурыч шулар иде.

Су алгыч салыначак урынны тикшергәч, төркем конторага кайтып китте.

Булатовның күптән инде конторага кереп чыгасы бар иде. Ул «Комсомол ячейкасы» дигән язулы ишекне ачты.

Ячейка секретаре Адушкин әллә нинди кәгазьләр эченә баткан иде. Тегеннән комсомоллар турында исемлек сорыйлар. Әле бер прораб, үз участогындагы комсомолларның санын, фамилияләрен белергә теләп, ячейкага отношение җибәргән. Цех җитәкчеләренә юллар күрсәтергә, сәяси мәктәпләр өчен дәреслекләр, җитәкчеләр табарга кирәк. Барысын да җыеп әйткәндә, шул «Светогрэс»ның ике йөз илле кешелек комсомол коллективы өчен Адушкин җавап бирә. Бер комсомол прогул ясаса, Адушкинга киләләр, воздействие ясa, диләр. Тегендә партиясез яшьләр эчеп сугышканнар, комсомол аң-белем эшләрен җитәрлек алып бармый, икенче урында ташчыларга эш юк, цемент беткән, тагын комсомолга чабарга, эчке мөмкинлекләрне файдаланырга, күрше оешмалардан бурычка цемент сорарга, баракларны тикшерергә, заказлар турында завод ячейкаларына хатлар язарга кирәк.

— Гафу итегез, комсомол ячейкасы секретаре сез буласызмы? — диде Булатов.

— Әйе, мин булам, — диде Адушкин, күтәрелеп карамыйча гына, кәгазьләр арасында актарына биреп.

— Миңа учетка керергә кирәк иде, — диде яңа кергән кеше.

Адушкин урыныннан күтәрелде, янында утыручы тех-секретарь Сәлимәне эзләде.

— Ул кешебез каядыр чыгып киткән икән шул... Ярый, мин үзем генә эшләрмен, — дип, өстәл тартмасыннан таушалып беткән бер исемлек чыгарды.

— Фамилиягез?

— Булатов.

— Чыгышыгыз, туган елыгыз?

— Эшче. 1908 ел.

— Кем булып эшләргә килдегез?

— Инженер-гидротехник.

Адушкинның күзләре зурая төште. Ул каршындагы кешегә урындык бирмәвенә дә уңайсызланды... Тәкъдим итмәкче иде, ә инде ул арада Булатов үзе, урындык алып, өстәл янына утырды. Кесәсеннән портсигарын чыгарды да секретарьга таба сузды:

— Рәхим итегез!

Адушкин бер папирос тартып чыгарды. Алар сүзгә керештеләр:

— Бирегә кайдан килдегез?

— Мәскәүдән. Яңа гына укуны бетереп чыктым.

— Безгә нинди эшкә килдегез инде?

— Гидротехника эшенә, специальностем буенча. Инженер Булатов ачык кеше иде. Ул Адушкиннан

комсомол эшенә ни рәвешле куелуын сорашты. Адушкин алдагы бурычларны санап чыкты.

— Менә безнең инженер-техник көчләр арасында комсомолларыбыз юк иде. Сезнең килү безгә зур шатлык. Менә хәзер техпропаганданы эшләргә кешеләребез юк, ә эшчеләр моңар бик сусыйлар.

Алар шундый мәсьәләләр турында шактый сөйләшеп утырдылар. Кинәт инженерның исенә ниндидер мөһим нәрсә төште, ул, сискәнеп, урыныннан торды.

— Ярый, хәзергә хушыгыз, мин ашыгам.

...Булатов нинди генә уйлар уйламады: менә институт, сыйныфтагы иптәшләре белән дәрес укулар, уен-көлке, мәктәпне ничек кенә булса да тизрәк бетереп чыгарга омтылу, чыгарылып: җыелышы, анда сөйләнгән сүзләр, анда бирелгән вәгъдәләр...

Хәзер менә шунда алынган белемнәрне тормышка ашырырга кирәк. Шул белемнәр әз, практик эшкә ябышырга җитәрлек түгел кебек. Күңелдә әллә нинди эчпошыргыч курку да бар.

Ишектән чыгуга, зур корпуслары белән станца күренеп тора. Бетон баганалар, тирәли арматура тимерләре, цементтан бушаган мичкәләр, тоташтан өелгән чуерташ тавы, аяк астында бөгәрләнеп яткан йомычкалар, вагонеткалар, йөрер өчен тар рельстан салынган юллар... — әйтерсең ул алар арасында югалып калды. Тачкалар тоткан эшчеләр, маңгай тирләрен киндер күлмәкләренең җиңнәре белән сөртүче җир казучылар Булатовны Якты күл буена кадәр озатып калдылар.

Якты күлгә кертелеп казылачак су алгыч коесы инженер Булатовның эшләү участогы иде.

Кыш көне җир казу эшләрен үтәү җиңел түгел. Шул җирне казу эшенә башлап Галиулла бригадасы тотынды. Булатов эш урыныннан үзе дә көннәр-төннәр буе китми торган булды, күп вакыт конторда гына кунды.

...Чабаталары белән кар өстендә сырлы эз калдыра-калдыра, җир казучылар су алгычны казыр өчен чәчелгәннәр.

Су алгыч янына ук комсомоллар «Кызыл такта» белән «Кара такта»ны китереп урнаштырганнар. Тактага электр лампочкасын беркеткәннәр. Андагы «Кызыл такта»дан түбәндәге сүзләрне укып була:

«Хезмәт дисциплинасын югары дәрәҗәгә җиткергән һәм эшләп чыгаруны 140 % ка җиткергән өчен элеккеге бетон-щиклар — Салахов бригадасы «Кызыл такта»га язылa».

...Төнге 12 булуга карамастан, су алгыч җанлы. Хәзер яңа смена килгән. Арыганнар йокларга китәләр.

Ләкин Булатов әле йокларга китми. Ул әле, яңа килгән сменаны ныклап урнаштыргач кына, Якты күл буеннан кузгала. Төнге сменадан кайтышлый, ул һаман уйлана: «Норма буенча эшчеләр андый туң җирне берәр кубометр эшләргә тиешләр. Шулай эшләгәндә дә, утыз өч көнгә тартыла. Ә эшне ун көннән артыкка сузмыйсы иде...»

Иртәгесен тагын көндәгечә таң атты. Көндәгечә, портфельләрен күтәреп, хезмәткәрләр эшкә чыктылар. Гуре-вич та кешеләр белән беррәттән эшкә килде.

Гуревич инженерлар арасыннан икеләнүчеләр төркемендә иде. Ул әле Совет властен чынлап торып аңлап та җиткермәгән, аңар каршы торып корткычлык та эшләми. Ләкин аның болай нейтраль торуы күпләрнең эчен пошырды.

Ул үзе дә моны сизде.

Революция елларында Гуревич саботажчылар сафында булды. Мәскәүгә якын урында паровозлар эшли торган завод салына иде. Власть советлар кулына күчкәч, төзелеш халыклаштырылды. Беренче булып Гуревич төзелешне ташлап качты. «Совет власте белән эшләп буламы соң, мин рабочийлар рәтеннән ничек жалованье алыйм, мин прежде всего инженер...» — диде ул.

Гуревич куркынган иде. Имеш, коммунистлар хезмәтнең барысын да бертөрле итеп исәпләячәкләр. Эшчегә күпме түләнсә, инженер да шулкадәр алачак. Ләкин алай булып чыкмады.

Соңыннан ул, үзе дә сизмәстән, совет эшенә бирелеп китте. Ул болай булды. Аклар гаскәре ул торган шәһәрдән чыгып кына киткән иде. Армия штабына вакытлы эшкә инженер кирәк булды. Гуревичның бер иптәше аны тәкъдим итте.

Комиссар белән икәүләп алар урта киңлектә булган елга буена атладылар.

Дошман гаскәре качкан чакта күперне ваткан. Бүрәнәләр тәртипсез рәвештә, башларын суга тидергән килеш, кое сиртмәседәй, кайсылары башларын һавага күтәреп кадалганнар...

— Шуны гаскәр чыгарлык итеп ясарга ничә көн кирәк булыр? — диде комиссар.

Гуревич кызып сөйләп китте:

— Менә прогоннары яраклы түгел, насадкаларын алмаштырырга кирәк, субайлар артиллерия үткәрә алырлык түгелләр... Расчет ясыйсы бар. Һәрхәлдә, бер атнада өлгертеп булыр.

— Бер атна?!

Комиссар кылыч сабына бәреп куйды:

— Өч көндә минем армиям елганың теге ягында булырга тиеш. Өч көн срок!

Гуревич шул минуттан алып эшкә тотынды. Барлык армеецларны җикте. Көн эшләделәр, караңгы дип төнне дә эшләмичә калдырмадылар. Күп кыенлыклар белән күпер өлгерде...

Өстәл артына утырып шул үткән хәлләрне уйлаган Гуревичның вөҗданы газапланды. Ул ишекне ачып бүлмәсеннән чыкты. Алгарак бара төшкәч, ак буяулы, җиз тоткалы ишек күренде. Гуревич шул ишекне шакый башлады. Эчтән:

— Пожалысты, мөмкин, — дип кычкырган тавыш ишетелде.

Алар бик шәпләп куллар кысыштылар.

Өстәл артында утыручының кулында телефон трубкасы иде. Ишектән керүчегә ул ишарә белән урын күрсәтте. Гуревич күрсәтелгән урынга барып утырды.

Булатов телефон трубкасын элеп куйгач, Гуревич сүзен башлады:

— Вот, иптәш Булатов, сиңа бер киңәш бирергә килдем, шаять, ачуланмассыздыр бит?

— Пожал ысты, пожал ысты, — диде Булатов.

— Сезнең бит җир эшләрегез бик әкрен атлый.

— Әлегә шулайрак шул.

— Шартлату юлы белән алдырсагыз, ничек булыр икән дим.

Ул үзенең Мәскәү янындагы паровозлар заводын төзегән чакта кыш көне җир эшләрен шартлату юлы белән алып барганлыгын сөйләп китте.

— Менә шул хакта хәзер генә саперлар ротасы белән сөйләшеп алдым әле. Иртәгә шартлатырга кил мәкче булдылар.

Гуревич, исе китмәгән сыман гына итеп:

— Беләсез, бик нык саклык белән эшләргә кирәк, — Диде.

Алар озак утырмадылар. Гуревич, урындыгын тавыш белән кузгатып, урыныннан торды. Булатов та кузгалды.

— Миңа да чыгарга кирәк. Динамит куяр өчен урыннар әзерлисе бар.

Көтелгән иртәгесе көн тиз килеп җитте.

Тышта каты булып туңган балчыкны корыч чөйләр генә җиңә алмадылар, техниканы ярдәмгә чакырырга туры килде. Динамит өчен урын кичә үк әзерләнгән иде инде. «Светогрэс»ның шефы булган саперлар ротасы су алгычта мәш килеп йөри.

Бераз вакыттан соң дөнья тетрәтерлек итеп шартлау тавышы чыгарды:

— Бух, бух, бух!

Навадан туң балчык ява. Әйтерсең ниндидер сүнгән йолдыз, үзенең әйләнү күчәреннән ычкынып, җиргә килеп бәрелгән дә, аннан аның кисәкләре җиргә коелалар.

Җир тузаны кире үз урынына ятты. Тирә-як ачык булып күренә башлады. Тузан пәрдәсе ертылды.

Әнә эшчеләр ашап килделәр. Алар килгән җиргә өстәл-өстәл балчыклар тачкага утырып китәргә әзер булып торалар.

— Ваклабрак салыгыз, авырга килер. Галиулла өйрәтеп йөри.

Су алгычка таба киң такталардан тачкалар йөрер өчен юл салынган. Шул такталар буенча туң балчык белән тулган тачканы эткән эшчеләр узып торалар. Тимерчыбыктан ясалган ыргак белән килгән тачкаларны бер эшче карап алып тора: ул шул ыргагы белән тачканың «кабыргасыннан» эләктерә дә сөйри. Шулай иткәч, тачка йөртүчегә дә җиңелрәк була.

Бар кеше шат. Алар техникага рәхмәт укыйлар. Тимер-бетон баганалар, үскән, зурайган сыман булып, башларын калкыталар.

Бүгенге киңәшмә су нигә кирәк булачагын эшчеләргә аңлатуга багышланды.

Булатов, чәчләрен рәтләп, кепкасын киде дә сүзгә кереште:

— Иптәшләр, без су өчен көрәшәбез... Беләсезме, су ул бик үткен нәрсә. Сезнең авылларны кайвакыт булса да су басканы бардыр... Безнең станца өчен дә, башка станцаларга кирәк булган кебек, су кирәк. Су ул, төрле тазартулар, фильтрлар аша үтеп, пар казанына керә, анда парга әйләнә. Пар турбина дигән машинаны әйләндерә, ә инде үз чиратында турбина генератор дигән машинаны әйләндерә башлый. Генераторда без электр тогы хасил булганны күрәбез. Әгәр дә, иптәшләр, без шушы бер ай эчендә эшебезне бетерә алмасак, станцаны җибәрү срогы хурлыклы рәвештә артта кала бирә дигән сүз. Һәрбер эшче моны яхшы исендә тотарга тиеш...

Бу сүзләрне тыңлау белән генә калмадылар: кыска һәм каты карар чыгарылды: «Су алгычны 15 апрельгә станцаны ходка җибәрү комиссиясенә тапшырырга. Барлык җир, бетон, монтаж эшләрен шул вакытка тәмам итәргә».

Беренче апрельгә унбиш кенә көн калган. Димәк, бетон белән монтаж эшенә унбиш көн. Бу артык кыска һәм артык көч куюны сорый торган срок иде.

* * *

Рейд ел үзенең уйларын Вәлиевтән яшерми иде.

Беркөнне алар барлык эч серләрен бер-берсенә ачып салдылар. Башта Рейд ел сөйләп китте:

— Иптәш Вәлиен, менә мин үземнең эволюциямә исем китә. Уйлыйм-уйлыйм да гаҗәпкә калам... Мин менә шушы егерме еллык хезмәтемдә яңа салган корпуслар кебек яңа кешегә әйләнә барам. Башта миндә динчелек көче ифрат көчле иде. Мәктәп миңа, билгеле, атеистлыкны бирмәде. Миңа соңыннан гына хөр фикер тудырырга мәҗбүр иткән китаплар укырга туры килде, менә шуннан миндә башта икеләнү туды. Соңыннан, һаман-һаман теорияне тирәнәйтә барган саен, ул мәсьәләдә ачыклык күрә бардым...

Менә мин егерме ел инде шушы төзү эшендә. Аның унбиш елы тимер юл төзеп үтте. Биш елын электр станциясе төзү эшендә үткәрдем. Революцияне миңа Мәскәүдә каршы алырга туры килде. Беләсең инде безнең халыкны: аларның кайберләре башта саботаж ясадылар, кайберләре корткычлыкка бирелде. Ә мин шул арның өченче төрендә — нейтралитет саклаучылар ягында булдым. Дүртенчеләр кебек тиз генә Совет власте ягына кушылып китмәдем. Менә хәзерге вакытта Гуревичны белми торгансыздыр әле. Ул, минем нәкъ теге вакытымдагы кебек, икеләнү моментын үткәрә, аңар хәзер безнең яктан нәни генә толчок кирәк...

Вәлиевне бер момент кызыксындырды, ахры, ул сорау биреп куйды:

— Сезнең чыгышыгыз ничек?

— Минем чыгышым инде үзе бер роман. Минем әти үзе немец, Рур өлкәсеннән. Ул — мондагы бер төзү фирмасында эшләргә, Россиядә акча эшләп кайтырга

планлаштыручыларның берсе.Ләкин тора-бара, ахры, ул планнан кире кайткан. Ниндидер бер граф кызына өйләнеп, Россиядә калган. Мин инде менә шулай ватанын югалткан, руслашкан немец... Вот, шулай итеп, мин ике милләт арасыннан килеп чыккан кеше.

— Да, ничево икән. — Вәлиев, нидер уйлаган килеш, шул сүзләрне әйтеп куйды: — Сез, алай булгач, Ефим Николаевич, тумыштан ук инженер икәнсез?

— Әллә сез талантның нәселдән күчүенә ышанасызмы? Ул дәвер миндә күптән югалды инде. Элек ул теория бик тирән тамыр җәйгән иде. Алыйк шул ук Гуревичны, мин сизәм: әле ул аңа нык ышана...

Шунда өстәл буендагы телефон шалтырады.

— Тыңлыйм! — Шул сүзләр белән Рейдел трубканы алды, аңар нәрсәдер сөйләделәр, ахры, ул, кашларын җыерып: — Да, шулай... Дөрес эшләгәнсез... Бик дөрес. Димәк, җайладыгыз, бик яхшы... Тугызларга таба... Иртәгә... Шулай... Яхшы... Хушыгыз... — Ул аннан Вәли-евкә табан борылды һәм: — Булатов шалтырата, мотор эшләми, ди. Нишләргә белмиләр. Ярый әле Салахов коткарды, ди. Күн заводындагы механический мастерскойга алып киткән. Шуның аркасында котлованны су басу куркынычы бар. Складтан тагы анда җиде ат көчле ике мотор бар иде, шул арны куярга әйттем.

Вәлиев кашларын җыерып тыңлап торды да:

— Мин китәргә уйлаган идем, әле ярый рәтләгәнсез,— дип, бераз тынычланып куйды.

Шуннан Рейдел Булатовны мактап китте:

— Гаҗәп кеше, менә дигән энтузиаст. Кирәк чакта җанын бирер, ә постын ташламас. Зур киләчәк өмет итәргә була ул кешедән. Җирле милләттән шундый кешеләрнең күтәрелүләре кирәк, бик кирәк...

Шуннан Вәлиев озак тормады, киенеп чыгып китте. Капка төбендә аны ат һаман көтә иде, төннең соң булуына карамастан, Вәлиев кучерга: «Төзелешкә!» — дип куйды.

* * *

Төн караңгы иде...

Моторист, кулындагы француз ачкычын ыргытып бәрерлек булып, насослар куйган җирдән югары күтәрелде:

— Эшләми, хет суел, обмоткалары эштән чыккан. «Ә нишләргә кирәк соң?» — дип, Булатов эчтән генә

уйлады.

Сабир да, сызгырынып, су алгычтан югары күтәрелде.

— Моторист, нигә качать итмисең? Су баса бит инде.

— Кулым белән качать итимме, әнә бит ике насос суыра, ә иң зурысы сафтан чыкты.

Булатов, ашыгып, комендатура ягына атлаган иде, ләкин Сабир, аны куып җитеп:

— Мин бернәрсә уйладым, иптәш Булатов. Хәзер менә бу эшләми торган моторны төзәттерергә кирәк.

— Ә кайда төзәттерәсең?

— Мин анысын үз өстемә алам, тик ат кына табыйк.— Ул, бераз уйлый торгач: — Анысы да булды. Ярты сәгатькә генә атны пожарниклардан да алып була, — дип куйды.

Булатов аңа үз планын үткәрергә ирек бирде. Үзе, комендатурага барып, Рейдел белән телефон аша сөйләште. Аннан складка йөгерде.

Башта ат белән складтагы ике моторны китерделәр. Сабир аннары гына, чанага ватылган моторны салып һәм биш эшче алып, төзелеш капкасыннан чыгып китте.

Күн заводының комендатурасында ул заводка керергә пропуск та сорап тормады, чөнки анда аны таныйлар иде.

Тимерче бүлегендә ут бар иде. Салахов туры шунда кагылды. Борис белән рәтләп саулык та сорашып тормады.

— Менә, иптәш Куликов, ни алсаң да ал, шушыны бүгенге таңга өлгерт, — диде.

Борис алай-болай боргаланып караган иде, Сабир тезгенне нык тоткач:

— Тырышырмын, — дип куйды. «Анархистларың да ударникка әйләнәләр, дөньясы

әйләндерә шул!» —Төзелешкә кайту юлында Сабир шулай уйлап кайтты.

Өченче смена эшкә чыккан иде, ләкин казый торган урынның су астында калуы аларга эшләргә ирек бирмәде. Эшчеләр кире кайтып киттеләр.

Таң алдыннан гына складтан китерелгән моторларны җибәреп карадылар. Моторлар никтер эшләмиләр. Майга буялган сырган киемнән озын чәчле моторист юкка гына азапланды, юкка гына көч түкте, никадәр тырышса да, аларның ник эшләмәүләренең сәбәбен төшенә алмады.

Шунда ук куркынган кыяфәт белән Вәлиев килеп җитте:

- Бастымы?

Шул сүзе белән ул шелтәдән курыккан сыман торган Булатовка килде.

— Эшләр начар тора әле, иптәш Вәлиев... басып китте шул.

— Ә складтан алып килдегезме?

— Килдек. Эшләмиләр.

— Механик мондамы?

— Чакырырга киттеләр. Ләкин өченче сменага килгәннәрне мин инде өйләренә җибәрдем, барыбер тик торачаклар. Ял көне ясарга риза булдылар.

Вәлиев искиткеч бер җентекләү белән озак карап йөрде. Су алгычны өч-дүрт тапкыр әйләнеп чыкты. Насослар янына төшеп, бол ай да ашыгыч эш аркасында тирләп чыккан мотористка сораулар бирде.

Аннан, берәр сәгать үткәч, Булатовка приказ сыман кыска-кыска киңәшләр биргәч, комендатурага кереп бер эскәмиягә сузылды.

Иртәнге сәгать дүртне ул тагын аяк өстендә каршы алды.

Кабаттан озак тартышулардан соң, пожарниклардан ат ала алдылар.

Төнне Булатов кебек кенә черем итеп үткәргән Салахов янә күн заводына мотор артыннан китте.

— Сабир, төн буе җәфаландык ул синең моторың белән,— диде Борис.— Әгәр «Светогрэс»тан башка җиргә булса, һич эшләмидер идем. Яратам мин ул төзелешне.

Борисның бу сүзләрен Сабир колагына салып куйды. «Безгә таба тарттырасы иде зәхмәтне!» Шуны уйлап, бу турыда Вәлиев белән сөйләшергә карар биреп куйды.

— Иртәгә счет язарсың да безгә килерсең, иптәш Куликов. Анда түләрләр. — Сабир, моторны сала-сала, шул сүзләрне әйтте.

Борис аның артыннан чыкты да:

— Начальнигың белән сөйләш әле, моннан согласовать итеп, мине күчерсен инде, — диде.

* * *

Борисның «Светогрэожа күчүен Вәлиев алкышлап каршы алды. Күн заводы белән бу мәсьәләне җайга салды. Шул көннән башлап тимерче Борис Куликов «Све-

тогрэс»ның яңа оешып килә торган механический мастерскоен юлга салырга тотынды.

Бар эшчегә, баш инженерларга караганда да эшнең иң авыр өлеше Вәлиевкә төште. Ул караңгы төн урталарында бик арып өенә кайткач та, өстәл өстенә портфеленнән зур блокнотын алып куя торган булды. Аш ашаган чакта да, чәй эчкән вакытта да ул һаман өстәлдә ятты. Ул иртәгә ниләр эшләргә кирәклек турында билгеләр ясау өчен иде.

Хатыны аны бу вакытларда төрле сораулар биреп һич йөдәтми, кооперативларда нинди ефәк күлмәкләрнең кайтканлыгын, иртәгә театрда кызганыч драма булачагы турында булсын — бервакытта да аны һич андый мәсьәлә белән комачауламады, болар бары да ял көненә карплы яки ял иткән көннең иртәгесен сөйләнә торган сүзләр иде.

Вәлиевнең шул төзелеш эшенә муеннан батканлыгын хатыны бик яхшы белә иде.

Ләкин ялгыз калган көннәр аңар бик җайлы булмадылар. Аның күңелен эч пошу басты. Ул һаман-һаман йөрәгеннән сызланды, ләкин иренә бу турыда әйтергә батырчылык итмәде. Әмма ул бу хәлдән котылу юлын үз башы белән исәпләп тапты. Ире дә аның бу юлына каршы килмәде. Хатын балалар бакчасы мөдире булып эшкә керде.

Алар иртә торып эшкә киттеләр. Кич ул ireннән ал-данрак кайтты. Көн аңар хәзер күңелсез тоелмады. Иркәләнүләр, җылы кочаклар турында уйлауны да онытты.

...Бүген дә Вәлиев ашыгып кайтты. Хатынына чәй алдында гына үзенең иртәгә кая барачагын сөйләп бирде.

— Каман шул пар казаннары җөдәттеләр инде, — диде ул.— Иртәгә мин иртәнге җиделәрдә шулар хакында Мәскәүгә очам.

«Очам» сүзенә әле колак күнеп бетмәгән иде. Шуңар да ул үзенә генә хас махсус бер яңгырау белән ишетелде.

Иртәгесен Вәлиев Мәскәүгә очты.

...Мәскәүдә аңар шактый чабарга туры килде.

Турбина белән генераторга Германиягә заказ бирелгән иде. Семмервальдд фирмасы әллә кайчан ал арны урнаштырып китте. Хәзер бар эшкә куркынычлык китергән, комачаулык ясаган нәрсәләр — пар казаннары. Сталин исемендәге Ленинград металлургия заводы «Светогрэс» өчен кирәк булган пар казаннары әзерләүне үз өстенә алды. Ләкин завод заказлар белән артык күмелгәнгә күрә, аңар өлгертү, билгеле, авыр иде. Металлургия заводында батырларча эш күрсәтергә туры килде. Ләкин шуларга карамастан завод өлгерә алмады.

Вәлиевкә бу турыда бик күп урыннарда, зур кешеләрнең кабинетларында булырга туры килде.

Поездда кайта-кайта да Вәлиев һаман шул пар казаннары турында уйлады, чөнки ал арның төзелешләрен ул яхшылап белеп бетерми иде. Шуңа күрә аңар төннәр буе «Пар казаннары» дигән китапны актарырга туры килде.

Мәскәүдән кайткач, ул металлургия заводын телеграммалар белән йөдәтеп бетерде. Ләкин завод дәшми иде.

Менә ул пар казаннарының юлга чыгуы турында телеграмма алды. Шул телеграмманы укыгач, иркен сулап куйды.

**Вакытлы буа**

Төн караңгылыгы сыекланды. Әкрен генә карны ашый торган язгы таң җиле исте. Кояш чыгышы ягыннан кызыллык беленде.

— Давай, коралларны җыегыз!

Брезент киемнән яр читендә торган урта буйлы, колаклы бүрек кигән кеше шулай кычкырды. Су алгыч өчен казыла торган чокырга, бу команда бирелүгә, җанлылык керде. Тиз хәрәкәтләр белән көрәкләрне, ломнарны, корыч чөйләрне, носилкаларны җыя бантладылар. Көрәк чыңлаган, кешеләрнең сөйләшкән тавышлары иртәнге тынлыкны боздылар.

Су алгыч хәзер шактый тирәнәйде, инде туң җир алынып бетте. Хәзер бәке сыман тишекләрдән кайнап-кай-нап чишмәләрнең чыгуы күренде.

— Ай-яй, төшеп китсәң!

Көрәк сабын кайнап чыгып торган чишмәгә тыгып караучы Булатов шул сүзләрне кешегә ишетелер-ише-телмәс кенә мыгырдады.

Хәзер чокырдагы балчыкны тачка белән ташу мөмкин түгел иде. Булатов механикалаштырылган күтәрү ков-шы ясау турында уйлады.

Иртәгесен механический цех ике сәгать эчендә механизмны ясап та өлгертте. Күтәрү ковшына вагонетка ящигын куйдылар. Ул ике тимер рельс буенча корыч аркан белән югарыга сөйрәлде.

Бер күтәрүдә бер вагонетка балчык чыга. Чыгарылган балчыкны тимер юл буенча Якты күлнең ары башына кадәр илтәләр. Ул ара да булмый, икенче вагонетка килеп җитә...

Сабир бригадасы китүгә, аның урынын Галиулла бригадасы алды.

Әнә тирән чокырда бригада мәш килә. Чишмәләрдән кайнап чыккан су хәзер чокырга җәелә башлады, куелган насослар гына ул кадәр суны суыртып өлгертә алмыйлар. Хәзер чабата белән эшләү дә мөмкин түгел.

- Кыш көне тездән суда эшлә әле, аяксыз калуыңны көт тә тор...

Бригада эчендә шундый сүзләр ишетелә башлады. Сүзнең куерганын көтеп торган Вәлүк ялгап куйды:

— Теләсәң нишлә, Галиулла, иртәгә болай булса, эшкә чыга алмыйм, канатым.

Галиулла кашларын җыерды:

— Ударникмы әле үзең?

- Ник, ударник булса нишләгән? Яланаяк эшләргә ударник булып язылмадым мин.

Булатов та бу сүзләрне читтән генә ишетте, ләкин берни эшләргә дә мөмкин түгел иде. Заказ күптән бирелеп куелган булса да, резин итекләр әле төзелешкә килеп җитмәгәннәр иде.

Галиулла инженер янына өскә күтәрелде:

— Бу эш киемнәре, резин итекләр турында нишлибез соң инде? Бик зарланалар бит.

— Көтәбез инде, тиздән булыр, диләр, шушы араларда көтәбез.

— Көтәбез дә шул, менә су көтми. Әле әнә кайсылары иртәгә үк эшкә чыкмыйбыз дип маташалар.

— Не! — Булатов шулай гына җавап кайтарды. Бер «һе» сүзе үз эченә күп мәгънәне яшергән. Бу сүз алдагы эшкә план корырга, иртәгә кайдан булса да күн итекләр табарга кирәклекне аңлата иде.

Чокырда һаман эш кайный.

Су өстенә тактадан аркылы-торкылы басмалар салынган.

* * *

Рабочком председателе Корнишинга ашыгыч эш чыкты.

Галиулла бригадасының ун кешедән калганы берсе дә эшкә килмәгән. Култык астына сыймый торган калын портфелен күтәргән килеш, Корнишин бригада урнашкан баракларга таба йөгерде.

— Кем бутый? Бутый торган кеше булырга кирәк, — диде Корнишин.

- Алай артык бутаучы юк та... соң бит, иптәш Корнишин, үзегез беләсез, шундый шартларда...

- Беләбез инде, түзәргә кирәк, тиздән була бит, була... Ә эш шундый кызу, әгәр промах бирсәк, беттек дигән сүз. Аңлыйсыңмы, барыбыз да беттек дигән сүз...

— Шулаен ул шулай да, итекләр кайчан булыр бит алар...

Баракка барып кергәндә, эшчеләр инде торганнар иде. Идән уртасында, шома итеп ясалган ялангач өстәлләрдә, зур калай чәйнекләр утыралар. Аларның авызларыннан пар күтәрелә. Бер читтә икмәк катылары, икмәк валчыклары...

«Ничегрәк сүз башласам яхшырак булыр икән?» — дип уйлап куйды Корнишин.

— Ну, җылы була, ахры, сезнең барак? — дип, ул бер дә туңмаган кулларын янган мич каршына килеп җылыткан булды. — Ничево, һавасы да яхшы икән, — дип куйды.

Эшчеләр дә:

— Ярый торган, — диештеләр.

— Ник соң, бүген ял көне мәллә, эшкә бармадыгыз?

— Әйе, ял итәргә булдык, — дип, арадан берәү, көлемсерәп, аңа җавап кайтарды.

— Үзегездән-үзегезме?

— Әйе, тоттык та үзебездән-үзебез...

- Ярый торган эш түгел, — диде Корнишин. Шуннан эшчеләр кызып сөйләп киттеләр:

— Соң бит ничек эшлисең...

Ул аларның сүзләрен бүлмәде, һәркайсына сөйләп бетерергә ирек бирде, шуннан соң гына дилбегәне каты тотты:

— Сез монда эшләргә килдегезме, иптәшләр? — Беренче сорау шул булды.

Аңар каршы:

— Әйе, эшләргә килдек, — дип җавап бирделәр.

— Эшләргә булгач, теләсә нинди авырлыкларга карамый эшләргә кирәк. Безгә биш елны дүрт елда тутыруы җиңел генә түгел, авырлыклар-киртәләр бар. Әгәр барыбыз да шулай тик торсак, ул ничек тулыр?

Арадан берәү:

— Тулганы белән булыр, — диде.

— Ә, юк, энем, син теге кешеләр җырын җырлыйсың. Определенно котырту бу. Эшкә бармыйча, бот күтәреп яталар. Ә анда аларның инженерлары шпунт кагарга көтә. Такта өстендә, һавада бит су юктыр.

— Без бит аста, чокырда эшлибез.

— Юк шул, Булатов бүген барлык эшчеләрне шпунтка куярга уйлый. Әллә бу эшне сез үзегезгә генә авыр дип уйлыйсызмы? Әнә инженер Булатов көннәрен-төннәрен шунда уздыра. Җылыну бүлмәсендә чишенмәгән килеш ике сәгать черем итеп ала да...

— Соң бит аңар акчасын да түлиләр.

— Эш акчада гына түгел, хезмәт күрсәтүдә. Сезгә, иптәшләр, башка бригадалардан үрнәк алырга булмыймыни? Ник бетонщиклардан Салахов бригадасы эшли? Бит җир казу бетонщикларның эше дә түгел әле. Бит алар-ның да резин итекләре юк. Шушымы сезнең ударниклыгыгыз?

— Тукта әле, сүзне озынга сузма, иптәш Корнишин. Син өстә генә эшләргә дисеңме әле?

Галиулла Корнишин өчен җавап бирде:

— Әйе, өстә генә, шпунт сугарга гына.

— Соң, алай булгач, барсак та ярый, җегетләр. Корнишин да йомшады:

— Барырга кирәк, иптәшләр. Икенче вакытта болай эшләргә ярамый, безнең күмәк договор бар, сез аны беләсез.

Эшчеләр берәм-берәм киенә башладылар. Капканы чыгуга, Корнишинга туры атка утырган Бу-латов очрады. Алар күрештеләр.

— Син кая барасың?

— Шул итекләр артыннан барыйм әле дим. Корнишин, аның сүзен бүлеп:

— Мин тегеләрне күндердем, — диде.

— Күндердеңмени? Ярый, яхшы булган. Хәзер баралар, диген. Шәп, шәп.

Ат кузгалып китте. Булатов төзелешкә кире кайтып кергәндә, кич якынлаша бантлаган иде инде.

Баш инженер Рейдел белән Булатов очраштылар.

— Самый кирәк чакта килеп чыктың, — дип каршы алды Рейдел.

— Беләсең, Николай Ефимович, — диде Булатов.— Бетерәм бит мин моны, серьезно бетерәм...

— Алай да эшең начар бит. Якты күл кыса, — диде Рейдел.

Якты күл буендагы карлар да эри башладылар. Ике яклап каралып, сыерчык түшедәй булып кара җир чыга башлады. Ике копер* шпунтларның башларын рәхимсез рәвештә кыйнадылар.

*(* К о п е р — субай кагу машинасы.)*

- Доң, доңгылт-доңгылт!

Бертуктаусыз шул тавыш яңгырады.

Мотордан чыккан электр көче корыч арканга бәйләнгән бабаны чыгыр буенча югары өстери. Алар гына җитми, Булатов ашыга, су алгычны әйләндереп алган шпунт коймасын тизрәк сугып бетерергә кирәк. Шуңа күрә барлык кул көчләре дә шпунт сугарга куелганнар.

— Әйдә күтәрәбезме?

— Әйдә күтәрик әле!

— Раз взяли!

— Да еще раз взяли!

— Раз берем, два возьмем, да, һоп, еще!

Брезент киемнән, бот төбеннән резин итектән су ал-гыч чокырында шаптор-шоптыр суда йөргән эшчеләр Булатовның күз алдыннан китми торган булдылар. Йокы алдыннан күз йомганда да ул көрәк тоткан эшчеләр армиясен күргәндәй булды.

...Булатов кулындагы кәгазьне артык селкеп килә иде. Су алгыч янына җиткәч, бер кешегә дә белгертмичә генә төргәкне ачып, күзен кәгазьгә төбәде.

Галиулла Булатовның ни тикшергәнен белергә теләде, аның янына өскә күтәрелде.

Булатов, аның озын балтырлы итектән икәнен күргәч, елмаеп каршы алды:

— Менә булмас дигән идең, Галиулла, булган бит. Ну, итекләр шәпме?

— Шәбен шәп тә, бераз салкынрак.

— Билгеле, киез итек кебек җылы булмаслар инде.

— Иптәш Булатов, ни тикшерәсез?

— Менә. Монда хәзер Якты күл суы безгә эшләргә ирек бирмәячәк.

— Ә хәзер нишлибез инде?

— Менә монда кара. — Булатов бармагы белән чертежга күрсәтте: — Менә бу төштән канау буенча Якты күл суын буып куясың да, насослар суны качать итеп торалар. Менә бу якка тактадан шпунт, уртага балчык. Буаны бетергәч, язгы суга карамыйча, су алгычта рәхәтләнеп бетон эшләрен алып барырга мөмкин булачак.

Алар вакытлыча гына ясалачак буа яныннан киттеләр.

— Вот менә шушы җиргә.

— Ә такта бармы соң?

— Анысы читенрәк мәсьәлә шул.

* * *

Ләкин күп тә үтмәде, проект үзгәрде. Шпунттан ясалачак вакытлы буаны чыптага ком тутырып кына ясала торган буа белән алмаштырдылар. Чөнки такта юк, төзү эшләренә дә такта җитми иде.

Әнә инде хәзер кечкенә чыпта капларга балчык тутыралар. Ул каплар утын әрдәнәседәй өелеп менә бара. Ике кырыйда коймадай шул каплар, уртада кызыл балчыктан үзәк булачак.

Эш кызып бара. Якты күл буена таралган кешеләр бертуктамый эшләүләрен генә беләләр. Кайсы чыпта капны җилкәсенә күтәреп ташый, кайсы носилка белән балчык китерә.

Су алгычта инде күп эш калмады, аны күп дигәндә тагын егерме сантиметр тирәнлегендә казыйсы бар. Билдән су булуга карамастан, Галиулла бригадасы су белән көрәш алып бара.

Галиулла үзе дә көрәк тоткан. Ул дымлы комны көрәк белән казып ала да механикалаштырылган ковшка сала. Шулай йөри торгач, Галиулла ике аягы белән чишмә кайнап торган урынга төште дә китте. Ул чокырдан көчкә күтәрелде, киемнәреннән шарлап су ага, төсенә курку чыккан, йөзе үлектәй агарган...

Димәк, хәзер киптерергә кирәк. Кайсыдыр, аны култыклап, теплушкага алып китте. Тимер мич теплушканы шәп җылыткан иде.

Озак та тормады, куркынган кыяфәт белән Булатов килеп җитте. Ишектән керер-кермәс беренче соравы шул булды:

— Нәрсә, Галиулла, баттыңмыни?

— Булды ла шул, кадалгыры, — диде Галиулла, резин итеген сала-сала.

Булатов, блокнотын кесәсеннән чыгарып, бер язу язды да каршыда басып торган Вәлүккә:

— Складтан менә шунда язылган әйберне алып кил әле, — дип, язуны тоттырды.

Вәлүк йөгерде. Ул кайтканда да Галиулла җылынып җитә алмаган иде әле.

— Бизгәккә сабышмасам инде, — диде Галиулла. Вәлүк кулындагын Булатовка бирде. Булатов, чайпалдырып караганнан соң:

— Мә, Галиулла, бар тәнгеңне шуның белән у, — дип, бутылкага салынган бер стакан спиртны Галиуллага сузды.

Вәлүк, көлемсерәп:

— Мин аны, иптәш инженер, бензин дип торам. Әгәр спирт икәнен белгән булсам, юлда ук мин аны...

Галиулла спирт белән аякларын ышкый башлады. Вәлүк бу хәбәрне су алгычтагыларга яшен тизлеге белән җиткерде:

— Батсаң да ярый икән.

Аңа каршы:

— Ник? — дип сорау бирделәр.

— Аңа, Галиуллага, хәзер спирт бирделәр, ә ул аның белән аягын уа...

Соңгы бөктәр чыпталарны күтәреп килделәр. Вакытлы буа таудай үсте.

— Кап җитми...

Алга шул куркыныч мәсьәлә килеп басты. Моңа каршы Булатов яңа бер чара тапты. Бу бераз куркынычлы иде дә, шулай да батырчылык итте:

— Иптәшләр, менә бол ай итәбез: буаның бер төшен тарайтабыз. Аңлыйсызмы, кап җитми, кап юк, — диде дә Галиуллага таба борылды: — Ә син, Галиулла, ике көн эчендә су алгычтагы балчык эшен бетерүне үз өстеңә аласыңмы?

— Юк, иптәш Булатов, ике көн күп булачак. Бир, бер көндә бетерәм.

- Молодис!

Булатов Галиулланың кулын кысты. Эшчеләр елмаешып карап тордылар. Шул вакыт берсе Булатовны күтәреп алды. Башкалар да минут эчендә аның тирәсенә җыелдылар, аны һавага чөя башладылар.

— Әй, юкны эшлисез сез, иптәшләр. Җиңгәч, менә җиңеп чыккач, берьюлы...

Кайсыдыр шунда арадан кычкыра:

— Син җиңәргә әйткәнсең икән, иптәш инженер, була ул!

Булатов көлемсери, Галиулла эшчеләрне эшкә куша:

- Әйдәгез, туктатмагыз, егетләр.

Комга выжлап кергән көрәк тавышлары тирә-якны каплыйлар.

Мәрданша карт аска карап сүз башлый:

— Шушы буа белән бу суны тоталар дип уйлыйсызмы? Валлаһи, тота алмыйлар. Минем ич инде тегермән буаларын күп күргәнем бар. Син, Мәһди абзый, Ташлы Ярдагы Митри тирмәнен беләсеңме әле?

— Теге Петровски алпавытыныкын әйтәсеңме?

— Әйе, әйе, самый шул.

— Хәзер бит анда совхоз тирмәне.

— Соң бит совхозларга калды инде ул.

— Әйе, шул тирмәндә тирмәнче булып минем Митри дигән белеш урыс эшли иде. Мин аңар арыш тарттырырга бара торган идем. Барганда бер яртыны куенга тыга барасың. Аның шунда кечкенә генә тирмән өе бар иде. Бер хутлап җибәргәч бит ул су тирмәне әйләнә дә тора, ә без шул арада «тегене» кәгеп чыга торган идек. Менә шунда инде урысым сөйли иде: «Беләсеңме, Мәрданша, Ташлы Яр елгасын ничек будым мин, — ди торган иде. — Буаның аскы ягы — тирес катыш чыбык, ә өсте — таш»,— ди торган иде. Бервакыт юри барып карадым: ул әйткәнчә, әкият, нәкъ үзе дигәнчә. Тыңлаучылар:

— Җә, сөйләсәң, рәтләбрәк, кыскарак итеп сөйлә, — диештеләр.

— Шул инде, тирессез буып булачак түгел моны. Бу-латов әрәм була. Валлаһи, аның башы Себер китәчәк, җәллим мин аны.

— Ныклап эшләсәң, нишләп булмасын ди ул?

— Әй энем, Митри инде ул белми әйтмәгәндер. «Су ул, Мәрданша, җылан күк ул», — ди торган иде.

— Чага икән алайса.

— Ник, аптырама, чагар әле. Барысыннан да бигрәк Булатовны җәллим мин.

Көрәкләр һаман үз көйләренә балчык ташлауны, җилкәләр капчык ташуларын белделәр. Сүз бара дип эш тукталмады.

Төзелеш: яныннан сыдырылып үтә торган тимер юл буенча ерактан поезд килүе ишетелде. Поезд килгән ходка тиз арада күздән дә югалды.

Эшчеләр аны эшләгән көйгә озатып калдылар.

**Җиңәр өчен җиңелү**

Чатнама аяз төн. Җил болытларны каядыр качырып бетергән. Йолдызлар гадәттән тыш чекрәйгәннәр.

Сәгать төнге унберләр булуга карамастан, баш инженер Рейд ел белән Булатов постларны тикшереп йөриләр. Алар эшләнеп беткән вакытлы буаны барып карыйлар — анда берни дә юк. Тик Якты күл дулкыннары гына комсызланалар, гомерләрендә күрмәгән сыман, буа читендәге балчыкны кимерәләр.

Җил күл буендагы яфраксыз өянкеләрне шаулатып, ачуланып үкерә. Дулкыннар бер-берсен куып мәш киләләр...

Ике инженер тыныч кына, җиңүчеләр кыяфәте белән мәһабәт атлап, бетон эшләренә әзерлек алып баручылар янына килеп туктадылар.

Шунда Булатов янына ашыгып Галиулла килде дә:

— Әйдә әле, иптәш Булатов! — диде.

— Кая? — дип сорады Булатов, үзе бераз каушады.

— Буага!

Булатов белән Галиулла буага таба йөгерделәр. Алар артыннан баш инженер Рейдел дә атлап китте. Буа янына җиткәч, Булатов тамагын кырып куйды да буаны җентекләргә тотынды. Вакытлы буаның аскы ягыннан кечкенә генә елгачык чылтырап агып ята иде. Ул шуны гына күрде.

— Шул гынамы? — диде Булатов.

— Шул гына.

— Давай бригадаңнан биш кешене куй, кызыл балчык төясеннәр! Бар көчләренә төясеннәр.

Рейдел өенә ашыкты.

— Яхшы карагыз, Булатов, куркыныч борын төбендә,— диде ул.

Шул минутта ук прорабның приказы җиренә җиткерелде. Биш носилка бертуктамый балчык ташый, өч эшче китерелгәнне тыгызлап, трамбовать итеп торалар. Аңар да карамыйча, шаулап, бөтерелеп аккан кечкенә елгачык һаман зурая бара, үсә бара.

Булатов әле бер носилкаларга балчык төяүче эшчеләр янына чаба, әле трамбовать итүчеләргә кычкыра:

— Катырак төегез, иптәшләр, катырак...

Елгачык зурая бара. Инде буаның өске ягыннан да су актарыла. Димәк, буа ерылды дигән сүз.

Кемдер кинәт шаулап аккан суга сикерде, үзе аягүрә көчкә генә басып тора, куллары белән су кырыендагы субайларга кадакланган тактага ябышкан, бот төбеннән суда.

— Кап китерегез! Кап! — ди ул.

Бу Булатов иде. Аның артыннан Галиулла белән Вәлүк суга сикереп төштеләр дә Булатов сүзләрен кабатладылар:

— Кап китерегез!

Берьюлы берничә кап китерделәр. Кап, суны чәчрәтеп, ерылган җиргә килеп төште. Кемдер авылдагы елгаларны тирес белән буу турында инженерга җиткерде:

— Даваегыз, тирес китерегез! Тирес! — диде инженер. Носилкалы кешеләр тирескә дип йөгерделәр, берничә

минуттан тирес тә килде. Шарлап агып торган суга төшкән өч кеше кире чыктылар. Булатов өзек-өзек приказ бирде:

— Галиулла, барлык эшчеләрне уятып алып кил. Ә мин үзем телефонга. Сабир, син монда кал.

Булатов конторда, телефон трубкасын тоткан килеш, ашыгып кына сөйли:

— Ефим Николаевич! Ерды. Нишлим?

Аннары тагын Якты күл буена төшеп китте. Ул хәлсез иде. Кинәт ул суны брезент белән бумакчы булды. Бу шәп һәм яңа уй иде. Шул уй белән бергә аның талчыккан тәненә дә хәл кереп киткән төсле булды.

* * *

Иртәгесен кояш көндәгечә шатланып, көлеп, нурга манчылып чыкты. Ләкин «Светогрэс» коллективы йөзе генә болытлы көн сыман караңгы, кайгылы иде.

...Булатов әллә нинди җиңелү моңсулыгы белән доклад ясый:

— Иптәшләр! Без вакытлы рәвештә чигенеп торабыз,— диде ул.

Гуревич үзенә хас бер елмаю белән карый: «Тырышып карыйсың да, тик белемең генә җитми бит. Иртәгә рәшәткә булыр үзеңә...» — дип уйлый ул.

Рейдел, уңайсызланып кына, күзлек аша Булатовка карап ала. Аны кызгана. «Менә әле җиңелүгә унике сәгать тә үтмәде, ике автомобиль белән килеп тикшереп тә киттеләр. Берсе РКЕдан, берсе райкомнан, тиздән, бәлки, ГПУдан да килерләр. Бәлкем, инде килгәннәрдер дә...» — Рейдел шулай уйлый.

«Төзелеп! башлыгы Вәлиев эш белән Мәскәүгә киткән иде. Ул кайтыр. Рейдел аңа ни күзе белән күренер, аңар ни дип җавап бирер? Ышанып, синең өстеңә калдырып китсәң дә шул дияр микән? Ә үзе булса да берни кыла алмаган булыр иде бит».

Гуревич ярым күңелсез рәвештә утырды. Ул Булатовка карап алды... «Ул шундый ябыккан... Дөрес булса, Булатовны эшли торган җирдә, конторда ук куна дип сөйлиләр. Шулай була торып та алып чыга алмады, мескен...»

Гуревич Булатовны аз гына булса да кызганды: «Менә инде арестовать итеп алып китәрләр. Совет режимы инженерлар өчен бик каты. Яшь инженер, совет белгече төрмәдә черер, фиркале бугай әле үзе», — дип уйлады ул.

Партия ячейкасы секретаре Адиловка да җиңелү уңайсыз. Менә дигән актив инженерың стройдан чыксын әле. Әйтергә генә җиңел, техпропаганданы юлга салып барганда гына бер татар инженерының бол ай китүе...

Язгы кояш нуры Булатовның чигәсенә төште. Кемдер форточканы ачты. Тыштан җиңел һава, яз һавасы бөркелеп керде.

Булатов эшнең ничек барганлыгын баштанаяк сөйләп чыкты:

— Без башта вакытлы буаны шпунтлап ясарга уйлаган идек. Такта юк, шуңар килеп терәлдек. Баш инженер белән киңәшкәннән соң, кызыл балчык тутырылган каплар белән буарга булдык. Кырыйга ике яклап шул каплар куелалар, уртага, төелеп, кызыл балчык салына. Анысы үзәк була инде, расчетка караганда, буа чыдарга тиеш иде...

Булатовның күзләре тагын да зуррак ачылганнар. Маңгай чәчләре дулкынланып киткән.

— Гидротехника — су белән сугышу эше ул, суга төрле корылмалар салу белеме, иптәшләр, бар эштән дә кыен эш булып исәпләнә.

Нидән килеп чыкты соң бу? Дөресен әйтергә кирәк, минем тәҗрибәсезлек тә, кышкы шартлар да — бары да безне җиңелүгә китерделәр. Киләчәктә ялгышны төзәтергә кирәк булачак. Без, кар эреп, җир кибүгә, тирәли шпунт кагып, буа ясап, су алгычтагы суны насослар белән суыртып эшкә башлаячакбыз...

* * *

Булатов доклад ясаган көннең иртәгесен Сабир, тузынып, Адушкин янына керде. Ячейка бүлмәсендә Адуш-кин үзе генә нидер язып утыра иде.

Сабирның йөзеннән үк Адушкин ни дә булса куркыныч әйбер барлыгын сизенде.

— Ни бар? — Ул шул соравын Сабирга бирергә ашыкты.

Сабир әүвәл тирә-ягына каранып алды да аннан соң гына, тамак төбеннән чыккан тавыш белән:

— Булатовны кулга алганнар, — диде.

Адушкин урындыгыннан күтәрелде дә, өстәлгә таба иелеп, бик гаҗәпләнеп:

— Ни сөйлисең? Булмас! Кулга алганнар, — диде.

— Әйе, ул кулга алынган.

— Булмас, юк сүздер. Булатов бит үзебезнеке. Ә безнекеләрне нишләп кулга алсыннар?!

— Йә, кызма инде, Адушкин, тикшерерләр бит әле. Алай калдырырлар дип беләсеңме әллә син!..

Сабир сүзләреннән ул бераз басылды, башын түбән иеп, тирән уйлап сүзсез калды.

— Их, Булатов! Алтын кеше иде ул, алтын... Менә беркөн шулай баракларга барып кердем. Ул эшчеләр арасында җәелеп утырган да техника түгәрәгенә җитәкчелек итә. Һәрнәрсәне төшендерә. Эшчеләр рәхәтләнеп тыңлыйлар... Кирәкле кеше иде ул безгә, кирәкле иде. Менә хәзер ул түгәрәкләргә кемне җитәкче итеп куябыз инде?

Сабир дәшмәде.

Ул Булатовка хәзер шикләнү катыш карауга кадәр барып җитә язды...

— Бу эштә корткычлык юк микән дип шикләнәм,— дип куйды ул.

Адушкин чын күңеле белән елый иде. Сабирның мондый шикле соравыннан ул сискәнеп китте:

— Бу нинди сүз? Нишләп? Комсомол кеше... Бит аның бар эше безнең күз алдыбызда, әгәр алай булса, синең белән мин дә...

Ул сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, ишек шакыдылар. Ул яшьле күзләрен тиз арада сөртте дә ишек кагучыга:

— Керегез! — дип кычкырды. Галиулла шаулап керде:

— Яңгыр коя, ә анда дождевой язмаска йөриләр. Адушкин аңламады, ахры:

- Ни бар? — дип кайтарып сорады. Галиулла тәрәзәгә күрсәтте. Аның юеш киемнәреннән идәнгә яңгыр тамчылары коела иде.

— Күрмисеңмени?

Адушкин тәрәзәгә таба борылды. Тәрәзә пыялаларына эре-эре яңгыр тамчылары килеп бәрелеп кире агып төшәләр. Адушкин, әле һаман төшенеп бетермичә:

— Җә? — диде.

— Шул менә. Гуревич, дождевой язмыйм, дип тартыша. Мондый яңгырда гына, ди...

— Язарлар, язмый булмаслар, — диде Адушкин, үзе Сабирга эндәште: — Даваегыз әле, Сабир, өчәүләп, теге заводка хат язып салыйк, бүгенге собраниедә үткәреп тә алырбыз.

Галиулла да өстәл янына килде.

Адушкин, карага манган каләмен күтәреп, маңгаена якын ук китереп, озак уйлады: «Ничек башларга?»

— Җә, табыгыз әле, җегетләр, ничек башлыйк? Алар өчәүләп уйларга тотындылар.

*«Сталин исемендәге Ленинград металлургия заводының комсомолларына».* — Кәгазьнең башына Адушкин шулай язып куйды.

*«Милли районнарның берсе булган Татарстан җөмһүриятендә салына торган «Светогрэс» теплоэлектроцентралънең комсомол коллективы сезгә түбәндәге хат белән мөрәҗәгать итә».*

Сабир да түзмәде, Адушкинның кулыннан каләмен тартып алды да кызу-кызу язып китте: *«Сезгә бирелгән заказлардан ике пар казаны һәм безнең станца өчен кирәкле булган башка нәрсәләрне өлгертүдә безгә комсомолларча ярдәм итәрсез дип ышанабыз. Безнең станца-ны җибәрергә тагын бер ай вакыт калды. Безнең турбиналарда хәзер монтаж эшләре бетеп, алар тиешле урыннарына урнаштырылдылар. Бар тоткарлык — сезнең пар казаннарында. Алынган телеграммага караганда, пар казаннары, инде юлда икән. Аларга кирәк булган вак кисәкләрен дә ашыгычлык белән җибәрүне сорыйбыз.*

*Безнең җиңү — сезнең кулыгызда!*

*Яшәсен юлбашчы коммунистлар партиясе!*

*Яшәсен электрлаштыруның шефы булган комсомол!*

*«Светогрэс» комсомол ячейкасы».*

Хат язылып бетте. Аны җыелышта тикшерәсе һәм җибәрәсе генә калды.

— Ну, егетләр, — диде Адушкин.— Безнең иң үзәк урыныбыз булып хәзер пар казаннарын урнаштыру. Алар унбишенче апрельдән калмый урнашырга тиешләр.

Иртәгесен кич комсомолларның гомуми җыелышы булды. Җыелыш өзеклелекнең сабакларын тикшерүгә багышланган иде.

Докладны баш инженер Рейд ел ясады.

Докладтан соң сораулар өстәлгә кәгазь күбәләкләр булып очтылар. Бер сорауга инженер озак тукталды.

— Менә монда бер бик җитди сорау бар: «Бу эштә корткычлык юк микән, шушы безгә доклад ясаучы да корткыч түгел микән?»

Залда утыручылар арасында шаркылдау булды, аннан бераздан тындылар.

— Юк, иптәшләр, хәзергә кадәр вөҗданымны сатканым юк һәм киләчәктә дә сатмам... Тиешле оешмалар эшнең бу ягын карарлар дип уйлыйм... Ну, иптәшләр, монда тагын Булатовның кайдалыгы турында сораулар бирәләр. Без әйттек инде, күп көч кую сәбәпле, Булатов талчыккан, ул хәзер бик каты авырый...

Җыелыш азакка таба бара иде. Клуб ишеген ачып берәү керде. Утырган кешеләр әйләнеп карый башладылар.

Ишектән ябык йөзле Булатов күренде. Кемдер утырган җиреннән кычкыра башлады:

— Николай Ефимович, үләргә яткан Булатов килгән. Ничек, ул аяк өсте авырыймыни?

Рейд ел бер сүз дә әйтмәде, ләкин аның йөзе яктырып китте. Адушкин да иркен сулап куйды:

— Булатовка сүз бирегез, ул сөйләсен, — дип, урыннан кычкыра башладылар.

Булатов сүз алды:

— Дөрестән дә, әз генә авырып алдым, ләкин хәлем бераз җиңеләюгә, менә монда килмичә калмадым. Дөрес, иптәшләр, бу авыр өзеклекне үткәрү ифрат кыен, бигрәк тә минем өчен кыен. Шуңа да мин, барлык авырлыкларга карамастан, эшләгән ялгышларымны төзәтергә сүз бирәм. Күрерсез, җиңү безнең кулда, бары безнең кулда булыр...

Тыңлап торучылар, аның сүзен бүлеп, кинәт кул чаба башладылар.

* * *

Элекке вакытлы буа ничек эшләмәскә кирәклекнең шаһиты булып калды. Киңәшмәдә тикшерелгән яңа проект буенча, вакытлы буа эшләтү һаман да Булатовка йөклэтелде.

Эшне кызулаттылар. Ике яклап шпунт коймасын сугарга да тотындылар.

- Югарырак, югарырак күтәр! Күтәрик, күтәрик!!!

- Раз возьмем, два возьмем, да, һоп, еще!

Шул тавышлар Якты күл буен тагын да җанландыра төште. Көндез дә, төнлә дә хезмәт җыры тукталмады. Өч көн үтәр-үтмәс, буаның коймалары ике яктан да әзер булды. Уртага кызыл балчык салынды. Аны нәзек катлау белән салып трамбовать итә бардылар. Буа кырыена мотор куелды. Баганадан тимерчыбык җибәреп, ток ялгадылар. Насослар әкрен генә суны суыртырга тотындылар. Су алгычтагы су җир төбенә сеңгәндәй булып кимеде. Менә инде тиздән аның төбе дә күренәчәк. Су китерү каналы Якты күл белән су алгычның икесен бергә тоташтыра да берсеннән берсен аерып ала алмаслык бөтен итеп ясый.

**Вакыт күп калмады**

Шул су каналын иң күп дигәндә унбиш көн эчендә казып бетерергә кирәк.

Булатов уйлады: «Ун көн, әйе, иң күп дигәндә унбиш көн. Туктаусыз эшләгәндә кырык биш смена дигән сүз. Кәр смена саен йөзәр кеше эшләсә, дүрт мең биш йөз эшче көче кирәк булачак. Юк, кул хезмәте белән генә булмый...»

Ул тагын чигәләрен учы белән тотып уйларга кереште. «Берәр машина кирәк иде, машина... Әйе, ничек тә булса эшне механикалаштырырга...» Кинәт ул ашыгып сызгалый башлады: менә канал буласы җирнең ике ягына баганалар сугып чыгасың, аларга, аркылы насадкалар ясап, такта җәйдерәсең. Уртада тактадан ясалган будка булачак. Будкага мотор белән лебедка урнаштырыла. Ле-бедкадан корыч аркан буенча түбән таба, су астына ковш асылынып төшәчәк. Аның авызы, соскыч авызы кебек почмак ясап, җиргә кадалып тора. Ковш өскә таба балчык алып менә. Менә монда, будка каршында, эстакада ясалачак. Шуның буенча ковш түбән һәм югарыга таба йөри. Чыгарылган балчыкны вагонетка килеп алып китеп тора...

Ул сызгалап бетерде дә Рейдел янына чапты. Бер кулына кепка, икенче кулына блокнот тоткан, ә тузган чәчләре дулкынлана. Ул конторга керер алдыннан комендатура аша үтте. Сакчы Булатовның бол ай ашыгып чабуын ни дә булса берәр куркыныч ашыгыч эш барга юрады. Артыннан куалармы әллә дип, Булатов килгән якка карады. Ләкин анда беркем дә күренмәде. Булатов баш инженер бүлмәсенә атылып керде.

Рейдел аның болай ашыгып керүеннән куркып китте.

— Николай Ефимович, эврика! Эврика! — диде Булатов.

- Ни бар, ни таптың?

— Менә су күтәрү каналын шулай казытам.— Ул үзеннән башка кеше таный алмаслык хәлгә килгән чертежын Рейд ел гә аңлатырга тотынды: — Менә моннан ике яклап субайлар суктырам, аннан такта җәйдерәм, эстакада да лебедка, мотор, ковш, вагонетка...

Сүз ахырында Рейдел проектны мактады:

— Бу бик яхшы фикер. Яңаны уйлап чыгару бит бу,— дип куйды.

«Их, тизрәк-тизрәк менә бу кечкенә блокнотта сызылган проектны гамәлгә ашырасы иде», — дип уйлады Бу-латов.

Кыш буе боз астында яшеренеп яткан Якты күл суы бүген зәңгәр һава төсен күрде.

...Булатов проекты буенча эш башланды.

Якты күл буена төшкән Гуревич Булатовның кыска бервакыт эчендә су алгыч каналында эшне ныклы юлга салып җибәрүенә гаҗәпсенде.

«Бу ничек болай? Димәк, унбише көн срок куелган су каналы... Эшләр болай барса, һичшиксез, ун көндә бетәчәк. Ул чакта Булатовка да премия, нинди яшь тәҗрибәсез кешегә!» — дип уйлады ул.

Гуревичның үзендә инженерлар турында гына йөртә торган үз фикере бар иде, ләкин ул аны кемгә дә булса сөйләп карарга батырчылык итмәде.

Гуревичның иң курыккан сүзе «корткыч» сүзе иде. Үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртучылардан, Гуревичтан эш киеме сорап кереп, ул яздырырга рөхсәт итмәсә, аны үз алдында ук шул сүз белән атаучылар бул-галады. Ике уртада йөргән Гуревичны совет ягына ныклап тартучы сәбәпләрдән берсе аңар «социализм төзүче» исемен алу булды. Кәм аңар, юлны эшләп бетергәч, премия дә бирделәр. Зур, якты, җылы квартирга да урнаштырдылар. Билгеле, Гуревич мондый эшләрне һич көтмәгән иде. «Большевиклар алар инженер хезмәтенә тиешле бәһа бирә алалармыни?» -- дип уйлый иде ул. Ләкин аның бу фикере дә дөрес булып чыкмады... Һәм Гуревич нейтральлектән акрынлап совет нигезенә, аерымлыктан коллективлыкка, бар көчен социализм фронтына бирә башлады.

* * *

Адилов бүлмәсеннән каядыр чыгып барадыр иде, аны Булатов туктатты.

— Мин сезгә җиңү рапорты белән, — диде.— Әйттем бит мин сезгә, иптәш Адилов, һәм шулай булып чыкты да: кичә төнге сәгать икедә канал казылып бетте. Бүген көндез су алгычка су җибәреп була. Теләсәң, ыстанны иртәгә үк ходка җибәр, су тоткарлык ясаячак түгел. Әле аңар тагын ике декада бар. Өстән генә исәпләүләргә караганда да эштә утыз мең сум экономия исәпләнә. Аңлыйсызмы? Утыз мең сум!

— Утыз мең сум?

Адилов, гаҗәпсенеп, шулай сорап куйды.

— Өстән-өстән генә исәпләгәндә дә әле, — диде Булатов.

— Молодис! Молодис! — Адиловның бар сүзе шул булды. Аннары ул: — Әйдә әле шунда киттек, — дип ялгады.

Алар күл буена таба атладылар.

Тиздән Якты күл буе тагын да яктыра төшәр. Тиздән Ильич лампалары берьюлы кабынырлар. Тиздән Якты күл буе гөрләп торыр...

Бер ай үтәр-үтмәс, Булатовка зур гына суммалы премия бирелде. Аны социализм Герое, төзелеш батыры дип тә игълан иттеләр.

Иректе илнең буеннан-буена төзү симфониясе яңгырый, чүкечләр чыңлый, тимер-бетон корпуслар башларын калкыталар, паровозлар ашыга...

**Төнлә**

Разия чишенде.

Чишенгәч, бүген ул да, башка кызлар кебек, өстәлендәге көзгесен алып үзенең йөзен карады: саргылтсу кашлар соргылт күзләрен асларына яшергәннәр, яңаклар за-водтагыга караганда суырыла төшкән, яңак сөякләре калкыбрак чыккан. Аннары ул көнлек дәфтәрен язарга утырды. Бәлкем, бу эш Разия өчен килешеп тә бетми торгандыр. Чөнки ул элек, андый эшләргә каршы чыгып: «Мещан гадәте булган шул альбомнарны, көнлек дәфтәрләре белән маташуларыгызны ташлагыз әле», — ди торган иде. Ә бүген Миләүшә авылына килгәч ясаган көнлек дәфтәренә үзе түбәндәгеләрне язып китте:

*«Авылга килгәнгә берничә айлар булды.*

*Әйе, бүген тәрәзә пыяласына көзге яцгыр тамчысы килеп сылана. Тышта җәй белән көз тартыша. Тышта җил. Агачларның, ялангач ботаклары өй тубәсен кыйныйлар. Мәктәп бүлмәсендә берьялгызы тору туйдыра башлады. Барысын да, барысын да ташлап, шәһәргә— заводка качасы килә, ләкин комсомоллык хисе ул саташкан уйларга ирек бирми, аларны авызлыклап тота.*

*Монда заводка караганда да көрәш көчлерәк тоела: бугазга-бугаз, йөзгә-йөз, сүзгә-сүз, канга-кан, үчкә-үч урыны бу.*

*Их, авыр да, татлы да, кызыклы һәм кызыксыз да син, көрәш.!*

*Бүген авыл советыныц утырышы булды. Икмәк за-даниесенец калдык өлешләрен бүлдек. Авыл уртасында әрәм булып череп ята торган Һашимов йортын колхоз правлениесенә бирдек. Ул Һашимов дигәннәре бик бай нәрсә булган икән, әйтәм,*

*заводта көлләү цехы һич алга китә алмыйдыр иде. Бай кеше соц Совет хөкүмәте өчен тырышамы! Әле нигәдер авылда йөри. Йортын тартып алганга эче поша булыр.*

*«Сабир, Сабир! Синең белән Миләүшә буендагы каеннар арасында йөргәндә, йөрәкләребезне бер-беребезгә ачып сала алган идек. Әллә хәзер мин оныттым, әллә син ташладың? Ник соң менә бу йөрәктәге бушлыкка мәхәббәт кереп утырасы урынга эш кереп утыра икән...*

*Мәктәп. Шулмы инде минем Сабирымны алыштырган әйбер. Яшь буын киләчәк тормышның матур чәчәкләре. Шулармы инде минем шатлыкларым? Ие, шулар. Болар бит бер-берсенә каршы, түгелләр. Бүген мәктәп. Иртәгә дә шул ук мине чорнап алыр...»*

Ул каләмен өстәл өстенә куйды. Көнлек дәфтәрен дә рәтләп җыеп куймыйча, караватына ауды. Ул бүген бик арыган иде. Ә тышта һаман-һаман җил үкерә.

Интек шыгырдады. Берәү акрын гына тупсаны каера башлады. Разия уянды.

Кем бар дигәнче, колагын салып тыңлады. Башта тыштагы җил генә шулай үкерәдер дип уйлаган иде, ләкин ике кешенең пыш-пыш үзара сөйләшкәнен ишеткәч, ул уеннан кайтты. Тупсаларны ныклап каерырга тотындылар. Разия тәрәзәдән сикереп урамга ташларга торганда, ишекне каерып керделәр дә аңар ташландылар. Берәү Разиннең бугазына ябышты. Аның тырнаклары йомшак муенга бүре тешләре күк сеңеп керделәр.

Биш минуттан инде Разиннең гәүдәсе идәндә ята иде.

...Иртәгесен көндәгечә балалар мәктәпкә җыелдылар. Алар укытучы апаларының дәрескә керүен озак көттеләр. Ахырда чыдамадылар. Берсе, дәшәргә дип, укытучы апаларының бүлмәсенә атлады. Керсә, ни күзе белән күрсен: апалары, чәчләре тузган килеш, идәндә аунап ята.

Малай куркып кычкырып елап җибәрде:

— Разия апаны үтергәннәр...

Буа ерылгандагы су ыргылган шикелле, балалар да ишеккә таба ыргылдылар.

Кичкә таба мәктәптә җыелып! булды. Кайгылы гомуми җыелышны укыту бүлеге мөдире Багданов ачты. Балалар, картлар, Миләүшә авыл халкы белән тулган зал эчтән генә көрсенде.

Багданов Разиннең тәрҗемәи хәленә, һөҗүмнең ничек булуына тукталды:

— Иптәшләр, Баязитова менә шушы залда утыручы ярлыларның баласы ул. Аның ата-аналары ачлыктан үлгәннәр. Шуннан соң ул балалар йортына эләгә. Аннан шәһәрдәге күн заводына эшкә керә һәм анда, үрнәк күрсәтерлек итеп бригаданың башында торган хәлдә, актив эшли. Эш белән бергә укуын да алып бара.

Укытучылар әзерләү курсында укып чыгып, безнең Миләүшә авылындагы ШКМга мөдирә булып керә. Биредә без аның авыл советы эшенә һәртөрле кампанияләрдә нык тырышып эшләгәнен күрәбез. Күрәсез, шуңа да сыйнфый дошман аны безнең арабыздан тартып алырга омтылды. Ләкин аның һөҗүме уңышсыз чыкты. Үләргә йөз тоткан сыйнфый дошман юкка гына безнең актив иптәшләргә ябырылмады.

Багдановның әйтерсең тамагына төер утырды: ул, сөйләүдән туктап, күз яшьләрен яшерер өчен түбән карады.

Өстәлгә бер кечкенә генә кәгазь кисәге килеп төште. Багданов бармак очлары белән генә кәгазьне ачты:

*«Иптәш, Багданов!*

*Заводка телеграмма җибәрергә кирәк. Аннан, сыйнфый дошманныц бу эшенә җавап итеп, моцарчы колхозга керми калган урта-ярлы катлаулар колхозга кермәк-че булалар. Телеграммада шуны күрсәт. Әхми».*

Язуны комсомол Әхми язган иде.

Багданов, язуга күз йөртеп чыкканнан соң, өзелеп калган сүзен дәвам итте:

—...Иптәшләр, Разия хәзер больницага озатылды, аның хәле авыр. Мин менә монда сезгә шәһәрнең күн заводына сугарга әзерләнгән телеграмманы укыйм:

*«Ленин исемендәге күн заводы партия ячейкасына Миләүшә авыл советыннан.*

*Кич 24 нче числога каршы төндә сыйнфый дошманнар колхоз яшьләре мәктәбе мөдирәсе Разия Баязитова-га һөҗүм кылдылар. Аны, каты рәвештә җәрәхәтләнгән килеш, больницага озаттык. Сыйнфый дошманныц бу чыгышына каршы Миләүшә авылы «Таллы Бүләк» колхозы обоз оештыра; ун хуҗалык колхозга керде.*

*Авыл советы».*

Багданов телеграмманы укып чыкты да сүзен дәвам итте:

— Һөҗүм кылучылар, иптәшләр, һичшиксез табылачаклар. Без шикләнгән кешеләрне инде кулга да алырлар. Без сыйнфый дошманнарга каршы кискен отпор бирергә тиешбез.

Ул да булмады, чәчләре тузган бер хатын, яшьле күзләре эчкә баткан бер ирнең кулыннан тотып, клуб ишегеннән сөйрәп керде:

— Ул кыйнаган Разияне, имансыз. Ул кыйнаган. Әйдә менә халык алдында ни йөзең белән җавап бирерсең, җирбит!

Хатын, баласын җитәклэгән сыман, сакаллы кешене президиумга таба өстерәде...

Ханым сәхнәгә менеп басты:

— Ишетәсезме, ул кыйнаган, дим Разияне! Салах кыйнаган! Эчүдән айнымаган нәрсә. Үз кызым кебек яраткан Равиямне кыйнаган. Менә халык алдында җавап бир, бәдбәхет нәрсә...

Хатын шулай буылып-буылып сөйләде:

— Бүген менә яктыргач кына кайтып керде. Бөтенләй үзгәргән, айныган... Үзе җылый, үзе сөйли... Әнвәр котыртты, ди. һашимовны әйтә. Тотарга кирәк имансыз-ны, качып өлгергәнче...

Сакаллы кешенең күзеннән борчак-борчак яшьләр акты, ул чынлап та елый иде.

— Сездән яшерен-батырын түгел, җәмәгать... Мин эчү белән бозылган бер кеше инде. Шулай, Һашимов кайткач, мине бер көн сыйлады, ике көн сыйлады: «Син шул Разия дигәннәрен дөмектерә алмассың микән? — ди. — Заводтан мине кудыртты, хәзер монда өемне тартып алдыртты», — ди. Күп эчүләрдән соң... Мин күндем... Менә шундый бер пычраклык эшләп ташладым...

Барысы да кызгану һәм ачу катыш хис белән картка карадылар.

Дөрестән дә, ул кызганыч иде.

Ул залдагы халык алдына килеп баскан... Керфекләре очыннан, борчак-борчак булып, яшь бөртекләре коела. Ул хөкем көтә... шыңшып-шыңшып елый...

* * *

Күптәнге ике танып: кеше поездда очраштылар.

— Кая киттең болай?

— Менә Төркестан ягына барып карыйм әле.

— Ә син кая?

— Менә дөньяны әйләнергә чыктым әле.

...Кинәт вагонга зәңгәр фуражкалы берәү керде, кешеләрнең документларын тикшерә башлады:

— Сезнең документларыгыз?

Зәңгәр фуражкалы кеше күптәнге ике танышның сүзләрен бүлдерде. Алар икесе дә берьюлы паспортларын чыгарып күрсәттеләр. Озын гәүдәлесенең документы зәңгәр фуражкалы кешене кызыксындыра төште, ахры, кесәсеннән телеграмма чыгарды. Телеграмманы паспорт белән озак чагыштырганнан соң: - Киенегез! — диде.

Биш минут эчендә зур гәүдәле кеше киенеп өлгерде.

...Әле генә булган күренеш танышына аңлашылмый калды. Имеш, кинәттән Һашимовны кулга алдылар. Ул бу эшнең очын уйлап чыга алмыйча урынына ятты. Тышта төн иде...

**Беренче май**

Бәйрәм таңы иртәнге кояш нурына күмелде.

Офык буен кызыл нурларга манчып күтәрелгән кояш үзе белән әнә шул киң шәһәр урамына да шатлык алып килде. Кичтән үк эленеп куелган байраклар иртәнге җилдә иренеп кенә тирбәлделәр. Киң урамнар аша тартылган лозунглар җиңүче сыйныфның йөрәгеннән ташыган бүгенге омтылышны үткәннәргә аңлаттылар.

Беренче май зур бәйрәм һәм җиңү көне иде.

...Бүген таңнан алып «Светогрэс» көндәгегә караганда да артык хәрәкәт урынына әйләнде. «Светогрэс»ка юнгштурм костюмы кигән комсомоллар, эш киеменнән эшчеләр бертуктамый агылып тордылар.

Демонстрация агымы, зур урамнарны әйләнгәч, Ленинга куелган һәйкәл янына җыелып, шәһәр башлыкла-рының рапортларын тыңлады. Аннан соң колонна Якты күл буена юл тотты. Байраклар җилнең исүенә ыргылып уйнадылар. Иң алда, трибуна янында ук, җиңүчеләр байрагы — светогрэсчыларга обкомол тарафыннан бирелгән байрак җилфердәде.

Музыка «Интернационал»дан бер куплет уйнагач, трибунада бөдрә чәчле, кылыч борынлы, зур күзле шәһәр советы рәисе Ефимов күренде:

— Иптәшләр, җөмһүриятнең гигант «Светогрэс»ны ходка җибәрү тантанасын ачык дип белдерәм...

Ул, «Светогрэс»ны төзүдә эшче сыйныфының каһарманлыкларына тукталганнан соң:

— Беренче сүз «Светогрэс» төзелеше башлыгы иптәш Вәлиевкә бирелә, — дип белдерде.

Шатлыклы «ура!» тавышы урман буена китеп яңгырады. Шул тавышны алып киткән җил көзгедәй күлнең өстен урман ягына таба йөгергән нәни дулкыннар белән шадралата.

...Вәлиев, уң кулындагы кепкасын йомарлый төшеп, сүз башларга омтылды. Ул, нәрсәдән башларга белмичә, беркадәр аптырабрак торды. Алай да ул, тагын бер омтылып, үзен кулга алды.

- Иптәшләр, бүген, — дип башлап китте ул, — бүген Беренче май. Алга куелган бурычны үтәдек. Җитмеш ике киловаттлы «Светострой» хәзер үзенең бер кисәге

белән «Светогрэожа әйләнде. Социализм эш методларын үзләштерү һәм партиянең нык җитәкчелеге астында без шушы уңышларга ирештек...

Музыка, аның сүзен бүлеп, шатлык көен уйнарга, колоннадагы эшчеләр, кызылармеецлар, хезмәткәрләр «ура!» кычкырырга тотындылар.

Соңыннан ул үзе дә сизмәстән кызып китте:

— Бүген Беренче май... Менә шундый көндә кечкенә генә бер эш бүләге китерү белән «Светогрэс» коллективы ифрат шат. Хәзер без унбиш мең киловаттлы «ВКП», ун мең киловаттлы «Ленин комсомолы», җиде мең киловаттлы «Пионер» дигән өч турбинаны җибәрәбез... Яшәсен Беренче май! Яшәсен алгы җиңүләргә җитәкләүче Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты һәм юлбашчыбыз иптәш Сталин!

Тагын «ура!», музыка тавышлары...

Вәлиевтән соң партячейка секретаре Адилов трибунага менде. Аның соры гимнастеркасының сул як кесәсендә җиңү ордены кадалган иде:

- Бу җиңү -- тагын бер партиянең тоткан юлының җиңеп чыгачагына, бишьеллык планның тулысы белән дүрт елда үтәләчәгенә җанлы шаһит. Сыйнфый дошманнарның авыз ерып көлүләре, оппортунистларның безгә хыялланучылар дип караулары безнең эшкә һичбер төрле дә комачаулык ясый алмады. Без, җиңү байрагын югары тотып, аңар кер төшермәдек... Сүзләр күп булды: имештер, «Светогрэс»ның бер як стенасы ярылган, имеш, бер як фундаменты җиргә сеңеп бара икән, быел станцаны ходка җибәрә алачак түгелләр икән... Ие, без мондый сүзләрне ишеттек, ләкин бирешмәдек. Карагыз (ул кулы белән бетон корпуслар ягына таба күрсәтте), элекке ташландык җирдә нинди гигант төзедек. Караңгылык баскан Якты күл буенда Ильич лампалары кабыздык!..

«Ура!» тавышы тагын урман буена китеп яңгырады. Инженер-техниклар исеменнән котлаучы Булатов сүзен кыска тотты:

— Безнең җиңүне шатланып каршы алган һәм аны үз күзе белән карарга дип килгән эшче сыйныфына ялкынлы сәлам! Совет төзелеше өчен җаннарын фида итәргә торган белгечләр һәрвакыт сезнең белән! — диде ул.

Адушкин да, Сабир да сөйләделәр. Бөтен сүзләр һаман шул җиңү ялкыны белән тулган иде.

Бер пионер, алга чыгып, быргы кычкыртты. Эстакададагы ленталар үзләре белән бергә өскә таба ташкүмерне әкрен генә сөйрәп алып менеп киттеләр. Күккә таба сузылган бетон корпуслар эченә яшерелгән машиналар үкерергә, Якты күл буендагы насослар су суырырга тотындылар.

Күп тә үтмәде, ораторлар сөйләр өчен ясалган трибуна буенда карбыз зурлыгындагы лампада ут кабынды.

Пионерлар бертуктамый барабан кактылар. Музыка «Интернационал» уйнады. Их, күңелле дә иде соң җиңү көне!

Шул җиңү көне өчен әйтерсең кояш та шатлана... Якты күлдәге кичәге дулкыннар каядыр югалганнар, камышлар да, шәмдәй булып, җиңү музыкасын тыңлыйлар.

Шәһәр шау-гөр килә...

* * *

- Вафа, сиңа хат бар! — дип, Вафаның кулына зәңгәр конверт китереп тоттырдылар. Хат Фатыймадан иде:

*«Атасы!*

*Менә без малаец батыр белән икәүләп сица хат язабыз, синец якка искән җилләргә ялгап, сица булган ялкынлы сәламнәребезне җибәрәбез. Язган хатыцны алдык, бик зур рәхмәтләр әйтеп, хат язганыңа шатланып калабыз... Әти кешегә бер яца хәбәр бар: хәзер без тотынып баса башладык инде. Әнкә белән икәүләп һәр көнне яслегә барабыз. Көнебез менә шулай үтә.*

*Үзем яслегә эшкә кердем: мөдирә булып эшлим. Ничә бала минем кулда тәрбияләнә. Син әле киткән чагың-да: «Малаемны бозар инде бу тәүфыйксыз нәрсә дип уйлагансыңдыр». Курыкма, мин ул иске гадәтләремне ташладым инде.*

*Менә армияңнән кайт, күрерсең, гөрләп тора башларбыз, хәзер мин гаиләнең нәрсә икәнен аңлый башладым... Кайт әле менә, атасы. Җимерттереп торырбыз, валлаһи.*

*...Сабирны бригадирлыктан десятник итеп күтәргәннәр. Галиулланы, бик файдалы тәкъдим ясаганы өчен, биш йөз сум белән бүләкләделәр. Каядыр укырга китәргә йөри бугай.*

*Күн заводы комсомоллары «Светогрэс» белән ярыштылар. Күчмә байракны Сабирлар алды.*

*Тиздән станцаны җибәрергә җыеналар.*

*Ярый, хуш..*

*Сине сагынып, Фатыймаң.*

*20 апрель».*

Хатны укыгач, Вафа уйга батты. Аның күз алдыннан бер-бер артлы күн заводында эшләгән көннәр, җанлы газета, җыелышлар узды.

...Майның уны иде.

— Ур-ра, ходка киткән, чынлап ходка киткән! — дип, газета тоткан килеш, Вафа, балаларча шатланып, казармадагы иптәшләре янына атылып килеп керде. — Иптәшләр, карагыз әле, карагыз әле! — дип, ул газетага тупас бармаклары белән сугып куйды. — Киткән, ходка киткән!

— Ни булган? Нәрсә ходка киткән? — дип, аны башкалар чорнап алды.

Укыганчы, ул рәсемнәрне күрсәтергә тотынды:

— Менә бусы — дулкынланып торганы — Якты күл дигән күл инде. Әнә ерактарак бер читтә бетон корпуслы бер йорт күренәме? Ул — мин эшләгән күн заводы. Ә менә бусы — «Светогрэс». Менә шул, моннан ун көн элек кенә ходка киткән. Менә бу рәсемне күрәсезме? — Баш инженер Рейдел. Менә бусы — Буланов дигән инженер. Теге, төрмәгә япкан булганнар да иртәгесен үк чыгарганнар, дип сөйләгән идем бит... Менә болары — минем авылдашлар, икесе дә безнең Миләүшәнекеләр; бусы — җир казучылар бригадиры Биктаһиров — зур гына экономия ясый торган тәкъдим керткән өчен бүлкәләнгән кеше. Бусы - - бетонщик ларның бригадиры Сал ахов. Бусы — партком Адилов. Рабочком Корнишин, комсомол секретаре Адушкин... Бол арның һәрберсе хезмәт ордены белән бүләкләнгәннәр.

Ул күрсәтеп бетерде дә:

— Их, кайтырга иде, күрергә иде шул « Светогрэс»-ның яктысын! — дип куйды...

**Эпилог**

Шәһәр читендә үзенең бетон корпуслары белән «Светогрэс» балкый. Зур тәрәзәләрдән җиз чыбыклар сыман ут яктылары күлгә сузылалар. Әйтерсең күл эченнән әнә шундый энергия чишмәсе туган...

Кожкомбинат төзелешендәге инженер-техниклар киңәшмәсеннән кайтучы техник Сабир Салахов үзенең бригадасы кулыннан үткән бетон корпусларга карап ала да үткәндәге хәлләрне, кешеләрне, бөек эшләрне күз алдына китерә. Инженер Рейдел Сабир Салаховның аркасыннан үзенең зур куллары белән кага: «Егет син, Сабир, егет, — ди. -— Тормышның югары ноктасыннан, тау итәгеннән тау башына менгән кебек үрмәлисең, яратам мин сине», — ди. Күптәнге бу сүзләр бүген әйтелгән кебек күңелдә сакланалар...

...Баштан үткән еллар, таныш кешеләр, аларның фигуралары, экранда алмашынып торган күренешләр кебек бертуктамый алмашынып торалар. Җәйге кояш офык артына яшеренгән.

Күктәге кызыллык та бетә бара. Шәфәкъ караңгылыкта югалырга юл алган. Ә Сабир Якты күл буйлап атлый. Шул тирәдә, Якты күл буен гомерендә беренче тапкыр күргән кеше сыман, бер кызылармеецның кызыксынып карап йөргәне

күренә. Ул күлнең озынлыгын да, «Светогрэс»ның бетон стеналарын да дикъкатьләп карый. Әлеге кеше шлемлы башын әле бер, әле икенче якка бора. Армеецның йөзендә шатлык елмаюы балкый.

Сабир адымын шул армеецка таба ешайта. Армеец та, Сабирга игътибар итмичә, күл буйлап «Светогрэс»тан ерак түгел яңа гына төзелеп ята торган тире комбинатына таба атлый.

Армеец, бәлкем, искәрми узып та киткән булыр иде. Ләкин Сабир аны туктатты:

— Вафа, бу син түгелме?

— А-а, Сабир, саумы?

Күптәнге дуслар озак итеп күрештеләр.

— Кайттым диген.

— Әйе, менә елны тутырдым да кайттым. Җә, сөйлә, кемнәр кайда эшлиләр?! Минем бик беләсем килә. Бит инде минем сине күрмәгәнгә ике ел тулды. Ә сез шул арада нинди корпуслар үстергәнсез! Тегесе күнкомбинат-мыни?

Сабир кайдан башлап китәргә дә белми торды.

— Рейдел, Булатов, Гуревич, Галиулла кебекләр кызыксындыра торгандыр инде сине?

— Билгеле, шулар. Бит мин соңгы вакытларда синең белән эшләсәм дә, алар миңа танышлар.

— Рейдел Владивосток ягына бер зур электр станца төзелешенә Энергоцентр тарафыннан күчерелде. Хәзер партиягә кергән икән, ду китереп төзеп ята, ди. Булатов биредә, аны күп вакыт очратам. Авыл хуҗалыгы институтында гидротехника кафедрасында доцент булып эшли. Ә Галиулла, Мәскәүгә хронометражистлар курсына барып, аны бетереп кайтты. Хәзерге вакыт бездә — кож-комбинат төзелешендә, хронометражист Гуревич шәһәрдән ерак түгел синтетик каучук заводы төзелешендә дип ишеттем.

Вафа, бер урынга баскан килеш, Сабирның сүзләрен дикъкать белән тыңлады. Аны бигрәк тә Галиулла мәсьәләсе кызыксындырды, шуңар ул Сабирдан кайтарып сорады:

— Галиулла бит әле ул яртылаш надан иде, кай арада укып өлгерде, — дип куйды.

Сабир аның сүзенә каршы халык мәкале белән җавап кайтарды:

— Тырышсаң табарсың, ташка кадак кагарсың, диләр бит.

— Әйе, шулай инде.

Алар Якты күл буйлап озак сөйләшеп йөрделәр. Сүз Һашимов турында да булды. Сабир Һашимовның кулга алынгач каядыр юкка чыгуын сөйләде. Атасы Салах турында күп каршылыклардан соң Миләүшәдә төзелгән «Сталин» колхозының актив члены булып китүен әйтте.

Хәлил Сафинны телгә алучы да булмады. Элекке мөдир үзенең укучылары күңелендә бераз гына булса да җылы хис калдырмаганга, аның турында сүз дә чыкмады.

Вафа никтер Разия турында бер дә сорашмады. Алар озак йөрделәр. Ай Якты күл аша үзенең нурларын алтын сукмак итеп таратты. Йолдызлар күптән күрешмәгән ике иптәшнең йөрәк серләрен тыңлаган сыман җемелдәштеләр.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, Сабир торган йорт янына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Сабир ишек буендагы тәрәзәне әкрен генә чиртте. Өй эчендә кемдер торды. Ишекне ачтылар.

Ишек ачучы Разия Баязитова иде.

*1931 — 1932*